Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

09
сентябрь 2019
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ВИКТОР КУДЕЛЬКИН «ЯШЬ РӘССАМ»

ИЗГЕ КӨНДӘ – ИЗГЕ ГАМӘЛ

13 августта язучы Ләбиб Лерон һәм «Безнең мирас» журналы редакциясе «Миллият йорты»нда Корбан ашы уздырды. Анда ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, күренекле ветеран журналистлар, әдипләр, галимнәр һәм дин әһелләре катнашты.

Фоторепортажның дәвамы 62-63 нче битләрдә. Салават Камалетдинов («Татар-информ») һәм Ленар Гобәйдуллин фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +
09 (309)
сентябрь 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

106

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Шәүкәт Гаделша**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*
12 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
20 **Татар шырпы заводлары.** *Л.Мортазина*
24 **Большевизм уты астында.** *К.Нәҗми*
30 **Археографик көндәлек.** *М.Госманов*
36 **Татар телендәме, рус телендәме?** *Г.Гобәйдуллин*
40 **Гаяз Исхакый – француз журналында.** *Л.Галиева*
42 **«Күпме яшь күкрәкне изге дип издермәдем».** *М.Фәйзи*

ТАТАР ГАМЕ

48 **Яшел тышлы китап.** *Х.Ибраһим*
50 **Безнең заман һәм замандашлар.** *Р.Хәмидуллина*
58 **Пушкин белән шигырь алмашу.** *З.Мансуров*

ДИНИ МИРАС

64 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

70 **Хөсәен мирза.** *Ф.Бурнаш*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

78 **Гомәр Бәширов көндәлегеннән**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 **Сәер дустыбыз Шамил.** *Ә.Фәйзрахманов*
83 **Сурәтле хатирә**
84 **Тарих шаһитлары.** *А.Дубин*
90 **Мәктәпләр һәм сабакташлар.** *Л.Лерон*
94 **Истә, һаман да истә!**



Onzième Année — N° 114 — MAI 1936

PROMÉTHÉE

Organe de défense nationale des Peuples du
CAUCASE (GÉORGIE, AZERBAIDJAN, CAUCASE DU NORD)
de l'Ukraine et du Turkestan

Directeur : Georges Gvazawa

40 **ГАЯЗ ИСХАКЫЙ – ФРАНЦУЗ ЖУРНАЛЫНДА.**
Ләйсән Галиева

84 **ТАРИХ ШАҺИТЛАРЫ.**
Абдулла Дубин

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Лотфулла Шәфигуллин
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

96 **«Әнвәр».** *Ә.Зарипов*
102 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*
106 **Якты күңелле җырчы.** *А.Хәкимова*

ХӘТЕР САГЫНДА

111 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **ТАССР тарихы – фотоларда**

Заказ №О-2271. Тираж – 2150 данә. Формат 70х108 $^1/_{16}$.
Басарга кул куелды: 22.08.2019.
Чыгу көне: 28.08.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы В.Кудельшкин рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Яшь рәссам»**. 1957. ***Виктор Кудельшкин рәсеме***

Шәүкәт Гаделша*

Яшәү белән үлем арасында

Ерак китмәдем мин, монда гына –
Яшәү белән үлем арасында.
Сукыр язмышымны тартып бара
Болытларның агы, карасы да.

Ап-ак болыт, йөзең чынмы ап-ак?
Кара болыт, син дә чынмы кара?
Арлы-бирле йөреп, эзлисезме
Күктән чыгып качар өчен ара?

Без үләнгә, чыкка әйләнәбез
Сез яудырган яңгыр, кар астында.
Сез качсагыз, безне кем юандырыр
Яшәү белән үлем арасында.

*Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты, шагыйрь Шәүкәт Гаделша (Шәүкәт Гаделша улы Сибгатуллин) 1949 елның 16 сентябрендә Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде районындагы Киндерле авылында туган.

Редакциядән: Бу айда мөхтәрәм каләмдәшебезгә 70 яшь тула. Шагыйрьне гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез! ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән.

Сафагәрәйнең шәхесе һәм язмышы Казаннан, Сөембикәдән аерылгысыз, әлбәттә. Ул, хакимияткә ашкынудан бигрәк, хаталар ясый-ясый, үзен табарга омтыла һәм күңеленә якын булган Казанга әйләнеп кайту юлларын эзли. Казанга кайту – Сөембикә алдында аклануның төп билгесе. Кабат Һади Атласига мөрәҗәгать итәбез: «Сафагәрәй хан, Казаннан куылгач, Нугай йортына китте. Йосыф мирза аның каенатасы булганга, ул аңардан ярдәм алып килергә... уйлады... Йосыф мирза Сафагәрәйне яратмыйдыр иде. Сафагәрәйнең: «Бары тик синең аркаңда гына Казанны яңадан ала алырмын; моннан соң син әйткәнчә булырмын...» – дигән сүзләре мирзаны йомшартты», – дип язып калдырган ул.

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

Бу өзектә кыйсса татар тарихында кара мөһер генә алып калган, әле дә булса каһәрләнә торган Шаһгалине «терелтә». Иң сәере: ул бәхетсез бәндәне Мәскәү дә читкә кага – 1531 елда, бер ел чамасы үтүгә, аны Кашир һәм Серпухов якларына «мактаулы» сөргенгә озаталар. Касыйм ханы таҗын кию генә коткармый: Шаһгали, чагыштырмача гадел тарихчылар Николай Карамзин һәм Михаил Худяков язып калдырганча, «бөек кенәз белән килешүне бозу»да гаепләнеп, чын-чынлап «изгой»га, ягъни мөртәткә әйләнә. Аның

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

яраннары да төрмәләргә ябыла, берничәсенең (романда әйтелмәгәненә өстик – Новгородта 80нән артык ир-атның) җаны кыела. Казан ханы, Шаһгалинең бертуган абыйсы Җангали үтерелгәч, бөек кенәз Иоаннга (әле 6 гына яшьлек Иван Мөдһишкә), Русиядә урнашкан тәртип-гадәт буенча аның исеменнән балигъ булганчыга кадәр идарә итеп торган анасы Елена Глинскаяга башын иеп баргач кына, бу «татарчонок-ханчык» алдында Казанга юл ачылган кебек... «Иоанн аны татар телендә сәламли һәм уртак табын янына утырта», – дип яза тарихчы галим...

Сөембикә, озак аңсыз ятканнан соң, ниһаять, исенә килде. Аның карашы кайбер урыннары келәм яки тиреләр белән капланган, ысланган тирмә диварлары буйлап шуышты. Почмакта шатыр-шотыр килеп янган учак бөтен тәненә рәхәт җылылык бирә. Хатын урыныннан тормакчы иде, ләкин хәлсезлектән башы әйләнеп китте. Газаплы ыңгырашып, ул куян тиреләреннән ясалган юрганга авып төште. Тавышын ишеттеләр, күрәсең, аның ягына, башын иеп, бер ир кеше килеп керде.

– Димәк, бу хәлләр күземә генә күренмәгән? – дип пышылдады ханым. – Мине син коткаргансың икән, Әхтәм бәк.

Хатынның хәлсез елмайган иреннәре калтыранды, ул алдында катып калган бәкне баштанаяк күздән кичерде. Сөембикә аны соңгы тапкыр күргәннән соң ул бөтенләй үзгәрмәгән кебек: шундый ук таза киң җилкә, кечкенә кара сакал уратып-каймалап алган батыр чырай. Әхтәм бәк, ханбикәнең ятагы алдында тезләнде дә, башын иде:

– Җәзага тартырга яки ярлыкарга мөмкинсез мине, ханым, әмма бөтен дөньяда бер генә зат та Сезнең монда икәнлегегезне белми. Ә миңа бик аз гына кирәк, ханбикә. Аяк очыгызда кол булырга рөхсәт итегез, тик боерыгыз гына һәм мин Сезнең өчен мөмкин булмасны да эшләячәкмен!

Сөембикә дәшмәде. Учактагы ут әкрен генә шатырдап алды. Хатын кинәт кенә кулын сузып үрелде, ирнең күкрәгенә кагылды. Бармаклары кәзәкиенең атлас каймасы буйлап йөгереп узды. Әхтәм бәк, көтелмәгән наздан гаҗәпләнеп, тынсыз катып калды, аз гына селкенсә дә, бу тылсымлы мизгел югалыр кебек иде. Әмма тылсым, ханбикәнең катгый, бер өмет тә калдырмый торган сүзләрен ишеткәч, юкка чыкты:

– Миңа язганы син түгел, Әхтәм бәк. Бу дөньяда без беркайчан да бергә була алмабыз. Мин сине анда – Казанда еш искә төшердем, Җангалидә кияүдә чагымда. Мин бик бәхетсез булдым, әмма язмышым ләүхелмәхфузда[1] шулай язылгандыр һәм аны үзгәртергә, Аллаһтан кала, берәүнең дә көче җитми!

Ир тиз генә муенын турайтты, кысылган тешләре арасыннан, үҗәтләнеп:

– Әмма Ходай сине миңа китерде, Сөембикә! – дими түзмәде.

Хатын башын чайкады:

– Юк, Аллаһ безгә, рәхимлек күрсәтеп, бәхилләшергә генә мөмкинлек бирде.

Бәкнең тәне дерелди башлады, ул яңадан иелеп төште һәм ханбикә, шулкадәр нык, гайрәтле ирнең тавышсыз гына иңрәвеннән аркасы ничек калтыранганын күрергә көче җитмичә, икенче якка борылды.

Ә тирмәнең киез диварлары артында инде күп санлы ат тояклары тавышы ишетелде, көчле ачы тавышлар яңгырады. Шуның артыннан ук кыныннан чыккан корал чыңлап куйды, кемнедер эчкә уздырмыйча, нөкәрләр ярсып кычкырды. Әхтәм бәк тиз генә аягына басты, көчле куллары биленә таккан хәнҗәр сабын кысып алды, ул, сөеклесен якларга әзер булып, тәвәккәл рәвештә чаршауны ачып җибәрде. Ләкин аны Сөембикәнең әкрен тавышы туктатты:

[1] Ләүхелмәхфуз – язмыш китабы *(тәрҗ. иск.)*.

– Син бу ахмаклыкны эшли алмыйсың, Әхтәм бәк, үзеңнең кешеләрең, торлагың турында уйла. Синең нәселең, бәк, акылыңа килергә чакыра!

Ул арада торакка, сакны бер читкә тибәреп, инде нугай яугирләре керә башлады. Бәкләр бәгенең йөзбашы аил хуҗасына баш иде дә:

– Тынычлыгыгызны бозганга гафу сорыйбыз, Әхтәм бәк, әмма без бәкләр бәге Йосыфның кушуы буенча аның кызын эзләп киләбез, – диде. – Сөембикә ханым берничә көн элек далада югалган иде. Безгә Сезнең ул хатынны табуыгыз турында хәбәр килде...– Сугышчы сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, өстенә ипсез озын чабулы сарык туны салган симез адәм, аның артыннан ук кереп, тыела алмыйча үкерде:

– Ханбикәм! Яраткан ханбикәм, Аллаһка шөкер, Сез исәнсез икән!

Шулай диде дә күңеле йомшак Җәгъфәр ага, күз яшьләре белән шатланып көлүен бергә кушып, Сөембикәнең аяк очына егылды.

***

Сафагәрәй инде унынчы көн Хаҗитарханда Габдерахман хан хозурында утыра иде. Кунакчыл хаким Казаннан сөрелмеш ханны кочагын җәеп каршы алды. Кара халыкның баш күтәрүе һәм шундагы түрәләрнең сатлыкҗанлыгы турында сөйләвен Сафагәрәйнең хәленә кереп тыңлады. Аның хәрби булышлык итүен соравына да каршы килмәде, тик хәбәр салучылар далага таралган нөкәрләрен җыйганчы гына сабыр итәргә кушты.

– Ә сез, кадерле туганым, Хаҗитарханда кунак сыен авыз итә торыгыз, – диде юмарт Габдерахман. Ул, сарай тәрәзәләре астында җәйрәп яткан каланы кочагына алып, Казан ханының каршысына китереп куйгандай хәрәкәт ясады. – Монда барысы да Сезнеке, Сафагәрәй.

Ләкин, Габдерахманның кунакчыллыгына, мул вәгъдәләренә карамастан, Казаннан куылган ханның күңеле төшенке иде. Авыр уйлар Сафагәрәй маңгаендагы күңелсез сырларны боргычлады, аны шик һәм курку упкынына батырды: «Әгәр тәхетне кире кайтарып алуга ирешеп булмаса, Казанны бүтән гомеремдә дә күрмәячәкмен бит инде. Ул чакта Сөембикәнең күзенә ничек карармын да бәкләр бәге Йосыф йортына кыюлыгымны җыеп бара алырмынмы?»

Кунакның салынган борынын күтәрер өчен, хуҗа төрле уеннар башлап җибәргән булды. Атта оста җилдерү яки ат чабышымы, җәядән ату һәм сөңге ыргыту дисеңме – һәммәсендә дә кырым егете Кечүк җиңеп чыкты. Габдерахман ханның үз кулыннан алган бүләкне – кыйммәтле кылычны – ул, түбәнчелек белән башын игән хәлдә, Сафагәрәйгә китереп тапшырды:

– Хаким, сугышчыгыздан көч, булдыклылык вә җитезлек таныклыгын кабул итеп алыгызчы. Яугирләрегездән бармак белән генә санарлык, ягъни бер учка сыярлык кына кеше калса да, ул учтагы гаярь затларны бөртек итеп уңдырышлы туфракка сипсәң, озак та үтми гайрәтле гаскәр үсеп чыгар! Сугышчыларыгызны кайнар көрәш эченә җибәрегез һәм без Казанны аяк очыгызга китереп куярбыз. Ә ошбу кылыч... Ул хакимнәренең аркасына пычак кадарга маташкан дошманнарыгызның башын кыеп төшерсен!

Сафагәрәйнең күзләре шушы мәлдә яктырып китте, сүрелгән сугышчан рухы кабат канатланды. Ул, Кечүк углан кулларыннан алган кылычны, затлы сабын учында кыскан көе, баш очында уйнатып алды:

– Ант итәм, сатлыкҗаннар тиешле җәзасын алырлар! Ә кем минем белән бара – бәрхет вә ефәккә төренер, козгыннар көтүе өстендә лачын булып очар, морза вә бәкләрдән югарырак күтәрелер!

Кырымлылар беренче булып кычкырды:

– Без синең белән, бөек хан! Алга, Казанга таба!

Аларның оран салуын хаҗитарханлылар да күтәреп алды.

Озакламый, Сафагәрәй ханның Габдерахман белән саубуллашыр сәгате сукты. Хаҗитарханның ике меңлек иреклеләр гаскәре аны шәһәр капкасы төбендә көтеп тора иде инде. Хаким белән йөзне-йөзгә куеп кысып кочаклашкач, Сафагәрәй әйтә куйды:

– Мин сине беркайчан да онытмам, туганым!

Хаҗитархан ханы күзләрен хәйләкәр генә кыскалап алды:

– Яшерен-батырын түгел, минем морзаларым да кайчак киреләнеп, тәртәгә типкәлиләр... Әгәр Габдерахман үз өлешенә тигән көмешен кулыннан төшереп җибәрә калса, мин сиңа өметләнермен, Сафагәрәй.

– Бабаларыбызның изге исеме белән ант итәм, минем сугышчыларым синеке булыр!

Казан, кыш китәр алдыннан, көннәр язга авышкач кына, аларның күз алдына калкып чыкты. Карга чумган шәһәр җиңелмәс калкан сыман нык, буй җитмәс биеклектә тора иде. Сөрелгән хан аек акылы белән бик яхшы аңлый: Казан кебек, теш үтмәслек мондый ныгытмага ике мең җайдак җитди куркыныч түгел. Әмма өмет уты, аз гына калса да, һаман пыскый... Сафагәрәй башкаладагы үзенә тугрылыклы кешеләргә ышана иде әле. Хаҗитарханлылар исә, әле генә көтүгә чыккан сыер-сарык көтүе кебек, тиз арада төрлесе-төрле якка таралып-чәчелеп киттеләр, Казансу яры буенда, үзләренә әллә ни кызык таба алмыйча, әрле-бирле, шул ук вакытта хуҗаларча йөренделәр, диварларга менеп өелгән шәһәр халкына да ара-тирә күз төшереп алгаладылар. Сафагәрәй, сабырлыгын җыеп, һәр көнне бабаларының моннан ярты гасыр элек төзелгән, уклар да вата, туплар да җимерә алмаслык калын-каты тимер-корыч белән тышланган капкалары ачылганын һәм казанлыларның, язмыштан узмыш юк, дип, яисә сабырлыклары төкәнеп, каршы чыкканын көтте. Вакыт уза торды, әмма могҗиза капкадан чыкмады, күктән дә төшмәде. Бистәнең кайбер кешеләрен тотыклап сораштылар-белештеләр: пайтәхет әле дә булса идарәчесез яши икән. Ханлык башында Боерган сәед һәм Кадыш белән Чуранарык бәкләр тора. Кулга килеп эләккән чапкыннан исә, Казан җиренә хакимлек итәр өчен бөек кенәз билгеләп куйган ханны алып кайтырга дип, Мәскәүгә бер шәехне җибәргәнлекләре мәгълүм булды. Ярсыган Сафагәрәй әсир чапкынны Кечүк бүләк иткән кылыч белән чабып ташлады.

– Хаиннәр! Алар, шәһәргә тик мине кертмәс өчен генә, урыслар алдында тез чүгәргә әзер икән!

Ә көннәр үтә торды, Сафагәрәй ханның барып чыкмаган эшенә яңадан-яңа бәлаләр өстәлә бара иде. Хаҗитарханлылар, бөтен тирә-юньне талап, яндырып бетергәч, Казан янында мәгънәсез басып торуларына ачыктан-ачык канәгатьсезлек белдерә башладылар. Аларның сукрану-шыңшулары һәрьяктан ишетелде:

– Мондый ныгытманы тупка тотмыйча алып буламыни?

– Безне ефәк-бәрхетләр белән төрергә кем вәгъдә бирде?! Бүген безгә тары боткасы гына тәтеде, болай булса, аягыңны сузарга да күп вакыт кирәкмәс.

– Тиздән яз җитә, юллар баткакка әверелә, без монда озакка тоткарланып калачакбыз.

Сафагәрәй ханга да, ниһаять, уңышка ирешә алмаганын танырга һәм Казан әргәсеннән кире чигенергә туры килде. Юлы Нугай тарафына иде. Әмма, Мангыт[2] тирмәләре тезелешеп утырган җирләрдәге шәһәрчек һәм авыллар аша үтәр алдын-

[2] Мангыт – мангыт нәселеннән булган Идегәй варислары хакимлек иткән дәүләт Мангыт йорты (яки Нугай олысы) дип аталган. Ул хәзерге Казакъстанның көнбатышындагы җирләрне, Идел белән Җаек арасын биләгән (тәрҗ. иск.).

нан, хаҗитарханлылар, югалтуларын кире кайтару максатында, тирә-юньдә очраган һәммәсен таладылар да киткәндә, эз югалту өчендер, ут салып уздылар. Сафагәрәй моңа бик итмәде. Яугирләр үзләренә тиешле өлешне алырга тиеш, дип санады ул һәм урыслардан соң тагын бер кат бу талау-яндырулар киребеткән казанлыларны акылга утыртыр кебек иде.

Иленнән, тәхетеннән сөрелгән ханны дала кинәт кенә килгән язы белән каршы алды. Әмма табигатьнең уянуы да Сафагәрәйнең күңелен күтәрмәде, Сарайчыкка[3] таба һәр адымы авырлык белән генә бирелде. Иң элек үзенең горурлыгы һәм тәкәбберлеге җанын-бәгырен изде. Менә кире борылып китә алса һәм үзсүзле бәкләр бәге белән очрашырга туры килмәсә иде! Тик Сарайчыкта Сөембикә яши, ә бу хатын аны буйсынмас Казанга караганда да ныграк тартып тора. Көтәме икән кайчандыр аңа карата мәхәббәт утында янган ханбикә, иренең хаталарын һәм уңышсызлыкка дучар булуларын кичердеме икән? «Әгәр дә мәгәр Сарайчык мине өнәмичә, каш җыерып кабул итсә, хатыннарымны һәм балаларны алам да Кырымга – Сәхибгәрәй агама кайтып китәм. Туган җирем мине дөньяга бар итте, ул миңа бу юлы да куәт бирер; кулымнан киткән ханлыгымны барыбер кире кайтарырмын!» Сафагәрәй шул сүзләрен, балачакта ятланган дога кебек, эченнән гел кабатлый бара иде. Шул ук вакытта, боларның барысы да узып китәр дә бәкләр бәге Йосыф киявен хәерхаһлы кабул итәр әле, дип өметләнде.

Ә бу көннәрдә Казан яңа ханга тугрылыклы буласына ант эчте. Бөек Мәскәү кенәзе аларга кайчандыр үзләре куып җибәргән Шаһгалине янә хаким итеп кайтарып бирергә карар кылды. Башта каһәрләнгән, аннары патша галиҗәнаплары ярлыкаган адәмчеккә инде кырык яшь тулып узган иде, әмма яшүсмер чагында кыяфәте һәм акылы нинди булса, Касыйм «малае» бик аз үзгәргән икән. Ул Казан агайларына тагын да сөмсезрәк булып күренде, шешенгән һәм юанайган хәрәм агасын хәтерләтте. Мондый зәгыйфь-гарип хаким, чибәр Сафагәрәй белән чагыштырганда, әлбәттә, бер чүп чүмәләсе генә иде, әмма, рус хөкүмәте белән тынычлыкның иң ышанычлы дәлиле булыр әле, дигән өмет белән, Казан аны түземсезләнеп көтте.

Шаһгали үзе яхшы хәбәрне иртә яздан алган иде. Касыйм ханы, йөзен Кыйбла ягына төбәп, намазлыгына тезләнде. Озак һәм тырышып, белгән догаларын укыды. Шаһгали бу максатына егерме биш ел буе килде бит, егерме биш ел! Җен ачулары чыккан казанлылар аны, әле бөтенләй яшь егетне, ханлыктан куалап җибәргәннән соң, аның бөтен хыялы тәхетне кире яулап алу иде. Хәзергә кадәр ул Мәскәү кенәзләренең ышандыруларына һәм татлы вәгъдәләренә алданып яшәде, ләкин, чибәр кәләш кебек, төшләргә кереп ымсындырып-ашкындырып торган Казан һәрвакыт кулыннан шуып чыга торды, ә күргән төшләре, уянып китү белән, төтендәй тарала барды. Шаһгали инде, үз язмышын үзе хәл итү өчен – Казан, әгәр анда килешеп булмаса, Нугай белән астыртын сөйләшүләр алып барырга тотынган иде. Берзаман, Мәскәү шымчылары уяулыгы белән, аның бу эшчәнлеге фаш ителде, зур гөнаһ саналды, һәм, әле борын асты да кипмәгән бөек кенәз исеменнән, тыңлаусыз «сынок»ны, сак астына алып, Белоозерога[4] сөрергә боердылар...

Атлы гаскәр Казан иленең очсыз-кырыйсыз юлларыннан бу юлы ашыкмыйча гына тыныч сәфәрен дәвам итә. Шаһгали иң алдагы атның иярендә уңга-сулга чайкалып бара, артыннан ияргән Палецкий һәм Бельский дигән кенәзләр белән хәзер аның

[3] Сарайчык – шул исемдәге вилаятьнең башкаласы булган борынгы шәһәр, нигез ташлары хәзерге Казакъстан җирендә (тәрҗ. иск.).

[4] Белоозеро – Белое озеро дигән күлдән һәм Мәскәүдән ерак түгел борынгы рус шәһәре, хәзерге атамасы – Белоозерск. Шул тирәдә үк Тула өлкәсенә керүче Белоозеро саласы да бар икән. Һәрхәлдә, Шаһгалине авылга түгел, шәһәргә сөргәннәрдер (тәрҗ. иск.).

исәнләшәсе дә килми. Гомере өзелүдән һәм алда ни көткәненнән өркеп, «курчак хан» бүгенге көнгәчә Мәскәү патшасының түрәләре каршында куштан койрык, «татарчонок-шамакай» булды, аларга ярарга тырышты. Ләкин ул үзе шуларның барысын бергә әле ничек кенә күралмый иде! Бу нәфрәт тойгысы аның хәтерен үткәннәргә – моннан ун елдан артыграк булып узган хәлләргә гел кайтарып, җанын кыйнап-көйдереп торды... Шаһгалине Белоозерога олактырганнан соң, Касыймда аның якын һәм тугрылыклы кешеләрен кулга ала башладылар. Дистәләгән әмир, морза һәм угланнар гаиләләре белән бергә Тверь, Псков, Новгород, Орешек[5] һәм Кареланың[6] куркыныч җир асты куышларына ябылды. Псковта җәлладлар җитмеш өч кешене, җәзалаганнан соң, асып-буып үтерделәр. Һәлак ителгәннәрнең хәләл җефетләре язмышы да җиңелдән булды-мы икән?! Коточкыч суыкларда аларны яңа ачылган бәкеләргә куып төшерделәр дә көчләп чукындырдылар, бу шәфкатьсез гамәлләр өстендә Бөек Новгород һәм Псков владыкасы[7] Макарий үзе торды. Акылларыннан шаша язган татар ханымнарын – бәк һәм морзаларның тол хатыннарын – шунда ук православныйларга – сугышчылар-га, һөнәрчеләргә, кыскасы, коллыкка алырга теләгән һәркемгә өләшеп бетерделәр. Шаһгали Белоозерода өч ел буе кайгырып һәм үзе өчен өне китеп яшәде, төшләрендә аңа катыйльләр ишек шакыган кебек тоела, шулай саташып чыга иде. Әмма өнендә Газраилнең аны түгел, ә Җангалине[8] алып китүе мәгълүм булды. Шаһгали әлегәчә бертуган абыйсын бәхет баскан язмыш иркәсе дип саный иде. Инде бу хәл килеп тугач, әле сабыйлыктан чыгып җитмәгән кенәз Иван исеменнән Мәскәү белән идарә итүче Елена Глинская[9] Шаһгалине исенә төшерде. Аны сөргеннән чакырып алып, бөек кенәз катына алып керде, Казан тәхетен вәгъдә итте, әмма шунда ук көтелмәгән хәбәрләр ки-леп иреште: казанлылар ханлыкка үзләре теләгән Сафагәрәйне хаким итеп өлгергәннәр икән. Шаһгалигә янә кире чигенергә туры килде. Аның аягы ун елга Мәскәү бозынаябышып катты һәм шул газаплы көтү, ниһаять, менә монда – Казан ханлыгына илтүче язгы кояш астында җебегән-җепшегән юлларда тәгәрәлләнеп килә. Тагын бер көннән ул пайтәхеткә хуҗа булып керәчәк һәм тәкәббер, горур Казан түрәләре кабат аңа баш иячәк.

***

Кышкы йокысыннан уянып килүче Сарайчыкта Сафагәрәй авыр көннәр кичерде. Бәкләр бәге Йосыф тәхетеннән сөрелгән кияү балакайны башкаласында кабул итәргә риза булса да, мондый адымга бары тик кызы хакына гына барганлыгын ачыктан-ачык сиздерде. Күңеле катуы, рәхим-шәфкать күрсәтергә теләмәве шул дәрәҗәгә җиткән иде ки, ул Сафагәрәйгә хәтта Сөембикә белән күрешергә дә рөхсәт итмәде! Югыйсә, калган хатыннары һәм кәнизәкләре белән очрашуына каршы килмәде үзе. Нугай хакименең әмере буенча, Сафагәрәйне, гаиләсе белән бергә, бәкләр бәге сараеның иске чатына урнаштырдылар. Хезмәтчеләргә һәм хәрәм агасына, бу торакка әлегә ярап торырлык төс-кыяфәт бирү өчен, байтак тир түгәргә туры килде. Сафагәрәйнең нәфрәтле һәм үпкәле карашы дым тарткан диварлар, кайчандыр затлы-зиннәтле булып та, инде күптән ватылган-кителгән тәрәзәләр буйлап шуышты. Салкын баскычта ул почмакка поскан әллә кайчангы пәрәвез җепләрен күрде, караңгы коридорларның төрле төшен күгәрек басканга, алар да ямьсез-шыксыз хәлгә килгән иде. Хәрәм агасы аңа бирелгән

---

[5] Орешек – новгородлылар нигез салган борынгы рус ныгытма-шәһәре, хәзерге исеме – Шлиссельбург. Андагы төрмәдә Петр патшаның беренче хатыны Евдокия, Александр Ульянов, үлем җәзасына хөкем ителгән башка мәгълүм шәхесләр дә утырган (тәрҗ. иск.).

[6] Карела – Новгородны шведлардан саклаган шәһәр-ныгытма, аның Корела дип тә язалар (тәрҗ. иск.).

[7] Владыка – чиркәү хуҗасы – архиерий *(тәрҗ. иск.)*.

[8] Җангали – 1532-1535 еллардагы Казан ханы *(тәрҗ. иск.)*.

[9] Елена Глинская – Литва кенәзләре токымыннан, Мәскәүнең бөек кенәзе Василий IIIнең икенче хатыны, Иван Грозныйның анасы (тәрҗ . иск.).

бүлмәләрнең ишеген ачу белән, аны көтеп торган хатыннары, бусагадан узуына ук, сабырсызланып, каршысына ташландылар, баш иеп, кулларын үптеләр. Җәгъфәр ага аларның яхшы хәбәрләр ишетергә теләүләрен бик аңлый, әмма берничек тә шатландыра алмый, шунлыктан йөрәге әрни иде. Сафагәрәй исә, хатыннарының нигәдер сөенеп чыркылдашуын, үзенә бөтенләй кагылмаган төсле бер колагыннан кертеп икенчесеннән чыгарып дигәндәй, битараф кыяфәт белән тыңлаган булды да аларның бик тырышып буялган-бизәнгән чырайларына салкын карашын сирпеп кенә узды. Болар, әлбәттә, хакимнең җылы куенына керергә әзерләнеп бизәнгәннәр инде, әмма күз камаштыргыч купшы киемнәре мондый мескен шартларда бигрәк тә шыксыз булып күренә иде шул. Фәйрүзәдән калганнарның барысын да читкә этәреп, хан аны гына үз янына дәште, якты күзләренә бакты:

– Фәйрүзә, син ябыгып киткәнсең.

Бикә барысыннан да арттарак тора, вакыт-вакыт кулъяулыгына йөткерә иде. Ул, нindидер гаебе бар сыман, алтын түсендәге чәчләре генә бизәп торган башын аска иде:

– Чирләп киткәнгә инде бу, хаким, узгынчы булсын.

– Ә ханбикәне кайда урнаштырдылар? – Сафагәрәйнең тавышы калтырап куйды, шуңа күрә Фәйрүзә дә аңардан күзләрен яшерергә мәҗбүр иде, телен әйләндереп сүз катарга, җавап кайтарырга курыкты. Бичәнең һәрвакыт шатлыклы, сөйкемле карашы беркайчан да булмагандай сүнгән, ханга инде, таләпчән кулы белән иягеннән тотып, аның башын күтәрергә һәм үзенә каратырга туры килде.

– Бу тискәре картлач кайда яшереп тота соң кызын?! Сезгә дә аның белән көрәшергә мөмкинлек бирмәүләренә һич ышанмыйм.

– Ханбикә хаста иде, – дип әкрен генә җавап кайтарды Фәйрүзә, – соңгы араларда аның янына табибларны гына керттеләр. Бәкләр бәге аны артык борчылудан сакларга тырыша. Ул хәтта Сафагәрәйнең хатыннары да кызының тынычлыгын алырлар дип курка. Нугай хакиме аны шулхәтле дә яратыр икән!

Сафагәрәй, тешен кысып, кече хатыны алдында чын тойгы-хисләрен сиздермәс өчен, тәрәзә катына китте:

– Башкалар янына барчы, Фәйрүзә, минем үземнең генә каласым килә.

Ул әле озак көннәр буена, бәкләр бәгенең ачуы басылганчы һәм аның күңелендә рәхим-шәфкать уянганчы, шунда яшәргә туры килүе ихтимал булган бүлмәне аркылы-торкылыга атлап узды. Аның, билгеле, хәрәмханәсен алып, Сарайчыкны ташлап китәргә дә мөмкинлеге бар-барын, тик Сөембикәне монда калдырыргамы?! Юк! Тормышы, бөтен язмышы Күк һәм Ходай тарафыннан аңа бүләк рәвешендә күптән теркәлеп куелган булса да, ул язу ничектер Тәкъдир китабыннан җуела калса, бу – акылга сыймаслык хәл ләбаса! Әлеге хатын аның бәхет бөтие, үзен хаким итеп тоярлык күңел йолдызы булды. Казан тәхетендә бары тик ул гына утырырга лаеклы, Сафагәрәйнең сөеп туймаслык бердәнбер гамәл фәрештәсе иде. Сөембикә дә аларны бәйләгән кайнар хисләрне онытмагандыр әле; бәс шулай икән, аның белән көрешәсе килгән көнне сабыр гына көтәргә туры килә. Ханбикә бәкләр бәгенең киребеткәнлеген җиңел генә сындыра алыр: ул бит юкка гына Йосыф кызы түгел! Сөембикә бу шыксыз сарайда барыбер бәхетле була алмый. «Ул да Казанның купшы хозурлыгын юксынадыр, – дип уйлады Сафагәрәй. – Сарайчык шултиклем күңел кайтаргыч кала, бирэдә дистәгә якын бай йорт бармы икән? Ә сарай дигәннәрен ташка үлчим, дәһшәтле Аксак Тимер, кылычын айкап, әле кичә генә бу төшләрдән узган төсле». Әй! Сарайчыкка ялт итеп торган Казанның мәгърурлыгына яки зиннәтле, яшеллеккә-чәчәккә чумган Бакчасарайгамы соң тиңләшергә. Юк, Сөембикә Казанны сагынмый булдыра алмас, аз гына хәл җыйгач, аны – Сафагәрәйне дәшеп алыр да, ханлыкны кире кайтарырлык дәрманың бармы,

дигән кискен таләбен куяр. Ә ул, нугайларның җиңелү белмәс атлы гаскәре үз кулына керү белән, моңа ирешми калмас.

Хан очлаеп килгән тар тәрәзәләрдән шәһәргә күз салды һәм кайчандыр кәрваннар башкаласы булган, инде элеккеге шанын җуйган бу дала тоткынлыгында озак түзеп тора алмаслыгын аңлады. Моннан Бөек Ефәк юлы узган, бай кәрван-сарайларда кешеләр мәш килгән, базарлар шаулаган, дөяләр үкергән... Аксак Тимернең дөньяны яулап алырга күтәрелгән рәхимсез кылычы сәүдә юлларының шаулап аккан, гөрләгән елгаларын кисеп, тар инешләр генә калдырып киткән. Хәзер кайсы кәрван башы Сарайчык аша узарга батырчылык итәр икән? Зиһенсезләр генә моңа сәләтледер; хәер, андыйлар да бар бугай. Хан бу мескен шәһәрчектәге иске тирмә-йортларда сыеныр урын тапкан мосафир-юлаучыларны, сәүдәгәрләрне күргәләде, хәтта араларында аның күңеленә якын булган кырымлылар да очраштырды. Әлеге иртәдә, бәкләр бәгенең сараена барырга җыенып яткан чакта, Сафагәрәй тагын бер «бетле» кәрванның ачык капкалардан мышкылдап кереп барганын күзәтеп торды. Һичнигә дә исе китмәүчән дөяләрнең муенындагы шөлдерләр сагышлы чыңлый, алар артыннан үлмәс шигырь юллары да чәчелеп-ияреп барадыр сыман:

Әй, кәрванчы, зинһар, ашыкмачы,
Китә, җаным дөньясы китә,
Оча күкрәгемдәге йөрәк тә,
Оча ул ярымны эзләп читкә.

Сәгъди газәлләрен Сөембикә белән бергә еш кына укыйлар иде алар. Хискә тулышкан юлларда бакча һавасының хуш исләре көчлерәк аңкый кебек, шуңа да ул үбешүләр, үрелгән куллар иркәләшүе арасында гашыйклар аларны бер-берсенә пышылдап туя алмый... Ир ыңгырашып куйды, йөзен диварга терәде, юеш салкын таш шунда ук аны исенә китерде. Кияве мондый хәлгә тарыганына Йосыфның шат булмавы баш китәрлек хәл түгел, әмма ул, Сафагәрәй, ханбикә белән күрешү котылгысыз ихтыяҗ икәнлегенә картлачны ничек тә ышандырыр. Алтын бәһасенә торырлык көннәр уза лабаса, Сафагәрәй шәһәр тирәсенә елышып кыш чыккан нугайлыларның инде тирмәләрен җыярга тотынганнарын үзе күреп тора. Тиздән бәкләр бәге дә җәйге көтүлекләргә китеп барыр. Ә аңа ни көтәргә кала соң – яңадан кыш җиткәненме? Хан, тәвәккәл адымнар белән, ятагыннан чыкты, үзен алда көтүе ихтимал түбәнсетүләргә нык торырга әзерләнеп, тиз-тиз генә сарай кичүләреннән узды. Тик, бәкләр бәгенең ишек төбенә якынлашуга ук, нөкәрләр аның алдында озын саплы кечкенә балталарын[10] кисештереп куйдылар. Сакта торучыларның өлкәне, Сафагәрәйгә каршы чыгып, тиешле хөрмәт тә күрсәтмичә, салкын гына баш игән булды, ләкин Сафагәрәй, йөрәген учына кысып, дәрәҗәсен төшермәгән төстә, аңа:

– Әфәндегә тапшырыгыз, Казан ханы аның белән хәзер үк очрашырга тели, – диде.

Яугирның йөзе чалышайды, әмма хуҗасының киявенә каршы сүз катарга базмады. Сафагәрәйне гаҗәпкә калдырып, ул шунда ук борылып чыкты да:

– Бәкләр бәге сезне өйләдән соң Тәхет залында көтә, – диде.

Урысчадан ***Мөдәррис Вәлиев*** *тәрҗемәсе* ■

[10] Авторда – алебарда (тәрҗ. иск.).

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

ЭТРУСК ТЕЛЕ НИНДИ ТЕЛ?

Этруск теленең серен ачу омтылышы биш йөз ел буе дәвам итә. Шул вакыт эчендә 11 меңнән артык язма истәлек табылган, тик аларның сере әле ачылып бетмәгән, диләр. Дөрес, галимнәр этруск язуларын күптән инде укыйлар, тик мәгънәсен аңлау гына зур кыенлыклар тудыра икән. Табылган язуларның кайберсе бер сүздән генә тора, ике-өч сүздән һәм дистәгә якын, аннан да артык сүзләрдән торганнары да бар. Этрускларның алфавиты билгеле, шул хәрефләрне өйрәнеп, этруск язуларын уку алай ук кыен эш түгел, тик укылган текстның нәрсә аңлатканын аңлау гына авыр. Шулай да хәзерге көндә галимнәр берничә йөз этруск сүзенең мәгънәсен ачуга ирештеләр. Кайбер галимнәр этруск алфавиты грек алфавиты йогынтысында барлыкка килгән, дигән фикердә торалар. Әмма моның белән килешмәүчеләр дә шактый. Бу мәсьәләгә без алда әле киңрәк тукталырбыз. Этруск алфавиты тора-бара кайбер үзгәрешләр дә кичергән. Римлылар өстенлек алганчыга кадәр, этрусклар Италиядә иң мәдәниятле халык булган һәм алар аша язу культурасы күршедә яшәгән башка халыкларга да көчкән яисә йогынты ясаган.

Этруск язуларының бер-берсеннән бераз аерылып торганрак төрле вариантлары да бар икән. Язуларның авторлары бер үк дәрәҗәдә белемле булмаган, аннан соң язулар төрле чорда, төрле төбәктә язылган. Төрки телләрдә диалектлар булган кебек, этруск телендә дә галимнәр диалектларга хас үзенчәлекләр булуын ачыклаганнар. Кайвакытта берәр хәрефне төшереп калдыру яки кыскартып язу да булгалаган икән. Этруск телен белмәү бер хәл, сүзләрнең төрлечә язылуы да телне өйрәнүне, сүзләрнең мәгънәсен ачып салуны катлауландыра икән. Мәсәлән, этрускларда Вел дигән кеше исеме еш очрый. Татарлар арасында да Вил исемле кешеләр бар. Шунысы кызык, этруск язма истәлекләрендә бу исем әле «Вл», әле «Ве», әле «Вел» дип языла икән. Менә шушы кечкенә генә мисал да этруск язмаларын уку һәм мәгънәсенә төшенүнең никадәр кыен икәнен күрсәтеп тора. Аннан соң язмадагы сүзләрнең кушылып язылуы, һәр очракта да сүзләрне аера торган ике нокта яки кыска сызыкның куелмавы да зур кыенлыклар тудыра. Шулай ук этрускларда сүздәге сузык авазларны төшереп калдыру, бары тик тартык авазларны гына язу гадәте дә булган. Табигый, белмәгән телдә андый сүзнең мәгънәсенә төшенү гадәттән тыш кыен эшкә әверелә. Менә шул сәбәпле, этруск телен аңлап уку процессы бик акрын бара.

Гасырлар буе, Яңарыш чорыннан башлап, этруск теле белән кызыксынган кешеләр бу телдәге язмаларны бөртекләп җыя килгәннәр. Язулар диварларга, төрле тормыш-көнкүреш әйберләренә, вазаларга, савыт-сабага, бронза көзгеләргә, таш табутлар капкачына, сөякләргә, чирәпкә, басуда ызаннарны билгеләү өчен куелган махсус ташларга һ.б. әйберләргә язылган. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтик, түбәләрне яба торган чирәп-черепицаны да этрусклар уйлап тапкан һәм чирәп утта яндырылганчы, аңа төрле сүзләр дә язып куя торган булганнар. Этрусклар текстны уңнан сулга язганнар, шулай ук җөмлә ахырында нокта да куелмаган.

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 7 нче санында.

*Фәнни-популяр тарихи бәян.

Кайбер галимнәр этруск алфавиты Эгей диңгезенең көнчыгышындагы Эвбея утравы греклары йогынтысында барлыкка килгән, дигән караштa торалар. Әгәр дә без Эгей диңгезе картасына күз салсак, Грециянең Эвбея утравының Кече Азиядәге Лидия патшалыгына капма-каршы торуына игътибар итмичә калмабыз. Диңгезнең бер ягында мөстәкыйль Эвбея, икенче ягында Лидия патшалыгы урнашкан. Аларның шул рәвешчә урнашуына карап, йөзгә-йөз урнашкан шушы ике ил арасында сәүдә итешү, шул исәптән мәдәни багланышлар да булгандыр, дигән фикергә килергә мөмкин. Һәм шушыларга таянып булса кирәк, кайбер галимнәр Лидиядә алфавит греклар йогынтысында барлыкка килгән, дигән фикерне үткәрмәкче булалар. Әмма тарихны тикшерә башласаң, бөтенләй киресе килеп чыга икән.

Кече Азиянең төньягында ике күрше дәүләт – Фригия белән Лидия урнашкан. Б.э.к. VIII гасырда Гордий һәм аның улы Мидас патшалар хакимлек иткәндә Фригия бик каты ныгып китә һәм көчле дәүләткә әверелә. Ул чорда Лидия Фригия патшаларына буйсынган хәлдә яши. Бу чорда Фригия бай илгә әверелә. Эш шунда ки, Мидас патша заманында анда дөньяда беренче тапкыр алтын акча суга башлыйлар. Лидиядәге Пактол елгасы алтынга бик бай була. Лидия патшалыгында алтын чыганаклары шулкадәр күп була ки, грекларда Мидас патша турында хәтта тарихи риваять тә барлыкка килә. Имеш, ул кагылган һәр нәрсә алтынга әверелә бара икән. Тик бу хәл Мидас патша өчен чын фаҗигагә әверелә. Аның кигән киеме дә, кулына алган ризыгы да, аяк киеме дә, тәхете дә – барысы шундук алтынга әверелә барган. Мидас патша бу афәттән бары тик Дионис-аллага мөрәҗәгать итеп кенә котылган. Бу илдә шулай ук көмеш, тимер, бакыр һәм цинк та чыгарылган. Кыскасы, металлургия Лидиядә зур үсеш ала һәм бу байлыкларның бер өлеше Фригиягә озатыла.

Б.э.к. VII гасыр уртасына кадәр Фригия Грециядән һөнәрчелек товарларын кертми, бары тик үз товарларын гына грекларга илтеп сата. Шунысы кызык, б.э.к. VIII гасырдан башлап, Фригиядә җитештерелгән әйберләр Борынгы Грециядә күпләп табылган. Ә грекларның Фригия белән сәүдә итүе сизелмәс дәрәҗәдә булган. Бу дәвердә Фригия мәдәни яктан да алга киткән. Шулай ук грекларның һәм соңрак римлыларның да Фригиядән күп казанышлар үзләштерүе ачыкланган, дип язалар. Мәсәлән, биналарның түбә кырыен (фризын) төрле төсләр белән бизәү, диварга эленә торган затлы келәмнәр туку, алтын җепләр белән киемнәр чигү, музыка кораллары, үзенчәлекле көйләр, ике көпшәле флейта һәм кифара (лираның бер төре).

Бу хакта галимнәр фикерен тыңлап карыйк: «Грекларның Фригиягә ясаган йогынтысы турында сүз алып баруы кыен <...> Әмма б.э.к. VIII гасырдан алып фригиялеләр һәм греклар бер үк алфавиттан – чын алфавиттан файдаланганнар. Бу алфавит тартык авазларны гына түгел, сузыкларны да чагылдырган. Беренче карашка ул б.э.к. I меңьеллыктагы финикиялеләр язуына бераз якын тора кебек; тик башка (шул исәптән грекларныкы да) Кече Азия алфавитларына, ягъни Лидия, Кария, Ликия һ.б. илләр алфавитларына ул бөтенләй охшамаган, дип әйтергә мөмкин...» (История Древнего мира. Расцвет древних обществ. М., 1983. – С.61).

Бу хәл нәрсә турында сөйли соң? Китерелгән өзектә сүз Фригия патшалыгының чәчәк аткан чоры турында бара. Ул чакта Лидия шушы дәүләткә буйсынган. Әйтелгәнчә, бу чорда Фригиянең Борынгы Греция белән багланышлары юк дәрәҗәсендә. Бай һәм көчле Фригиянең грекларга исе китми, алардан берни кабул итми. Бердәнбер уртак нәрсәсе – алфавит икән. Әмма Фригиядән көньякта урнашкан Лидия, Кария, Ликия һәм башка дәүләтләрдәге алфавит бөтенләй үзгә булган. Ни сәбәпле? Без бу дәүләтләрдә яшәгән төркиләрнең үз алфавиты булган, дигән фикердә торабыз. Бу очракта сүз б.э.к. VIII гасырдагы вазгыять турында бара.



Цере шәһәре порты Пиргида табылган этрускча язылган алтын пластинка

Инде тирреннарга әйләнеп кайтыйк һәм сүзне дәвам итик. Әгәр дә б.э.к. VIII гасырда Кече Азиядә урнашкан Лидия һәм башка дәүләтләр алфавитны греклардан да, финикиялеләрдән дә кабул итмәгән икән, димәк, тирреннарның, үз ватаннары Лидияне калдырып, яңа ватан эзләп, озын һәм хәтәр юлга чыгып киткән чакта үз алфавитлары булу бәхәссез мәсьәлә. Италиягә алар үз язу системасын булдырган халык сыйфатында килеп урнашканнар. Галимнәрнең этрусклар Италиягә килеп урнашканнан соң алфавитны греклардан кабул иткәннәр дигән сүзе дөреслеккә туры киләме соң? Алар, традициягә яраклашып, этрускларга грек алфавитын тагалар түгелме?

Италиягә килеп урнашып, анда бер гасыр вакыт эчендә 12 шәһәр-дәүләт конфедерациясе төзегән, авылларда яшәүче латиннарга Рим шәһәрен һәм дәүләт төзеп биргән этруск халкының үз язу системасы, алфавиты булмаганмы? Бу халык әле Лидия патшалыгында яшәгәндә үк матди һәм рухи байлык туплаган, металлургияне яхшы үзләштергән, матур биналар төзи белгән, шуңа күрә яңа җирдә – Италиядә ул беренче гүзәл цивилизация төзүгә ирешкән. Башка халыкларга үрнәк һәм остаз булган.

Без алдагы бүлекләрдә этрусклар Римның остазлары булуы хакында күпмедер мисаллар китердек. Инде латин алфавитының барлыкка килүе мәсьәләсенә дә тукталып үтик. Урта гасырларда фән һәм дин теленә әверелгән латин теле яулап алынган халыкларга ул телне көчләп тагуда зур роль уйный. Әмма римлылар латин алфавитын үзләре уйлап тапканмы? Бу мәсьәләдә француз этрускологы Жан-Ноэль Робер фикеренә колак салыйк. Ул менә нәрсә яза: «С («Ц» дип укыла) хәрефенең өченче урында торуы латиннарның алфавитны греклардан түгел, этрусклардан кабул итүе турында сөйли» (Ж.-Н. Робер, 217).

А.И.Немировский да этрусклар алфавитының күрше кавемнәр тарафыннан



Гасырлар дәвамында үзгәреш кичергән этруск алфавиты

кабул ителүен билгеләп үтә. «Италиядә этрускларның колонияләре барлыкка килү аларның алфавиты таралуга китерә. Этруриядән читтә урнашкан Лацийда (латин кабиләләре яшәгән өлкә. – *С.Ш.*) да иң борынгы этруск язулары табылган (Пренесте, Фалерия, Поджо-Соммовилла, Рим, Сатрик шәһәрләрендә). Этрусклар тарафыннан колонизацияләнгән Кампаньяда иң борынгы этруск язулары Понтеканьянода табылган кара төстәге савыт-сабаларда күренә һәм алар б.э.к. VI гасырның беренче чирегенә туры килә, ә Капуя, Нола, Калес шәһәрләрендә табылганнары б.э.к. 550-450 елларга карый. <...> Төньяк Италиядә исә этруск язулары Фельзина (Филсинә), Спина, Адрия һәм Марцаботто шәһәрләрендә табылган (Нем., 72).

Галимнәр күптән инде этруск теленең һинд-аурупа телләре гаиләсенә кермәвен ачыклаганнар, чөнки һинд-аурупа телләре аша этруск теленә ачкыч табу уңышка китермәгән. Этруск теле нинди тел соң?

Беренчедән, аның агглютинатив тел икәне ачыкланган. Агглютинатив телләрдә сүзнең тамыры беркайчан да үзгәрми. Сүз тамырына суффикслар, кушымчалар өстәү юлы белән генә яңа мәгънәләр барлыкка килә.

Икенчедән, этруск телендә, флектив телләрдәге кебек, сүзнең тамыры алдына префикслар, предлоглар куелмый. Аннан соң этруск телендә җенес-род төшенчәсе юк. Аның бу сыйфатлары төрки телгә хас үзенчәлекләрне чагылдыра һәм, моннан чыгып кына да инде, этруск телен күпмедер үзгәреш кичергән төрки тел дип санарга мөмкинлек бирә, дип әйтергә мөмкин.

Этруск телен өйрәнгән Аурупа галимнәре, мәсәлән, бу тел бер генә телләр гаиләсенә дә керми, үзе бер аерым тел, дигән карашта торалар. Алар арасында Австрия галиме В.Бранденштейн гына этруск телендә төрки сүзләр катламы булуга игътибар итә. А.И.Немировский исә, этрускларның этногенезы гаять катлаулы

булганлыгына басым ясап, бу телне катнаш тел дип саный. «Безнең аңлавыбызча, халыкның формалашуы мәсьәләсе – ул барыннан да бигрәк этник компонентларның формалашуын ачыклаудан гыйбарәт. Ә инде этрусклар мәсьәләсенә килгәндә – бу очракта төрле чорда Италиягә килеп урнашкан пеласк һәм тирреннар күздә тотыла, әмма алар күпмедер вакыт ут күршеләр булып яшиләр, соңрак кушылып китеп, этруск халкын барлыкка китерәләр. Буталчыклык килеп чыкмасын өчен, кисәтеп куябыз, чөнки грек авторлары Эгеидада (Эгей диңгезе бассейнында. – *С.Ш.*) яшәүчеләрне дә, этрускларны да тирреннар дип атаганнар. Без исә «тиррен» төшенчәсен Эгеидада яшәүчеләргә һәм Италиядә б.э.к. 800 нче елга кадәр тереклек итүчеләргә карата гына кулланабыз. Шушы датадан соң безнең өчен Италиядә тирреннар да, пеласклар да юк, бары тик этрусклар гына бар» (Нем., 16).

Галим менә шундый фикердә тора, этрускларны катнаш халык булган дип саный. Әйе, этруск теленә башка телләрдән дә сүзләр үтеп кергәндер, бу табигый хәл, тик галим әлеге агглютинатив телнең төрки тел нигезендә формалашуына игътибар итми.

Этрускларның тарихы һәм теле белән кызыксыну, бу халыкның серен ачарга омтылу татар зыялылары арасында да күзәтелә. Күренекле язучы Нурихан Фәттах 1990 елда басылып чыккан «Шәҗәрә» китабында, этрусклар мәсьәләсенә шактый тирән кереп, аларның тарихына зур урын бирде, бу халыкның төркилеген ачып салу өлкәсендә кётелмәгән күзәтүләре, табышлары белән уртаклашты, кызыклы фактлар китерде. Һәм, әйтергә кирәк, аның шушы фидакяр хезмәте бу мәсьәлә белән шөгыльләнү юнәелешенә этәргеч бирде.

Хәзерге көндә татарлардан Борынгы Ибериядә (Испания) яшәгән иберләр һәм Этрурия халкы этрусклар телләрендәге төрки сүзләр катламын ачу белән Уфа дәүләт авиация техник университеты галиме, күренекле этруск һәм башка борынгы төрки телләр белгече Фәрит Рәфкат улы Латыйпов бик уңышлы шөгыльләнә. Аның «Исследование протюркского языка методом ПЭКФОС. Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка». – Казань. ПЭКФОС һәм «Исследование этрусского и минойского языков на основе фоноэволюционной пратюркской гипотезы и камбинаторно-частотных методов». – Уфа. 1999, дип аталган һәм башка китаплары, бу темага багышланган күп санлы мәкаләләре басылып чыкты.

Ф.Р.Латыйпов 1977 елдан бирле этруск теленең килеп чыгышы, аның лексик составы, бу телдәге төрки сүзләр катламын ачыклау мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Бүгенге көндә галимнең фидакяр хезмәте шактый зур нәтиҗәләргә китерде, дип әйтергә мөмкин. Аның тарафыннан берничә йөз сүзне эченә алган «Этрускча-русча сүзлек» төзелде, шактый озын этруск текстлары рус теленә тәрҗемә ителде. Галим этруск телен өйрәнү, текстларны тәрҗемә итү мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләрдә катнаша, бу серле телдәге төрки сүзләр катламын ачыклау мәсьәләләре буенча дәлилле чыгышлар ясый. Шулай ук ара-тирә «Мәдәни җомга» газетасы битләрендә Чаллыда яшәүче Нәсим Илһам улы Сәхаповның да этруск теленнән тәрҗемәләре басылгалый. 2014 елда аның «Тюркские корни этрусского и итальянского языков» исемле мәгълүматларга бай китабы да басылып чыкты. Тикшерә торгач, ул итальян телендә гаять калын төрки сүзләр катламы булуын ачыклаган. Аның сүзләренә караганда, итальяннар үз телләрен этруск теленнән килеп чыккан тел дип исәплиләр икән. Әмма һинд-ауропа һәм ауропацентризм теориясе тел белемендә хакимлек итү сәбәпле, үз телләренең төрки тел нигезендә барлыкка килүен башларына да китерә алмаганнар (Н.Сәхапов. Күрсәтелгән хезмәт. 7 б.) Татар зыялыларының әлеге мөһим эшне дәвам итүләрен хуплап кабул итәргә кирәк. Бу юнәлештәге тикшеренүләр киләчәктә мул җимешләр бирер, дип өметләнергә нигез бар.

Хөрмәтле академигыбыз Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев тә, төрки-татар этногенезы белән күп еллар буе шөгыльләнгән зат буларак, шумер һәм этруск телләре мәсьәләләренә шактый тирән кергән галим. Әйтергә кирәк, әлегә татарлардан этруск теленең төркилеген ачып салу мәсьәләләре буенча зур эшләр башкарган беренче шәхес Садри Максуди кызы, зур галимә һәм җәмәгать эшлеклесе Адилә Айда булып тора. М.З.Зәкиев «Төрки-татар этногенезы» исемле саллы хезмәтендә Адилә Айданың фәнни эшчәнлегенә зур бәя бирә һәм аның хезмәтләре, этруск телендәге төрки сүзләр катламын ачып салу өлкәсендәге табышлары турында сөйли. Без, шул китапка мөрәҗәгать итеп, Адилә Айданың этруск теленә багышланган хезмәтләренә, фәнни карашларын яктыртуга бераз тукталып үтмәкче булабыз.

Адилә Айданың атасы профессор Садри Максуди да этруск теле белән кызыксынган. Кызы да әлеге мәсьәлә белән кызыксынып китә һәм берничә ел дәвамында моңа хәтле этрускология буенча басылып чыккан бик күп хезмәтләр белән танышып чыга. Шундый әзерлек белән үзе дә этруск теле мәсьәләләренә башы-аягы белән кереп чума, элекке авторларда булмаган һәм файдаланылмаган яңа материаллар туплый. «Шуларны анализлап, 1971 елда сорау формасында «Этрусклар төркме иделәр?» дигән французча китап бастырып чыгара. Бу китапның басарга бирелү көненнән алып, 16 ел буе тагын да өстәмә тикшеренүләр үткәреп, 1985 елда Адилә Айда Анкарада тагын французча «Этрусклар төрк иделәр» дигән китабын бастыра» (Зәкиев, 112).

Адилә Айда этрускларны бик борынгы төркиләр – прототүркләр (баба төркиләр) дип саный һәм дөнья фәнендә бу карашны яклаучылар ул гына түгел икәнне ачыклый. Әйтик, Исаак Тайлор, Барон Карра де Ваукс, В.Бранденштейн атлы галимнәр дә шушы караштa тора икән.

Галимә этруск теле мәсьәләләре белән шөгыльләнүен дәвам итә. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1987 елда Анкарада «Төркиләрнең элекке аталары» дигән китабын бастыра. Ниһаять, чирек гасырлык хезмәтен гомумиләштереп, Адилә Айда төрекчә зур бер хезмәт яза һәм ул 1992 елда Анкарада басылып чыга («Этрусклар (турксакалар) түрк иделәр. Гыйльми дәлилләр» (Зәкиев, 112).

Мирфатыйх Зәкиев үзе этруск телен прототүрк (баба төрки) тел дип санамый. «Чөнки прототүрк дип раслау – башка төрки телләр шушы телдән яралган икән дигән сүз булып чыга. Нәрсә булса да булсын, монысын киләчәк тикшеренүләр ачар, этруск телендә төрки эзләр тагын да ачыграк сакланган. Алай гына да түгел, б.э.к. 2 меңенче елларда ук (моннан 40 гасырлар элек) гадәти төрки тел формалашкан булган һәм ул этруск телен формалаштыруда этәргеч көч буларак катнашкан» (Зәкиев, 113). Кайбер мәгълүматларга караганда, хәзерге заманда төрки тел дип аталган агглютинатив тел тагын да ераграк дәверләрдә формалашкан.

Геродотның тарихи хезмәтләренең бер урынында: «Эллада элекке заманнарда Пеласгия дип аталып йөргән», – дип язуын әйтеп узган идек. Инде алдагы бүлекләрдә пеласклар турында укучыга беркадәр мәгълүмат та бирелде. Әйе, чыннан да борынгы грек кабиләләре Грециягә үтеп кергәнче, анда пеласк дигән халык яшәгән. Һәм ул греклар кысрыклавы аркасында үз ватанын ташлап китәргә мәҗбүр ителгән. Эгей диңгезендәге Лемнос һәм башка утрауларга таралып, Крит утравына, шулай ук этрускларга хәтле Италиягә дә килеп урнашкан. Пеласклар тарихы һәм теле этрускология фәнендә зур мәсьәлә булып тора. Әмма пеласклар һәм этрусклар теленең тугандаш, якын телләр булуы фәндә инде исбатланган нәрсә. «Бу этнонимны Адилә Айда *пела-сак* сүзләреннән ясалган, ди. *Пела* этнонимы тарихта төркиләрнең бер өлешен атаучы *булак* рәвешендә булып, Орхон язмаларында ул *булгак ~ пулгак*

формасында очрый. Шулай итеп, *пеласк* сүзе *булгак – сак ~ пулаг – сака ~ пъласак – пеласк* формаларында үзгәреш кичерә. <...> Димәк, *пеласклар* да төрки кавемнән килә булып чыга. Бу – бер чыганак.

Б.э.к. 2000 еллар элек Урта Азия кабиләләрен иранлылар *тур,* дип, җирләрен *Туран* дип атыйлар, алар хәзерге Төркия урнашкан Анатолиядә күренәләр һәм *турһан* дигән сүзне греклар *тиррен* дип йөртәләр. Адилә Айда гына түгел, барлык галимнәрнең дә исәпләвенчә, бу *тирреннар (турһаннар)* дә этрускларның элгәреләре итеп саналалар.

Турлар, Италиягә килеп җиткәнче үк *саклар* белән кушылып, *турсака* халкын формалаштыралар. Адилә Айда уйлавынча, *турсака* сүзе латин телендә *турски* этнонимына әйләнә. *Турски*дан *этруск* сүзе ясала» (Зәкиев, 114).

«...Адилә Айда китабының беренче бүлегендә этрусклар һәм төркиләр өчен дин өлкәсендә уртак дәлил – 74, хокук буенча – 1, сәнгатьтә – 1, ашамлыклар буенча – 1 охшашлык күрсәтә, аларга тулы анализ бирә» (Зәкиев, 114).

Үзебездән өстәп куйыйк: төзелеш-архитектура, каналлар ярдәмендә җирләрне сугару, су үткәрү өчен акведуклар төзү, хисаплау системасы, «рим цифрлары», мәгъдәннән тимер эретеп кою, римлыларда вәхшилек төсмере алган гладиаторлар сугышы, ике көпчәкле арбага җигелгән атларда ярышлар оештыру һ.б. өлкәләрдә этрусклар Римның остазлары булганнар. Этрускларның остазлыгы турында алда әле тагын сүз булыр.

«Китапның икенче бүлеме «Телгә мөнәсәбәтле дәлилләр» дип атала һәм анда автор этруск һәм төркиләр өчен уртак булган 74 охшашлык күрсәтә.

Адилә Айда иң элек, төрле галимнәрнең латин әлифбасы тарихы турындагы фикерләрен туплап, материалларны анализлап, шундый фикергә килә: этруск әлифбасы турсакалар яки пеласклар тарафыннан Урта Азиядән Италиягә китерелә, ул иске төрки әлифбасы була, шуннан, әкренләп, латиннарга латин әлифбасы булып керә. <...> Язу системасының кайбер үзенчәлекләре дә күктүркләрдә һәм этрускларда охшаш: мәсәлән, уңнан сулга язу, сузыкларны төшереп калдыру (*ртк* – артык, *блк* – балык (шәһәр). Соңгы үзенчәлек төрки тел белмәгән көнбатыш галимнәренә этруск язуларын дөрес укырга мөмкинлек бирми» (Зәкиев, 114-115).

«Адилә Айда борынгы төркиләргә һәм этрускларга уртак булган 40 сүз күрсәтә. Аның 15е, дини төшенчәләрне белдерүче буларак, латин теленә дә кергән, чөнки римлылар башта этруск динен кулланганнар һәм этруск теле аларда дин теле буларак та йөргән. Калган 25 сүз этруск һәм төркиләрдә генә очрый.

Менә ул уртак сүзләр: 1) *аугур ~ огур ~ угур* = шат, шатлык; 2) *һаруспекс (һаруспекс)* – латинча корбан ителгән хайван эчендәге әгъзаларны карау, моның беренче өлеше төркичә *карын* (эч) сүзенә барып тоташа; 3) *камиллус* (кам-иллус) соңгы өлеше латинча кушымча, төркичә *-чык*-ка туры килә, *кам* – төркичә, дин кешесе, шаман динендә сакланган; 4) *темплум* сүзе күкне, Тәңрене тану, андагы *ум* – латин кушымчасы, *темп* өлеше төркичә «тап – табыну», л – кушымча (табын – табыл?); 5) *атриум (атр – иум)* сүзендә *иум* – латин кушымчасы, *атр* = *ата-йер*, ягъни, «аталар җире», *атриум* – этруск иле. (Монысы белән килешеп булмый, чөнки *атриум* – йорт эчендәге учак яна торган зур бүлмә, түшәмендә ачыклык калдырылган. Бәлки учак янында аталар гына утыргандыр. – *С.Ш.*); 6) *макте* – Тәңрене мактау, корбан чалу, *мактау* фигыленнән; 7) *авил (аuил)* сүзе «йыл» мәгънәсендә, *аuил*да башта **а** төшеп кала, аннан соң – **у**; 8) *сеакулум* сүзендә соңгы *ум* – латин кушымчасы, *сеак ~ сук ~ сус* = йүз (якутча *сүс* – йөз – 100); *ул ~ аuил ~ йыл*; *сукауил = йуз йыл* ~ йөз йыл; 9*) саепе* – латинчасы «бик күп, бик еш». Якутчада *сыбы* – тыгын, тыгыз; 10) *аегер, аегр (ум)* – латинчада авыру мәгънәсен бирә, *авыр – агыр* – төрки тамыры; 11) *тога* –

латинча каплау, ябу, саклау, төркичә *тонг* = кием. Латиннар, **н** ны төшереп, *тог ~ тога* дип кулланганнар; 12) *куриа (кур-иа)* – сәяси яки дини оешма, корылма. Төркичә *кору* сүзеннән; 13) *курулис (курул-ис)* – дәүләт эшлекләләре җыены, *дәүләт* сүзенең эчтәлеге дә «кору» мәгънәсе белән бәйле. (Биредә «корылтай» сүзен дә өстәп булыр иде. – *С.Ш.*); 14) *куиритес* – коручылар, нигез салучылар; сүз тамыры – *кур (кор), -итһ* – итальянча – *чы, -ес* – күплек кушымчасы. 15) *балте* – итальянча «кылыч асылган билбау», төркичә: «билдә»; чагыштыр: «һәнҗәр әлдә (кулда), кылыч билдә»; 16) *атта* – бөек ата, *ата* сүзенең балалар әйтелеше *әттә*дән килә. Бу каралган сүзләр этрусклардан итальяннарга кергән.

Хәзер итальяннарга кабул ителмәгән, гректа һәм башкаларда очрый торган этруск-төрки сүзләрне карыйк.

17) *аис* – Тәңренең бер исеме яисә тәңреләрнең берсе. Төркиләрдә еш очрый торган Умай якутларда *айсит* дип әйтелә. *Айсит* сүзендә, *ит* – монгол күплеге, *аис* – Тәңре; 18) *апа* – ата, төркичә *аба*; 19) *(о) клан (оклан)* – оглан, огул; 20) *(у) лукһум-улуг* һәм *-ым* – тартым кушымчасы – *улугым, бөегем*; 21) *сек – кыз ~ кыс*, метатеза күренеше, ягъни **к** һәм **с**ның урыннары алмашынганлыктан, *сык ~ сек, секс*; 22) *млак (мулак)* – Тәңрегә бүләк, Тәңрегә багышлау, мулак – бүләк; 23) *сук* – дини гамәл, корбан бәйрәме; 24) *һинтһа – һ ~ с* күчеше аркылы уйгырдагы *сынты* – җир асты дөньясы белән бәйләнешле бер җир; 25) *бегое* – пәйгамбәр ханым, чуашта *пиге*, гадәти төркидә *бикә*, борынгы төркидә *пеке ханым* «мадонна» мәгънәсендә йөри; 26) *тһан* – Табити тәңресе белән сүз алмашу, *табыну (тап)* сүзеннән. 27) *сатһ* – **с** һәм **й** чиратлашуы аркылы *йат, кую, җирләштерү*. 28) *тһез* – ясау, төзү; 29) *зикһ* – язу, уйгырча *җиз*; 30) *туш* – үлеләрнең ял урыны, *төшерү* фигыленнән; 31) *кап* – савыт, кап, контейнер; 32) *һек* – кую, тезү, төркичә *эк ~ ик*; 33) *сак* – изге хәрәкәт яисә сыйфат, хөрмәт итү, саклау; 34) *фала* – күк (күк җисеме һәм төс). Иске төркичә *һала, һалла*; 35) *нак* – ник, ничек, ни өчен; 36) *ананк* – төркичә анынг, аның; 37) *ми – мини* – мине; 38) *вел* – ул (ол); 39) *таркуин (иус)* – төркичә *тарһан. Тар* – чәчү җире, *һан* – әфәнде, король, икесе бергә – «чәчү җире әфәндесе»; 40) *расена* – этрусклар үзләренә *расена* дигәннәр, ул *арсана* сүзеннән үзгәргән һәм *арс-ана* өлешеннән тора; *арс* – асыл, көчле, өстен, *ана* – ана. *Арс-ана* – төркиләрне барлыкка китергән төп, асыл ана. Күктүркләрдә дә *асена* (ашина) этнонимы булган (Зәкиев, 115-117).

Без М.З.Зәкиевнең «Төрки-татар этногенезы» китабыннан зур текст күчереп алып, укучыны бераз ялыктырдык бугай. Әмма бу кирәк иде. Хәзер укучы этруск теленең нинди тел икәнен күпмедер дәрәҗәдә күз алдына китергәндер. Әйе, ул «саф» төрки тел түгел. Этрускларның тарихы һәм этногенезы шактый катлаулы булганга, телләре дә төрле алынмалар белән чуарланган. Шуңа күрә, сүзләрнең мәгънәсенә төшенү өчен, бик зур тырышлык, гыйлем һәм вакыт таләп ителә. Этрускология белән шөгыльләнүче галимнәр бу телне нинди тел аша гына укырга тырышып карамадылар. Дөресен әйткәндә, б.э.к. гаять югары мәдәни һәм матди үсешкә ирешкән әлеге серле халыкны үзенеке итү өчен фәндә хәзер көрәш бара. Менә руслар да, этрускларның үз атамалары расена булуга таянып, этруск теленә рус теле аша ачкыч табарга тырышалар. (Ф.Р.Латыйпов этрускларның үз атамасы «тарк» булган, дигән фикердә тора. – *С.Ш.*) Алар этрускларга багышланган төрле тикшеренүләр алып баралар, китаплар бастырып чыгаралар. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, «расена» дигән сүз бөтенләй халык атамасы – этноним түгел. Галимнәр ачыклаганча, ул этруск сүзе «rasna», ягъни «дәүләт» дигән сүздән килеп чыккан икән» (Нем., 92). ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

ТАТАР ШЫРПЫ ЗАВОДЛАРЫ

Ләлә Мортазина

XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы – Россиядә сәнәгать һәм икътисад үсеше алга киткән дәвер. Нәкъ шушы чорда Идел буеның иң эре икътисади үзәкләренең берсе булган Казан шәһәре бөтен татар җәмгыятендә капиталистик мөнәсәбәтләр үсүдә зур роль уйный башлый. Татарлар арасында эшмәкәрлек белән шөгыльләнүчеләр – сәнәгать өлкәсендә эшләүчеләр, сәүдәгәрләр арта, сәүдә-сәнәгать фирмалары, компанияләре барлыкка килә. Бу күренеш бөтен Россия төбәкләре буйлап, шул исәптән Казан губернасында киң җәелә. Татар байлары капиталларын икътисадның төрле өлкәләренә кертеп, бер үк вакытта рухи якларны да кайгырталар – мәктәп-мәдрәсәләргә, мәчетләргә ярдәм итәләр, татар шәкертләренә белем алуда булышлык күрсәтәләр.

XIX гасыр ахырында Казан губернасында 3 меңнән артык вак завод һәм фабрика була, аларда 6 мең тирәсе кеше хезмәт куя. Нәкъ шушы чорда яңа төр сәнәгать тармагы – шырпы җитештерү үсеш ала. XX гасыр башында Казан һәм Чистай өязләрендә җитештерелгән шырпы Казан губернасын гына түгел, Россиянең башка өлкәләренә дә җибәрелә.

XIX гасыр ахырында Казан өязендәге татар авыллары – Мәмдәл, Юртыш һәм Абсабашта (барысы да хәзерге Биектау районына карый) шырпы фабрикалары ачыла. Халык телендә аларны завод дип йөрткәннәр. Шундый иң беренче заводка 1872 елда Мәмдәл авылы крестьяны **Хәсән Галиев (Мөхәммәтгалиев)** тарафыннан нигез салына[1]. Ул авылдан бер чакрым ераклыкта, халык өчен куркынычсыз урында төзелә, янында кое да казыла. Завод авыл халкы су ала торган күлгә фосфорлы кушылма калдыклары агып төшмәсклек итеп төзелә. Анда 16 кеше эшләгән.

Күп тә үтми, Казан артында шырпы җитештерү эше тагын да киңәеп китә. Мәмдәлдә, мәсәлән, 1884 елда **Ш.Ихсанов** тарафыннан тагын бер фабрика ачыла, анда барлыгы 22 эшче хезмәт куя. 1881 елда Юртыш авылында да заманы өчен шактый зур шырпы фабрикасы төзелә. Аның хуҗасы **Шакир Хәмит улы Хәмитов** була[2]. 1894 елда Юртыш авылында **Шәрәфетдин Вәлитов** тарафыннан тагын бер шырпы фабрикасына нигез салына[3]. Болар инде шактый заманчалаштырылган предприятиеләр була. Ш.Вәлитов фабрикасы, мәсәлән, ике өлештән гыйбарәт: берсендә товар җитештерелә, капларга тутырыла, икенчесендә контора урнаша. Аның җиллләтү өчен вентиляция җайланмалары, махсус юллыклары, фосфор саклау өчен идән астында-

[1] ТР ДА, 2 ф., 7 тасв., 96 эш, 1 б.

[2] Малеев А. Каталог спичечных этикетов Российской империи. 1860-1917. Ч.3. Губернии Гродненская, Иркутская, Казанская, Калужская, Киевская, Ковенская. С.13 // http://phillumeny.info/wp-content/uploads/2012/08/Maleev-Russia-1860-1917-part-3.pdf

[3] ТР ДА, 2 ф., 7 тасв., 1183 эш.

гы урыны була. 16 хезмәткәр эшләгән бу фабрика авылдан 150 сажин ераклыкта төзелә.

Шакир Хәмитов фабрикасында 41 кешегә эш урыны булдырыла. «Мөселман шырпы заводы» буларак дан казанган әлеге фабрика, Казан тирәсе авылларында гына түгел, Казанның үзендә һәм губернада да яхшы танила. XX гасыр башында татар җәмәгатьчелеге арасында әлеге «милли» предприятиене белмәгән кеше сирәк була. Габдулла Тукайның «Мин

Нәтиҗәдә, алар акционерлык җәмгыяте төзергә карар кыла. Ширкәткә мөмкин булган кадәр мөселманнарны гына кабул итеп, моңарчы дин кардәшләребез кулындагы бу заводны хуҗалар киләчәктә дә мөселман исемнәре астында калдырырга телиләр. Эшнең башында Шакир Хәмитовның инде зур тәҗрибә туплаган уллары Гариф белән Фатих тора.

шушылар илә милләтче» дигән әсәрендә әлеге фабриканың хуҗасын искә алуы да шул хакта сөйли. Ул, ярым шаяртып: «Шакир Хәмитов шырпысы илә генә тәмәке тартам», – дип, үзенең «миллилеген» раслый[4]. Дөрес бу шаяру гына, әмма әлеге сүзләр Шакир Хәмитов һәм ул җитештергән продукциянең татарлар арасында популяр булуы турында сөйли. Моннан тыш, Ш.Хәмитов иҗтимагый өлкәдә дә шактый билгеле шәхес була. 1907 елда Россия Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында, юрист Садри Максуди, Күлбаш мулласы, ахун Сафиулла Максудов, Мәмдәл имамы Вафа Зариповлар белән беррәттән, «Юртыш карьясенең спичка фабриканты Шакир Хәмитовның» да беренче турда Казан өязеннән вәкил итеп сайлануы билгеле[5]. Алай гына да түгел, Ш.Хәмитов фабрикасы Россия күләмендә дә яхшы билгеле булган. Россия империясенең 1884, 1890, 1897 елларга караган документларында (адрес-календарьлар, завод-фабрикалар исемлеге һ.б.) бу эшмәкәр турында мәгълүмат бирелү шуны раслый. Тагын шуны да әйтеп китү мөһим: әлеге сәнәгать оешмасы, моңа кадәрге шырпы фабрикаларыннан аермалы буларак, кеше сәламәтлеге өчен бик зарарлы булган фосфордан файдаланудан баш тарткан. Шуңа күрә аның дан-дәрәҗәсе дә арткан. 1914 елда киң җәмәгатьчелеккә төрки-татар дөньясы хәбәрләрен җиткерүгә зур игътибар биргән Оренбург газетасы «Вакыт»та Юртыштагы әлеге шырпы фабрикасы һәм аның тарихына багышланган зур гына мәкалә басылып чыга[6]. Бу мәкаләгә һәм Россия империясенең статистик документларына таянып, игътибарыгызга татар халкының XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы сәнәгать үсешендә зур әһәмияткә ия булган шырпы җитештерү тарихының бер сәхифәсе – Юртыш авылындагы Хәмитов шырпы фабрикасы турында бәян итәбез.

***

Билгеле булганча, бу фабрикага 1881 елда Шакир Хәмитов тарафыннан нигез салына. Баштагы 15 елда ул иске ысулда, бик зур кыенлыклар белән көн күргән, чөнки шырпының тартмасы да, күкерт һәм буяулар барысы да кул белән эшләнгән. Шунлыктан, шырпы аз җитештерелгән, аның бәясе кыйммәт, ә сыйфаты начар булган. 1890 елда биредә 45 кеше хезмәт куйган. Шакир әфәнденең үсеп җиткән уллары Фатих белән Гариф фабриканы үзгәртү, зурайту кирәклеген аңлаганнар. Үзара киңәшләшкәннән соң, гаилә әгъзалары, Россиядәге кайбер алга киткән зуррак фабрикаларда файдаланыла башлаган яңа ысулны өйрәнү өчен, ике туганның яше буенча зуррак булган Гарифны Россиядәге иң зур шырпы фабрикаларының берсенә җибәрергә карар кылалар. Шулай итеп, Гариф анда «малай» булып өч ел чамасы хезмәт итә, бик яхшы шырпы ясау алымнарын күреп, төрле ысулда эшли торган яңа машиналарны өйрәнә. Юртышка үзе белән берничә төрле заманча машинаны да кайтарта. Бу машиналар бик зур булмаса да, җитерштерү эшенә шактый җиңеллек биргән, нәтиҗәдә, товар күләме көннән-көн арткан. Элек бар нәрсәне кул белән башкарган вакытта көненә 5-6 тартма тирәсе шырпы эшләсәләр, яңа машина куйгач, 20-30 тартма җитештерә башлаганнар.

Биш-алты ел шул рәвешчә эшләгәч, машиналарны тагын да арттыралар. Бу юлы чит илләрдәге фабрикаларның тәҗрибәсе белән танышырга карар кылып, икенче улары Фатихны Австриягә җибәрәләр. Фатих, Австриягә барып, шундагы зур гына бер шырпы заводына хезмәткә керә. Андагы машиналар белән тиз арада гына таны-

[4] Тукай Г. Мин шушылар илә милләтче // Габдулла Тукай. Әсәрләр. Алты томда. Т.4. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2015. – Б.82.
[5] Казан өязендә сайлаулар // Йолдыз. – 1907. – 18 гыйнвар.
[6] Хәсән Манашев. Мөселманнарда һөнәр вә сәнәгать // Вакыт. – 1914. – 28 гыйнвар.

шып, Швейцариягә китә. Анда ул шул чордагы иң зур шырпы фабрикаларында була, яңа технологияләр, иң соңгы чыккан машиналарны өйрәнеп, беркадәр чит телләрне дә үзләштерә. Бу яңа машиналарның күбесе Германиядән китерелгән була. Фатих, үз фабрикаларына машина һәм кирәкле коралларны эшләтер өчен, Германиягә юл тота. Бирэдә шактый гына яшәп, төрле машиналарның корылу, урнаштырылу ысулларын өйрәнеп, үзләре өчен иң уңайлы дип тапкан техникага заказ биреп, Россиягә кире әйләнеп кайта.

Германиядән кайтарткан яңа машиналарны урнаштырганнан соң, Хәмитовларның заводы моңа кадәр күрелмәгән көч белән эшләп китә: элеккеге 20-30 урынына, көненә 70-80 тартма шырпы җитештерә башлый. 1912 елда фабриканың еллык кереме 10150 сум тәшкил итә. Аның рәсми офисы бу вакытта Казанның Печән базары урамында, Хәлиулла Хәйбуллин кибетендә урнашкан була[7]. 1914 елга Хәмитовларның шырпы фабрикасы 150дән артык кешене хезмәт урыны белән тәэмин иткән. Шулай итеп, заманында дистә кеше белән, кул хезмәтенә генә нигезләнеп эшли башлаган кечкенә генә предприятие шактый зур фабрикага әверелгән.

XX гасыр башында сәнәгать үсешенең алга китүе җитештерү предприятиеләрен яңартуны, үзгәртүне таләп иткән. Яңа шартларга туры килмәгәннәре ябылуга дучар булган.

Шулай итеп, 1913 елда Казан губернасында бары тик 3 кенә шырпы заводы үз эшен дәвам итә. Аның икесе – Чистай, берсе Казан өязендә булган[8]. Хәсән Манашев билгеләп үткәнчә, заманча фабрика һәм заводлар белән ярышыр өчен, моңарчы яхшы гына эшләп килгән предприятиеләрне тагын да киңәйтергә, тагын да зуррак машиналар алып, җитештерүне арттырырга кирәк. Моның өчен, әлбәттә, җитештерүгә салынган кертемнәрнең, капиталның мөмкин кадәр зуррак булуы шарт. Бу исә, әлеге чорда Европа илләрендә киң таралганча, ширкәт, акционерлык җәмгыяте төзүне таләп иткән. Файда-табыш алуны шул рәвешчә бермә-бер арттырырга мөмкин булганын Юртыштагы шырпы фабрикасы хуҗалары да яхшы аңлый. Нәтиҗәдә, алар акционерлык җәмгыяте төзергә карар кыла. Ширкәткә мөмкин булган кадәр мөселманнарны гына кабул итеп, моңарчы дин кардәшләребез кулындагы бу заводны хуҗалар киләчәктә дә мөселман исемнәре астында калдырырга телиләр. Эшнең башында Шакир Хәмитовның инде зур тәҗрибә туплаган уллары Гариф белән Фатих тора. Бу вакытта инде Шакир әфәнде үзе вафат була. «Вакыт» газетасы журналисты хәбәр иткәнчә, абыйлы-энеле ике туган, көчлерәк бер ширкәт ясап, зуррак акчалар керткәндә, һичшиксез, бу эшне тиешле югарылыкка куячаклар. «Ширкәткә кушылырга теләүчеләр булса, хәзердән үк хат белән яки күреп белешергә мөмкиндер», – дип тә өсти мәкалә авторы.

1918 елгы мәгълүматлар буенча, Шакир Хәмитов нигез салган шырпы заводы «Одинцов һәм Хәмитов» дигән исем астында пар машиналары белән эшләүче «Радий» ширкәтенә, акционерлык җәмгыятенә әверелә. А.Малеев китергән чыганакка караганда, 1919-1923 елларда ул «Восток» шырпы заводы буларак билгеле. ■

[7] Варзар В.Г. Список фабрик и заводов Российской Империи. 1912 г. – СПб. Типография Киршбаума (отделение). Составлен по официальным сведениям Отдела Промышленности Министерства Торговли и Промышленности под редакцией Варзара В.Е., 1912. – С.276 //http: istmat.info/node/26498

[8] Ермаков В.В. Акцизное дело в Казанской губернии в условиях первой мировой войны // Исторические, философские, политические и юридические науки, культурология и искусствоведение. Вопросы теории и практики. – 2012. – №7. – Ч.3. – С.61-64.

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

Большевизм уты астына

Кави Нәҗми

11. Беренче утырыштан соң

Күтелгән көн килеп җитә. 1928 елның җәй уртасында Ченәкәй фатирында Уфа белән Казан богемачылары очрашалар. Төн буенча киңәш бара. Киңәштән соң яшерен оешмага «Җидегән» дип ат кушыла. Буржуа әдәбиятының калдык көчләре, шул йолдызга карап, пролетариат гегемониясеннән качарлык юл эзлиләр.

«Җидегән» членнарына партиянең әдәбият фронтындагы җитәкчелегенә, көннән-көн үсеп баручы пролетариат әдәбиятына каршы бөтен чаралар белән көрәшү бурычы йөкләнә. Шуңа күрә алар пролетариат әдәбиятының тотнаклы көчләренә бу турыда эндәшергә дә куркалар. Юлаучы шагыйрь һәм язучыларның да зур гына өлешен үз сафларына чакырырга мөмкин тапмыйлар. «Җидегән»нең быелгы язга хәтле сиздертмичә эшләп килү сәбәбен әнә шуннан, составның бертөрлелегеннән һәм сыйнфый сизгерлегебезнең йомшаклыгыннан эзләргә кирәк.



Qajʙer iptəşlər həm alar tarafnnan ʙirlgən jaləƣƅş informatsiələrgə tajanucƅ MAPP ʙlən Ural APP qarşndaƣƅ tatar siksiələre kʙek ʙөten ʙer kolliktiflar TAPP ƣa qarşƅ ut actƅlar. Altmştan artƅq tatar, urƅs, cuaş jazucƅlarƅn tuplaƣan həm matur ədəʙiat frontndaƣƅ çirle kyrnşlər ʙlən, doşman ilimintlarƅnꞑ coƣşlarƅ ʙlən ajausƅz kөrəş alƅp ʙaroƣan ʙer ojşmaƣa qarşƅ ut jynəlderrlek nindi səʙəplər ʙar soꞑ? Mondƅj səʙəplər juq. Ləkin prolitariat jazucƅlarƅnƅꞑ ojşmalarƅna grupcacƅlƅq ciren joqtƅrroƣa tləycelər yz ʙaşlarnnan:

1. TAPP Cnəkəjgə matirial ʙulşlƅq kyrsətkən imeş.

2. „Çidegən“ TAPP nƅꞑ ʙorƅn tөsndə, TAPP nƅꞑ yz ecndə tuƅp yskən imeş. kʙek jaləƣan xəʙərlər taratƅp, kyz ʙujadƅlar. Nqlƅ tikşerylərdən soꞑ ul xəʙərlərneꞑ cpci ojdrma ikənnege ʙlnde.

Ufada da, Qazanda da, ʙaşqa urnnarda da tatar həm ʙaşqrt ʙurzuaziəseneꞑ qaldƅq kөclәre, tөrle tarmaqta zian kiterycе agintlarƅ ʙar. Sƅjnfi doşman prolitariat diktaturasƅna həm anƅꞑ ojşmalarƅna qarşƅ hөçymen tirritoriə ʙlən cikləmi. Tirritoriə jaqnƅ oƣna (anda da fəqət Qazannƅ oƣna) kyzdə totu, „Çidegən“celkkə qarşƅ ʙer front ʙulƅp kөrəşəse vaqtta, TAPP ƣa iꞑ əşəke pcraqlar ƅroƣƅtu—„Çidegəncelər“gə gnə çinllek tudƅra. Muə şuꞑar kyrə də—RAPP tan „Çidegən“ eşen tikşery өcen kilgən JURIN iptəş yz məqaləsndə gruppacƅlƅq nigzndəge coƣşiaroƣa qarşƅ nƅq otpor ʙirep uzdƅ. Xəzer ʙez Danʙastaƣƅ 35 mnnəp tatar şaxtjorlarƅ ismnnən, Qzƅl ərmiədən həm ʙaşqa urnnardan alnoƣan rizolytsiələrneꞑ də prolitariat jazucƅlarƅnƅꞑ ojşmalarnda gruppacƅlƅq tudƅrroƣa mataşu kʙek kyrnşlərgə iꞑ qatƅ udar jƅsaularƅn zur şatlƅq ʙlən əjtə alaʙƅz.

Bu momintlarƣa tuqtaluƅm ʙlən ʙrgə, min TAPP eşndəge kimcelklərne, jaləƣşlarnƅ tomalap qaldƅrroƣa tləmim. TAPPnƅꞑ yz rizolytsiəsndə də ul kimcelklər, jaləƣşlar ʙik acƅq əjtlgənnər. („Ataka“nƅꞑ 3 nce nomirnnan TAPP rizolytsiəsen qaraƣƅz).

15. Şəfqət kөtməsnnər.

Bez ədəʙiat frontndaƣƅ sƅjnfi kөrəşneꞑ ajruca kisken corƅn kicerəʙez. Bu kөrəş—saflarƅʙzdan qorƅc ʙrdəmnek sorƅj. Bu kөrəş—ədəʙi ojşmalarƅʙznƅ prolitariat həm kolxozlar qatlaunnan kytərlgən jaꞑa kөclər ʙlən noƣƅtuƅʙznƅ sorƅj. Bu kөrəş—prolitariat jazucƅlarƅn Marks-Linin idiələre ʙlən nqlap suƣarunƅ, alarnƅꞑ kvalifikatsiələren massa arasndaƣƅ kөndəlek eşkə, sotsializm tөzeleşenə ʙəjləp kytərүne, ʙu tөzeleş turnda ontlmaslƅq əsərlər tudƅruƅʙznƅ sorƅj.

Bu kөrəş—nəşriatlarƅʙznƅꞑ, ədəʙi ojşmalarƅʙznƅꞑ çitəkcelegen ʙol'şiviklaştƅruƅʙznƅ sorƅj.

Bu kөrəş—Stalin iptəşneꞑ XVI ncƅ sjzda əjtkənncə:

—„Cit həm sƅjnfi jөzen juƣaltqan ilimintlərne citkə sʙerep taşlap, tyʙənnən jaꞑa kөclər ysterrgə“

—„Kapitalizm ilimintlərenə ʙөten front ʙujlap kiꞑ hөçym alƅp ʙarroƣa“,

—„Massalarnƅ ileʙzdəge kapitalizm ilimintlərenə qarşƅ sƅjnfi ujaulƅq ʙlən suƣarƅp, rivolytsion aktiflqlarƅna moʙlizatsiə jasaroƣa“ quşa.

Bөten frontlarda çiꞑep kilyce Linin partiəse tarafnnan өsteʙzgə jөkləngən ʙu ʙөjek ʙurcnƅ ʙez tulƅsnca, ytərʙez, ʙarlƅq qiƅnnqlarnƅ, prolitariat diktaturasƅna, prolitariatnƅꞑ iksez-ciksez çiꞑşlərenə prolitariatnƅꞑ zur kөrəşlər ecndə tuƣan ədəʙiatƅna qarşƅ jynəlgən ʙarlƅq coƣşlarnƅ ʙatƅr admnar ʙlən taptap uzarʙƅz.

Sƅjnfi doşmanƣa həm anƅꞑ tөrle tөstəge agintlarƅna ʙzneꞑ jөrəklərdə əz gnə də qzƣanu tojƣƅsƅ ujanmas. Monƅ „Çidegən“ celər də, alarnƅꞑ dəslarƅ ʙuləƣan soltanƣəliefcelər də, ƣəjazcƅlar da islərndə nƅq totsnnar!

QƏVI NƏÇMI.

Ədəʙiat frontndaƣƅ kommunis kөclərne ʙrgə tuplap prolitariat ədəʙiatƅ gigimoniəse өcen kөrəşy—ʙzneꞑ ʙurcƅʙƅz!

8

«Атака» журналының «Большевизм уты астына» мәкаләсе басылган соңгы бите. 1930 ел

«Җидегән» программасының безгә билгеле булган өлешен, тагын да ачыграк сәяси вариант белән әйтсәк, түбәндәге пунктларга бүлгәләргә туры килә:

1. Пролетариат әдәбиятына каршы көрәшү, пролетариат язучыларын, шагыйрьләрен, матбугаттан, театрдан кысрыклап, укучыларны, тамашачыларны «җидегәнчеләр» монополиясенә алу.

2. Коммунистлар партиясенең матур әдәбият тармагындагы җитәкчелегенә каршы көрәш.

3. Марксизм тәнкыйтенә каршы көрәш.

4. Партиянең матур әдәбияттагы сәясәтенә дошманлык саклаучыларны «Җидегән»гә туплау.

5. Хатлар һәм башка юллар

Ахыры. Башы журналның 2019 елгы 8 нче санында.

Нәкый Исәнбәт хатыны Гөлсем белән. 1925 ел

аркылы Казан белән Уфаның театр, матбугат, әдәбият көчләре арасындагы, шулай ук уку йортларындагы настроениеләрне хәбәр итешеп, кайда һәм нинди чара күрү юлларын билгеләү.

6. «Җидегән»нең барлык членнарына, шул җөмләдән «Җидегән» төзелгәнче берберсе турында начар караштa булганнарына да, дуслашу, яклашу бурычын йөкләү.

«Җидегәнчеләр»нең үзара язышкан хатлары, матбугатта һәм матбугаттан тыш чыгышлары, «Җидегән» ачылганнан соңгы тикшерүләр – «Җидегән»нең әнә шул нигездә эшләгәнлеген ачып бирәләр.

12. Кул кулны юа

Беренче биш пунктны үтәү өчен, «Җидегән» членнарының үз араларында татулык урнаштырырга кирәклеген алар бик яхшы белгәннәр. Шулай ук үз членнары белән милләтче, динче, туранчы, гаязчы шагыйрьләр, язучылар арасында дусларча бәйләныш урнаштыру аркылы гына «Җидегән»не үстерергә мөмкин икәнлеген дә алар нык истә тотканнар.

Югарыда әйткәннәребезне раслаучы күп мисаллардан берничәсен (Уфа «җидегәнчеләр»е язган хатлар буенча) күчереп үтәбез: «Әсәреңне җибәрерсең бит? «Яшь юксыл» битендә тәнкыйть язып ташларбыз». «Рецензия яздым. Сиңа яхшы тукталдым». «Драматурглар союзының әгъзасы булсаң, әйтеп яз. Авторскийны симезрәк алырсың. Яңа пьесаң булса, анысын да җибәр. Уйнатылачак». «Тиз көндә Уфаның барлык ыгы-зыгысын төяп бер ябык хат язармын». «Казанга кайтып җиткәнсездер

Фатих Кәрим белән Төхвәт Ченәкәй. 1935 ел

инде. Сез икегез дә ике гәзиттә отчетный төстә берәр нәрсә язып үтәрсез. Шул язмаларда Карнай белән Батыр Вәлидевкә дә положительный тукталып үтегез».

Шуңар «җидегәнчеләр»нең бер-берсен мактап язган эпиграфлы һәм эпиграфсыз мәкаләләрен, Кутуй тарафыннан язылган обзорлардан солтангалиевче Бурнаш белән гаязчы Исәнбәт турындагы төче мәдхияләрне кушсагыз, бик тулы бер күренеш килеп чыгар.

Яз башында гына әле:

«Ә, бу нәрсә? Тавышмыни?

Моңар бары Казан гына тоташкан», –

дип зарланучы Кутуй, Уфа «җидегәнчеләр»е белән «тоташу» шатлыгына манчылып, Уфадагы яңа дусларын популярлаштыру кәсебенә тотына. Пролетариат язучыларның оешмалары тарафыннан әйтелгән карашлар белән һичбер санашмыйча, тотнаксыз мәкаләләр яза[1]. Исәнбәт белән Бурнашның сәяси йөзләрен, пролетариат әдәбиятына каршы чыгышларын томалап калдыра[2].

Мондый яклашулар әдәбият-матбугат сызыгында гына бикләнеп калмыйлар, өй тормышларындагы, семья багланышларындагы бозыклыкларын яклашуга хәтле барып җитәләр. Моңар Уфадагы бер конфликтның ничек бастырылуын бик ачык факт итеп санарга ярый.

Казан богемачылыгыннан Уфа богемачылыгына олаккан Минский, Уфа кыз-

[1] Шуның ачык бер мисалы итеп 1928 ел, 7 сентябрьдә чыккан «Красная Татария» гәзитендәге Кутуй мәкаләсеннән түбәндәге юлларны күрсәтергә мөмкин: «Современная татарская литература богата стихотворной поэзией. Немало прекрасных страниц внес в нее даровитый поэт Наки Исянбят. Вещи Исянбята как-то скоро завоевывают к себе симпатию читателя, заучиваются наизусть и ходят как народные песни из уст в уста. Исянбят за последнее время больше выдвинулся как сатирик. Так написаны его пьесы «Гижрат» и «Культур Шангарей». Он чуток и наблюдателен, быстро подмечает негодное и вкладывает весь материал в такую канву, что написанное им делается бессметрным». – Кави Нәҗми искәрмәсе.

[2] Кутуйның украин телендәге «Червоний шлях» журналында, «Коммунист» гәзитендә, урысча «Литературная газета»да былтыр бастырылган мәкаләләрен карагыз. – Кави Нәҗми искәрмәсе.

Бер кузгалган тегермән ташы һичкемне читләтеп тормыйча ватып тартырга керешә... Кави Нәҗминең төрмәдән чыккан чагы. 1940 ел

ларыннан берсен «укытырмын» дип алдап, зур скандалга эләгә. «Җидегән»нең актив члены булган Минскийны бу хәсрәттән коткару өчен, «җидегәнче»ләр иң кабахәт чаралардан да тартынмыйлар. Ул турыда аларның хатларында түбәндәге сүзләр бар: «Суфия бик күңелсез. Апасы килеп китте. Җизнәсе матбугатка чыгам, дип сөйләнә». «Сез киткәч, мәсьәлә куера төште. Үзе дә, туганнары да мәсьәләне үч алу төсендә куярга уйлыйлар». «Тыныч бул! Теге мәсьәлә башына салкын су сипкән кебек булды. Батырның сезнең хактагы шигырен Сәгыйтькә кулга төшерергә куштым. Җибәрермен әле. Тегеләрнең тавышы ишетелмәслек булып томаланды. Хәзер ул «Сәнәк» тирәсенә дә якын киләлмәслек хәлгә куелды. Крепость ныгытылды». «Почта белән язылган хатларда сәясәтләр язылган. Эшне уйлап чиш!» «Минский! Хәлләр җиңеләйде. Теге якта «күзлек» кенә б*ләтләнә[3]. Батыр – безгә дус. Теге хатлардагыча эшләсәгез, «күзлек»кә минус куярга да ярый. Бу турыда мин барган көнне үк сөйләшербез. Ашыгыч сөйләшербез».

13. Эчтән чери

«Җидегән» үз членнарын әнә шундый «агай-эне»ләрчә яклашу, бер-берсенең гаебен яшерү (круговая порука) тойгысы белән сугара. Ләкин «җидегәнче»ләрдә «Җидегән»нең үзәк тамырын черетә торган икенче сыйфат та бар. Бу сыйфат үз эчендә карьеристлык, ач күзлелек (рвачлык), көнләшү, гарьләнү, үпкәләү кебек күренешләрне бергә җыя. Буржуа әдәбиятының йөзтүбән мәтәлгән чорындагы талантсыз каләмнәренә уртак сыйфат булган бу хәл – «Җидегәнчелек»нең әзенә төшәргә ярдәм итә.

Кутуйның зур гына эшләрне башкаруы, рецензияләр язуның уннан тугыз өлешен үз кулына алуы – менә болар, беренче чиратта, Минский белән Ченәкәйнең йөрәкләрен әрнетә. Алар үзләренең өзлексез пешка булып йөрүләренә гарьләнәләр. Кутуйның югары үрмәләвеннән көнләшәләр. Ниһаять, быел татар совет язучылары җәмгыятеннән Ченәкәй чыгарылганнан соң, «җидегәнчеләр»нең кайберләре арасындагы «семья җәнҗалы» тышка ташып чыга. Башка вакытта теленнән тотып тартсаң да

[3] Оригиналда бу сүз цензурасыз бирелгән. – *М.Т.*

үз серен әйтмәүче Ченәкәй, тазарту иләгеннән узгач, бик сүзчән булып китә. Көннәрдән беркөнне ул Совет язучылары җәмгыятен чистарткан комиссиянең членына килеп, түбәндәгеләрне сөйли: «Мине чыгаргансыз икән. Ләкин язучылар арасында миннән элегрәк чистартылып чыгарылырга тиешле кешеләр бар. Мәсәлән, ТАППта Кутуй тора. Ул моннан ике ел элек Уфада төзелгән «Җидегән» исемле яшерен оешманың җитәкчеләреннән берсе бит». Бу турыда тулы итеп заявление бирергә кушкач, Минский белән бергәләп язарга вәгъдә куя. Ләкин алар икесе дә бу вәгъдәләрен үтәмиләр. Шуннан аларга: «Алай булгач, киләсе атнада ук, ТАППны чистарткан вакытта үз гаепләрегезне әйтеп, «Җидегән»нең бөтен составын, программадагы теләкләрен, китергән зыяннарын санагыз», – дип, икенче тәкъдим ясала. Алар шуңа күнәләр. ТАППны чистарту вакыты көзгә калдырылгач, аларга ул заявлениеләрен матбугат аркылы белдерергә киңәш бирелә. Шулвакытта «Җидегән»нең Минский белән Ченәкәй тарафыннан саналып бетмәгән серләрен, членнарын ачу, ныклап тикшерү чаралары күрелә. Шушы тикшерүнең кайбер нәтиҗәләре бу мәкаләгә нигез итеп алындылар.

14. Төбе-тамыры белән куптарып чыгарыйк!

Ләкин әле «Җидегән»нең барлык членнары, чаршау артына посып өлгергән ярдәмчеләре, эшләгән зыяннары турында тулы җавап алу өчен тагын бик күп моментларны тикшерергә, «Җидегәнчелек»нең иң яшертен тамырларына хәтле куптарып чыгарырга туры киләчәк.

Милли буржуа агентларының әдәбият фронтындагы пычрак чыгышларына җимергеч отпор бирү өчен, иң элек үз сафларыбызны сыйнфый сизгерлек, большевикларча бердәмлек, һәрбер мәсьәләгә, һәрбер күренешкә марксистларча дөрес анализ бирә белүчәнлек белән сугарырга тиешбез.

«Җидегән» ачылу уңае белән байтак карарлар чыгарылды, мәкаләләр язылды. ТАПП җыелышының, МАПП һәм Урал АПП каршындагы татар секцияләренең, Татар совет язучылары оешмасының карарлары, 14 имзалы протест, шулай ук Казан, Мәскәү, Уфа, Свердловск, Новосибирск гәзитләрендә басылган күп кенә мәкаләләр – «җидегәнчеләр»нең сәяси йөзләре турында дөрес характеристика бирәләр. Төп моментларның берсе турында, шушындый бердәмлеккә ирешү – үзе генә дә татар пролетариатының никадәр үсүен күрсәтә ала. Ләкин кайбер мәкаләләрдә, сәяси йөз мәсьәләсе дөрес куелу белән бергә, байтак кына ялгышлар, пролетариат әдәбияты өчен чамадан тыш зыянлы настроениеләрне очратабыз. Бу ялгышларның, настроениеләрнең төбендә нинди теләкләр ятканын, тамырлары кайда тоташканын тикшерүне аерым мәкаләгә калдырып, аларның барысы өчен дә уртак булган бер моментны әйтеп узабыз.

Кайбер иптәшләр һәм алар тарафыннан бирелгән ялгыш информацияләргә таянучы МАПП белән Урал АПП каршындагы татар секцияләре кебек бөтен бер коллективлар ТАППка каршы ут ачтылар. Алтмыштан артык татар, урыс, чуаш язучыларын туплаган һәм матур әдәбият фронтындагы җирле күренешләр белән, дошман элементларның чыгышлары белән аяусыз көрәш алып барган бер оешмага каршы ут юнәлдерерлек нинди сәбәпләр бар соң? Мондый сәбәпләр юк. Ләкин пролетариат язучыларының оешмаларына группачылык чирен йоктырырга теләүчеләр үз башларыннан: «ТАПП Ченәкәйгә материаль булышлык күрсәткән, имеш; «Җидегән» ТАППның борын төбендә, ТАППның үз эчендә туып үскән, имеш!» кебек ялган

хәбәрләр таратып, күз буядылар. Ныклы тикшерүләрдән соң ул хәбәрләрнең чеп-чи уйдырма икәнлеге беленде.

Уфада да, Казанда да, башка урыннарда да татар һәм башкорт буржуазиясенең калдык көчләре, төрле тармакта зыян китерүче агентлары бар. Сыйнфый дошман пролетариат диктатурасына һәм аның оешмаларына каршы һөҗүмен территория белән чикләми. Территория ягын гына (анда да фәкать Казанны гына) күздә тоту, «җидегәнчелек»кә каршы бер фронт булып көрәшәсе вакытта, ТАППка иң әшәке пычраклар ыргыту – «җидегәнчеләр»гә генә җиңеллек тудыра. Менә шуңа күрә дә, РАППтан «Җидегән» эшен тикшерү өчен килгән Юрин иптәш үз мәкаләсендә группачылык нигезендәге чыгышларга каршы нык отпор биреп узды. Хәзер без Донбасстагы 35 меңләп татар шахтерлары исеменнән, Кызыл Армиядән һәм башка урыннардан алынган резолюцияләрнең дә пролетариат язучыларының оешмаларында группачылык тудырырга маташу кебек күренешләргә иң каты удар ясауларын зур шатлык белән әйтә алабыз.

Бу моментларга тукталуым белән бергә, мин ТАПП эшендәге кимчелекләрне, ялгышларны томалап калдырырга теләмим. ТАППның үз резолюциясендә дә ул кимчелекләр, ялгышлар бик ачык әйтелгәннәр («Атака»ның 3 номерыннан ТАПП резолюциясен карагыз).

15. Шәфкать көтмәсеннәр

Без әдәбият фронтындагы сыйнфый көрәшнең аеруча кискен чорын кичерәбез. Бу көрәш – сафларыбыздан корыч бердәмлек сорый. Бу көрәш – әдәби оешмаларыбызны пролетариат һәм колхозлар катлавыннан күтәрелгән яңа көчләр белән ныгытуыбызны сорый. Бу көрәш – пролетариат язучыларын Маркс-Ленин идеяләре белән ныклап сугаруны, аларның квалификацияләрен масса арасындагы көндәлек эшкә, социализм төзелешенә бәйләп күтәрүне, бу төзелеш турында онытылмаслык әсәрләр тудыруыбызны сорый.

Бу көрәш – нәшриятларыбызның, әдәби оешмаларыбызның җитәкчелеген большевиклаштыруыбызны сорый.

Бу көрәш – Сталин иптәш XVI съездда әйткәнчә, чит һәм сыйнфый йөзен югалткан элементларны читкә себереп ташлап, түбәннән яңа көчләр үстерергә; капитализм элементларына бөтен фронт буйлап киң һөҗүм алып барырга; массаларны илебездәге капитализм элементларына каршы сыйнфый уяулык белән сугарып, революцион активлыкларына мобилизация ясарга куша.

Бөтен фронтларда җиңеп килүче Ленин партиясе тарафыннан өстебезгә йөкләнгән бу бөек бурычны без тулысынча үтәрбез, барлык кыенлыкларны, пролетариат диктатурасына, пролетариатның иксез-чиксез җиңешләренә, пролетариатның зур көрәшләр эчендә туган әдәбиятына каршы юнәлгән барлык чыгышларны батыр адымнар белән таптап узарбыз.

Сыйнфый дошманга һәм аның төрле төстәге агентларына безнең йөрәкләрдә әз генә дә кызгану тойгысы уянмас. Моны «җидегәнчеләр» дә, аларның дуслары булган солтангалиевчеләр дә, гаязчылар да исләрендә нык тотсыннар!

«Атака» журналы, № 4-5, 1930 ел

*Басмага **Миләүшә Талипова** әзерләде.* ■

Безнен мирас №9 сентябрь 2019



АРХЕОГРАФИК КӨНДӘЛЕК

Миркасыйм Госманов

II сәфәр.
Рязань өлкәсе, Касыйм шәһәре.
23 июль-22 август, 1964 ел

*Беренче сәфәр – 1963 елны Оренбург өлкәсе һәм Көньяк Башкортстанга оештырылган археографик экспедиция юлъязмасы галимнең кызы, профессор **Диләрә Госманова**ның кереш мәкаләсе белән журналыбызның 2014 елгы 5-6 нчы саннарында басылып чыккан иде. Казан дәүләт университетында 1965-1989 елларда археографик экспедицияне җитәкләгән тарих фәннәре докторы, академик **Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов** (1934-2010) әлеге көндәлекләрне 25 ел дәвамында алып барган.*

1964 елгы археографик көндәлек ике нөсхәдә саклана. Беренчесе экспедиция барышында язылса, икенчесе 1966 елда күчерелгән. Алдагы текстта икенче вариант тәкъдим ителә, әмма анда керми калган, ягъни беренче нөсхәдәге кайбер мөһим өлешләр астөшермәдә бирелә. Галимнең тел стиле тулысы белән диярлек саклана. Шулай итеп, борынгы язма мирасыбызны җыю, өйрәнү, саклау хакындагы кызыклы һәм мавыктыргыч юлъязманы укуны дәвам итик, дуслар.

Редакция

Быел Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәре һәм аның тирәләренә барырга булдык. Планны расладылар. Ләкин экспедиция составы турында сүз чыккач, былтыргы дәрәҗәле агайлар (Шамилдән башкалары) читкәрәк тайпылдылар. Шулай итеп, Шамил абый[1] һәм мин. Ләкин ул да экспедициягә бик әз вакытка гына килергә уйлый. Яисә Мәскәүдә эше бик күп. Уйламаган җирдән Әбрар Кәримуллин[2] бара торган булып чыкты. Шулай итеп, формаль рәвештә өч кеше. Чынлыкта исә без икәү: Әбрар һәм мин. Машина кирәкми. Шулай булгач, әзерлекләр дә чамалы. Җыйнак...

23.VII.64.

Иртәнге сәгать 6да Әбрар Кәримуллин белән «Станюкович» пароходына утырып, Казан портыннан киттек. Төнне, әлбәттә, вокзалда уздырдык. Ә Шамил абый Касыймга Мәскәүдән килергә тиеш, соңгарып...

Көн көздәгечә соргылт, салкын иде.

Каютабыз бик тар, җайсыз; дүрт кешелек. Шулай да көне буе диярлек йокладык. Уянып, ашап-эчеп алгач, тагын йокладык. Пароходта гел карт-корылар һәм бер төркем мәктәп балалары, ана тавык кебек кабарынган укытучылары белән.

24.VII.64.

Көндезге 12дә Горький шәһәренә җиттек. Сәгать 5кә хәтле шәһәр аралап, кибетләр буйлап йөрдек. Гаҗәп: безнең Казанда ачлык кебек – бернәрсә дә юк (юлга дигән азыкны, хәттә ак ипине дә көчкә тапкан идек – колбаса һәм май турында сөйләп торасы да юк. Шикәр, ярмалар талаш белән...), ә биредә барысы да бар: төрле сорт ите, мае, шикәр-балы, сыры, сөте, төрле винолар, шәп тәмәкеләр! Бик сәер булды. Ләкин соңра аңладык – Горькийда моннан элек беркадәре чуалышлар булган, имеш, һәм шуның өчен кибетләр тулы, имеш... Ярар, ни булса булган, ә без азык-төлек алдык: консервалар, киптергән балык, сыр, помидор, май һ.б. Әлбәттә, 5-6 шешә румын виносы, 40-50 пачка болгар сигареты...

25.VII.64.

Муром шәһәренә җиттек. Көн бик матур иде. Шуңа күрә су коенып, ял итәргә булдык: пантон күпер аша Ука елгасының икенче ягына чыгып, озак кына коендык.

26.VII.64.

Иртәнге 9:20дә Касыйм шәһәренә җиттек.

Әллә кайдан манара һәм чиркәүләр каршылый. Гел манаралар. Без шәһәргә чыктык, пароход 4-5 сәгать торачак (Рязаньга барып, шуннан Касыймга кире кайтачакбыз). Димәк, хәзергә чыгып танышу гына.

Кечкенә генә, тузан-пычрак кына иске шәһәр. Сәүдәгәрләр, мещаннар шәһәре. Иске йортлар, таш кибетләр, тимер ишекләр, чиркәү манаралары... Әйтерсең лә тормыш биредә катып калган... Гүяки совет властеның бер яңалыгы да аңар кагылмаган. Менә үзәктән барабыз. Гел борынгы, революциягә хәтле йортлар. Бер яңа бина, безнең көннәр төзелешен күрмәссең...

---

[1] **Мөхәммәдьяров Шамил Фатих улы** (1923-2005) – тарих фәннәре кандидаты, профессор, ТРның атказанган фән эшлеклесе. 1956-1965 елларда КДУда эшли, 1959 елдан СССР тарихы кафедрасы мөдире. – *Ред.*

[2] **Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин** (1925-2000) – филология фәннәре докторы, ТРның атказанган фән эшлеклесе, ТРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. 1953 елдан университетның фәнни китапханәсендә эшли. 1964 елның декабреннән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында. – *Ред.*

Ләкин бераз баргач, шәһәрнең үзенә күрә күркәм сыйфатлары да ачыла башлады: җыйнак, шау-шусыз, тыныч, тарихка экскурсия...

Казаннан алган адрес буенча Фәрхәнас апа Бәшированың өен эзләп таптык. Аның адресын яшьлек дусты Заһидә Бурнашева – «Гыйффәт туташ» биргән иде... 70 яшьлек, бәләкәй генә, җыйнак кына, орчык хәтле әби. Гаҗәпсенгәндәй, якты чырай белән каршылады. Сөйләшә торгач, максатыбызны аңлаттык. Әбиебез бераз аптырап калды, аннары өйдән бер хат алып чыгып укып бирде. Анда: «Кулъязма җыю максаты белән Шамил әфәнде Мөхәммәдьяров бара, ярдәм итәрсең», – дип язылган. Язучы – Шамилнең каенатасы – Камал Бәширов. Менә Фәрхәнас апа аптырый, без көлдек: «Без шул Шамилнең кешеләре инде, ул соңрак киләчәк, ә без эшли торабыз», – дидек. Әби җәйрәп китте: «Алайса була, кулъязмалар күп табылыр!»

Әңгәмәләшә-әңгәмәләшә чәйләдек. Дуслаштык. Вәгъдәсе шәп, зурдан. Энесе Һади абый белән дә таныштык (сеңелләре Галимә – Алимә эштә икән). Рязаньнан килгәч, материаллар белән таныша башларга булып, саубуллашып киттек. Ләкин авылларның бик хәрабә булуларын искәртеп куйдылар...

Юлдан элекке Хан мәсҗеденә сугылдык. Анда хәзер музей. Төп бинаның бер өлеше бик яңа (XIX гасыр), бары манара гына бик борынгы. Тәкыяләр (мавзолейлар) дә XVI гасырдан[3].

Менә пристаньга төшеп барабыз. Шәһәрне бөтенләй айкап чыктык, диярлек. Берничә генә җирдә яңа салынган йортлар күрдек... Ләкин Касыймның элек, заманында гөрләп торган булуын да хәзер ачыграк күрәбез. Әйе, шук сәүдәгәрләр, тук мещаннарның оясы булган бу!..

Сәфәребезне дәвам итәбез. Каютада эссе. Көн матур.

Ә Ука буйлары!.. Бормаланып аккан чамалы гына елга. Бөдрә урманнар, киң болыннар... Матурлыгы үзгәчә. Бу – мишәр крае. Ирексездән искә Сергей Есенин шигырьләре төште. Менә кайда ул шигърият чишмәсе!..

Кич бик матур иде...[4]

27.VII.64.

Көн матур иде. Тентка чыгып кояшта кызынып яттык. Ә табигать!.. Ука бормаланып-бормаланып ага. Текә ярлар. Киң болыннар, ара-тирә бөдрә урманнар, күлчекләр... Болыннарда гөмбә кебек кибәннәр, сыер көтүләре. Төркем-төркем аккош болытлар... Есенин поэзиясенең чишмәсен күрдем кебек, аның сере каян килүен аңлыйм сыман: тыйнак, гүзәл табигать, ул зәңгәрсу, тонык, зәңгәр якты моң белән өретелгән...

Бу, мөгаен, иң хозурлы көннәрнең берсе булгандыр!..

Сәгать 4тә (көндезге) Рязаньга җиттек. Шәһәр пристаньнан ерак түгел. Кечкенә генә, ярыйсы пөхтә генә шәһәр сыман. Зур авылны да хәтерләтә. Шәһәрдә бераз «типтергәч», «Приокский» дигән гостиницага урнаштык. Кичен – моцион. Тыныч йокы (пароход вибрациясеннән соң...).

---

[3] Беренче нөсхәдәге абзац төшеп калган: «Музейга кереп тормадык. Кайткач керербез. Иске генә шәһәр. Яңа йортлар бик сирәк. Анда-монда гына. Әммә ярыйсы гына яшел... Юлда очрашып кына Сафа абзый Янбаев белән таныштык. Очрашачакбыз. Адресны алдык...»

[4] Беренче нөсхәдәге абзац төшеп калган: «Бераз Агыйделне дә хәтерләтә. Яр буйлап урманнар, болыннар, әрәмәлекләр. Кичен палубада бераз танцевать иттек. Анна Михайловна дигән Мәскәү укытучысы белән таныштым. Акыллы, күңелле һәм әдәпле генә хатын. Ул үзенең укучылары белән. Аларны саклый-саклый башы каткан мескеннең... Уку-укыту турында озак кына сөйләшеп тордык...»

28.VII.64.

Ашыкмыйча Облисполкомга килдек. Документларыбызны күрсәтеп, тиешле кәгазьләр алдык. Урындагы властьлар өчен.

Шәһәр архитектурасы белән танышабыз. Бик бай. XVI гасырдан калган бик шәп биналар бар!.. Ләкин күбесе җимерелер кебек – ремонтсыз...

Архив описьлары белән танышабыз. Искитәрлек нәрсәләр очрамый...

29.VII.64.

Музейга килдек.

Ул бинасы белән дә, материаллары белән дә бик бай. Ләкин тәртип, оештыру җитми. Надан гына кешеләр эшли. Гаҗәп түгел, чөнки гыйльми хезмәткәрләрнең айлык хезмәт хакы – 45 сум, ә директорныкы – 69 сум. Уборщицадан артык түгел! Хурлык...[5] «Югарыга карап фикер йөрт, түбәнгә карап шөкер ит», – дигән мәкаль искә төште.

Чыннан да, без үзебезне әһәмиятсез генә җирдән килдек, дип уйлый идек, ә монда, безне бик олылап кабул итәләр: «О, сез бит Республика!» – диләр.

Музейда ремонт булгач, артык эш калмады (архив вәгъдә итми).

30.VII.64

Самолет белән Касыймга очтык. Сау бул, зур авыл!..

Манзара күктән бик кызык иде: күбрәк – сазлыклар... Юлда 30 минут булдык. Касыймда гостиницага утрнашкач, Ука буена төшеп су кердек, рәхәтләнеп кызындык. Кая ашыгырга?!.

31.VII.64

Горисполкомда булып, тиешле кешеләргә күренеп-күреп чыктык. Музейга юнәлдек. Музейның гыйльми хезмәткәре – Галина Ивановна Садкова. Соңра бу «гыйльми» хезмәткәрнең 30 сум эш хакы ала торган булуын белдек! Белемле генә, төпле генә хатын. Теләктәш. Фондында булган кулъязмаларны күрсәтте. Махсус килеп тасвирлар өчен 10-15 кулъязма аерып куйдык. Иртәгегә. Ә бүген архитектура истәлекләре белән танышабыз. Манараны карыйбыз, тәкыяләргә кереп чыктык. Әйе, без элекке курчак касыйм ханнары «дәүләт сөргән» җирләрдә йөрибез. Манара 1470 елда салынган. Ләкин нигезсезлек, төпсезлек сизелеп тора. Утрау гына, ком утравы сыман.

Г.И.Садкова үзе башлап йөрде, белгән кадәр аңлатты...

Ул акыллы гына хатын: кулъязмаларның югалып, хур булуы бар, бередә беркем дә аларның кадерен белми. Безгә аларны ничек тә Казанга алдырырга киңәш бирә. Культура министрлыгы аша алырга мөмкин. Уйларга кирәк.[6]

Кичен касыймлы укытучы Әхмәт ага Ишембаевка бардык, озак кына сөйләшеп, әңгәмәләшеп утырдык (ул. Федорова, №14). Ачык чырайлы, хуш холыклы кеше икән. Безне атаклы Касыйм казылыгы белән сыйлады. Ярыйсы!

Авыл хәлләреннән, халык тормышыннан бай гына мәгълүмат бирде. Сүзләренә карганда, халыкта милли тойгы да, йомыклык та көчәя бара. Татар мәктәпләре сугыштан элек үк ябылган[7]. «Декрет» белән.

---

[5] Беренче нөсхәдәге абзац төшеп калган: «Ләкин бу кешеләрне кызганмыйча булмады. Бу чын мәгънәсе белән административ-бюрократик корбанлыгы...»

[6] Беренче нөсхәдәге абзац төшеп калган: «Чыннан да матур фикер! Без шулай эшләргә тиешбез! Әмма бик оста эшләргә кирәк. Дөрес, Мәскәүнең үзенә дә алып кую ихтималы бар. Ярар, алсын, ичмасам анда югалмас...»

[7] Беренче нөсхәдәге җөмлә төшеп калган: «Педагогик техникумдагы татар бүлеге дә ябылган...»

Әхмәт ага (55ләрдә) өйләнмәгән. Ике сеңлесе бар, үзеннән чак кына яшьләр, алар да тормыш кормаган...

1.VIII.64

Музей. Кичә аерып куйган кульязмаларны актарып утырам. Шактый кызыклылары очрый. Кайберләреннән өзекләр күчерәм. Табышмаклар очрый (китап ахырларында). Кульязмаларның күпчелеге дини эчтәлекле, әлбәттә. Дөньявилары да шактый. Кайберләре Урта Азиядән килгән. Шунда сатып алганнар. Шунда ук татар шәкертләре күчергәннәре дә очрый.

Менә Т.Ялчыголның «Рисалә-и газизә»се, матур гына почерк. Катай авылы башкорты Тимергали Габделкәрим, Петербургта чакта, саткан 1832 елны, 200дән артык бит (№261).

Менә бер кульязма (Ишан Шаһ Машрап), Урта Азия кульязмасы. «Ханкирмәнле» Мөхәммәтмәһди Муса улы 1878 елны Бохарада сатып алган. Әсәр эчтәлеге белән үзбәкләргә карый. Татар табышмаклары очрый (башка почерк белән язылган).

Менә изгеләр турындагы бу китап мирзалардан Тимербулат мирза Назирмөхәммәт мирза Максудовның милке булган. 1845 елны Ташкент шәһәрендә күчерелгән (№1238).

1283 номерлы кульязмада (1849 ел) борынгы әйбер күчермәләре дә бар. Ахырда төрек сугышы, Волга-Дон каналын казу турында кызыклы хәбәр бар. Каян күчерде икән?

№1279 – «Йосыф китабы».

№1254. Мәҗмуга. Төрле текст. XVIII һәм XIX гасыр чиге. 205 кәгазь. Бер «Тәгъбирнамә». Иң азакта татарча «Вәкаигънамәдән» өзек китерелә. Казан алыну белән башлана. Бик кыскартылган, шул ук вакытта биредә артык элементлар да бар сыман... Ахыры булмавы кызганыч, кайчан төзелгән вариант булуын ачыклап булыр иде... Җирле тарих элементлары да бар. Гаҗәп: оригинал Касыйм тарихы табылмас микән?!

Музейда озак кына утырдык. Минем күчереп утыруыма Әбрарның сабыры шартлый башлады. Чыннан да озак утырам бугай.

Кичке якта Фәрхәнас апага бардык[8]. Ул безне иске йортның (хәзер сарай булып калган) икенче катына алып менде. Анакаем: бер бүлмә эче тулы китаплар, киштә-киштә, сандык-сандык китаплар! Бер генә киштәне актара башлаган идек, төрле кульязмадан 50-60 данә аерып алдык! Ару өстенә дулкынлану да кушылды... Ә Әбрарның күзләре ау этенеке кебек ялтырый – малай, азартлы гына! Фәрхәнас апа (бәләкәй генә какча әби!) безне елмаеп кына күзәтә: балаларның күңелле уйнауларын күзәткән ана кебек. Бераздан: «Ярар, – ди, – бүгенгә ял итегез. Иртәгә әнә сандыкларны да ачарсыз. Анда кульязмалар тагы да күбрәк».

Без, өс-баштан тузаннарны кагып, ишегалдына чыктык. Озак итеп тәмәке тартабыз. Дулкынлану чыгып бетми. Моңарчы бу кадәр күп кульязмаларны хосусый кулда бер җирдә дә күрмәгән идек.

Арылган. Кичке 8. Фәрхәнас апа безне чәйгә чакыра.

Озак кына әңгәмәләшеп утырдык. Фәрхәнас апа хәзинәсеннән тыш адреслар да вәгъдә итә. Кульязмалар булуын үзе күргән.

---

[8] Беренче нөсхәдә болай дип язылган: «Моннан соң Фәрхәнас апа Бәшировага бардык, аларның аталарыннан калган бай көтепханә белән таныштык. Күрәсең ки, Касыйм шәһәрендәге көтепханәләрнең бик күбесеннән монда китаплар җыелган! Сарайда җыелган китапларны гына актарып та 60-70ләп кульязма һәм китап сайлап алдык! Иртәгә каралачак тагын өч сандык бар! Алардан нәрсә чыгар икән?! Аның өстенә тагын бер-ике адрес бар. Димәк, эшләр уңа! Шамил Мәскәүдән килүгә без шактый нәрсәләр карап куячакбыз. Шулай ук иртәгә музейда каралмаган бер өлеш китаплар бар әле... Димәк, эшлә дә эшлә!..»

Бу бик кызыклы гына гаилә: Фәттәхетдин Бәширов Казан якларыннан күчеп килгән. Мишәрләрдән. Мулла булып мәчет тоткан, мәдрәсәдә шәкертләр дә укыткан. Гомерендә ике хәзинә җыйган булса, аларның берсе – китаплар. Революциядән элек Казанга килгән саен йөзәрләп китап алып кайта торган булган. Революциядән соң Касыйм байлары тузып, аларның көтепханәләре дә таралган чорда, ул күп кенә әйберләрне һәлакәттән коткарып калды.

Бик олы яшкә җитеп үлгән. Гомеренең соңгы көннәрендә күзләре күрмәс булган. Шулай да вакыт-вакыт зур борынлы, түгәрәк ак сакаллы сукыр какча бабай капшанып кына китапларын барлый торган булган.

Фәрхәнас апа боларны тыйнак кына алды... Ә мин күзләремне йомам: күз алдында күңел нуры сүнмәгән мәһабәт ак бабай, аның куллары сөекле китапларына тигән саен йөзендә сөенү чагыла: менә алар! Шул ук вакытта бабаның битендә олы хәсрәт тә бар: укып булмый аларны!..

Фәрхәнас апа да, аның энесе Һади абый, сеңлеләре Алимә апа да, тормыш төземичә, берялгызлары яшәгән. Өчесе дә бөтен гомерләрен укытучылыкка биргәннәр... Сәер дә, аңлашыла да кебек...

Шулай итеп, безгә эш җитәчәк...

2.VIII.64

Иртә белән Мәхмүдә апа Итакаева дигән бер апага кереп чыктык. Татар, якты чырай белән каршы алса, чәй куя... Бер-ике кулъязма да бар икән. Мактый-мактый алдык.

Музейда бөтенләй эшкәртелмәгән кулъязмалар бар икән. Шуларны аерып алып карап утырдык. Бу кулъязмаларның барысын да алу фикерен киләчәктә күтәрергә кирәк.

Ука суы буена төштек. Көн бик матур иде. Алтын ком... Шәп!..[9]

Фәрхәнас апаларның ачылмаган сандыкларын ачтык – кулъязма![10] Берсе артыннан берсе, һәр өч китапның берсе – кулъязма. Әбрарның күзләре очкынлана. Гадәти шәкерт конспектларын да зур табыш кебек аера тора: «Менә тагын кулъязма!..»

Өч-дүрт сәгать эчендә йөздән артык кулъязма һәм сирәк китапны аерып куйдык.

Дөрес, аларның күбесе гадәти шәкерт конспектлары яисә гарәпчә юриспруденция әсәрләре. Ләкин араларында бик әһәмиятлеләре дә бар. Әдәби әсәрләр дә. Менә фарсыча «Сәйфелмөлек» вә «Бәдигыйлҗәмал» кыйссасы. Проза.

Ярар. Бу бер коллекция белән бөтен экспедиция эше акланды. Ә эшләве күңелле булды. Ара-тирә ишегалдына чыгып тәмәке тартам. Ә ишегалды – яшел хәтфә, әйтерсең лә яшел келәм җәйгәннәр (хәрәкәт аз булганга, үләне тездән киләрлек булып үскән), сызылып кына бер-ике сукмак ята, тәрәзә төбендә күпереп гөлләр үсә, алардан өстә алмалар пешеп утыра... Тик өем-өем утыннар гына ямь-яшел ишегалдының төсен бозып торалар.

Без канәгать, безгә карап Фәрхәнас апа да сөенеп йөри. Без Шамилнең килүен көтәбез. Ә ул аларның кияүләре бит.

Дәвамы бар

*Көндәлекләрне басмага **Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

[9] Икенче вариантта бу җөмлә төшеп калган: «Төштән соң Солтанов Айфулла абзыйга бардык. Бер-ике кулъязма алдык...»

[10] Икенче вариантта төшеп калган җөмлә: «...кулъязма һәм сирәк китаплар хәзинәсенә чумдык! Байлык һәм байлык!!! Өч-дүрт сәгать эшләп, йөздән артык китап һәм кулъязма аерып куйдык... Озын сүзнең кыскасы: экспедициянең бөтен чыгымы һәм максаты акланды!!! Шамил килсен...»

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

ТАССР

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИННЫҢ ТУГАН ТЕЛДӘ УКЫТУ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАШЫ

«Безнең мирас» журналы укучыларына Газиз Гобәйдуллинның күп еллар элек язылган мәкаләсе тәкъдим ителә. Анда күтәрелгән мөһим мәсьәлә хәзерге вакытта милли җәмәгатьчелегебез һәм матбугат мәйданыбызның игътибар үзәгендә.

Күренекле татар тарихчысы, әдип һәм педагог Газиз Салих улы Гобәйдуллин (1887-1937) Казан шәһәрендә дөньяга килгән, «Халидия» мәдрәсәсендә белем алган. Үзлегеннән рус һәм Европа телләрен өйрәнгән, дөнья әдәбияты, тарихы һәм фәлсәфәсе белән танышкан. Казан император университетының тарих-филология факультетын тәмамлаган. 1920-1930 нчы елларда Казан, Баку, Сәмәрканд, Ташкент, Мәскәү, Пятигорск шәһәрләрендәге югары уку йортларында укыткан. Татар һәм башка төрки халыклар, Шәрык илләре тарихы, әдәбият тарихы буенча күп санлы гыйльми хезмәтләр язган, фәнни эзләнүләр алып барган. Үткен эчтәлекле хикәяләр иҗат итеп, «Г.Газиз» имзасы белән матбугатта бастырып чыгарган. Дәһшәтле 1937 елда кулга алынып, нахакка гаепләнеп атып үтерелгән. 1957 елда акланган.

Мәкалә 1923 елгы «Безнең юл» журналыннан (№12. – Б.11-12) алынды. Искергән сүзләргә җәяләр эчендәге аңлатмалар безнең тарафтан өстәлде.

Татар телендәме, рус телендәме?

Газиз Гобәйдуллин

Әдәбиятыбызда «Ана телендә мәктәп» фикере 1905 ел революциясеннән бирле сөйләнеп килә. Октябрь революциясенә кадәр бу мәсьәләгә бары сәясәт вә милли яктан каралып киленде һәм бу идея иске хөкүмәт белән көрәшнең бер коралы булып барды. Хәзерге көндә миллият мәсьәләсе хәл кылынып килә, хәтта Октябрь революциясе бу бабта *(мәсьәләдә)* милләтчеләр теләгәннән артык хокук биреп, милли мәсьәләдә талашырга имкян *(мөмкинлек)* калдырмады. Шуның өчен урта мәктәпләрдә вә профессиональ уку йортларында уку теленең русчамы, татарчамы булуы мәсьәләсен бөтенләй сәясәттән чыгып, бер дә сабыйланмыйча, бер хиссияткә бирелмичә, «эш» ягыннан карарга мөмкин. Ибтидаи *(башлангыч)* мәктәптә фәннәрне ана телендә уку мәсьәләсе ул бер мәгълүм хакыйкать, хәтта Ильминский шикелле консерватор педагог тарафыннан да хәл кылынган бер мәсьәлә. Шуның өчен мәсьәләнең хәл ителмәгән ягы – бары урта мәктәп.

Бу елларда татар яшьләренең урта мәктәптә ана телендә укуга каршы фикерләре күренә башлады. Яшүсмерләр мәктәпкә керергә килгәндә, «русчамы, татарчамы укыла?» дип сорап, татарча дәресләргә ышанмыйча карыйлар. Аталар да балаларын китергәндә «русча укыла торган мәктәпкә бирмәкче идем...» дигән шикелле фикерләр сөйлиләр. Монда бер гаҗәп эш юк; мәктәп ислахаты *(реформасы)* заманында «фән, фән» дип кычкырдык та, мәктәп вә мәдрәсәләргә «фән» керттек; ләкин кертелгән фәннәрне укытучысы юньле булмаганга, укытырга дәреслекләр булмаганга, ул «фәннәр» бик начар укытылдылар ки,

Газиз Гобәйдуллин

гали *(югары)* мәктәпкә керергә теләсәләр, мәдрәсәдән укып чыкканга карамыйча, һәндәсәне *(геометрия)* дә, җәберне *(алгебра)* дә, җәгърафияне *(география)* дә, тарихны да, табигыятьне дә яңадан укырга мәҗбүр булдылар; хасыйль *(кыскасы),* татар мәктәпләрендә фән укыган булып, аның бары ишеген генә иснәп калдылар.

«Соң бит безгә гали (югары) мәктәпкә керергә кирәк, әгәр монда ул дәресләр татарча укытылсалар, анда бит имтихан тотып булмас!» – диярләр. Бу көчле дәлил; ләкин фәннәрне татарча укыткан чакта бер шартны үтәргә кирәк. Ул шарт исә татар мәктәпләренең дәрес программын ясаганда татар хосусияте белән хисаплашу.

Октябрь революциясе соңында да гөмбәләр шикелле үсеп чыккан икенче баскыч мәктәпләребездә, техникум вә курсларыбызда һәр фәнне дә татарча укыта башладык; ләкин аларны укытырга көчле мөгаллимнәр таба алмадык. Мөгаллимнәребез яисә «Хөсәения», «Мөхәммәдия», «Галия», «Касыймия», «Госмания»дә укыган кешеләр иделәр ки, бу мәдрәсәдә укытучылар яисә

Истанбулда сухтә булып *(бик тырышып)* укып кайткан яисә анда ярым-ярты «Мөлкия» *(хөкүмәт уку йорты)*, рөшдия *(урта мәктәп)*, игъдадияләрендә *(мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү сыйныфларында)* селкенеп йөргән кешеләр; яисә Учительски школада бары ибтидаи мәктәптә рус азбукасы, дүрт гамәл «гыйльме хисап» укытырга хәзерләнгән затлар иде. Урта мәктәпләребез ачылгач та, боларга без үзләре белмәгән нәрсәләрне укытырга куштык; табигый, болар укыта алмадылар; паёк алдылар, селкенделәр, йөрделәр. Аталарның да, балаларның да ана телендәге мәктәпләрдән тәмам ихласлары чыкты куйды!

Шуның өчен бу мәсьәләне тикшергәндә, маузугны *(мәсьәләне)* без болай куябыз:

– Әгәр көчле мөгаллимнәр булса, дәреслекләр мөкәммәл булса, урта мәктәпләрдә фәнне шәкертләр белми торган русчамы, әллә татарчамы укыту педагогия җәһәтеннән файдалы?

Мин бер дә өркемичә, бер дә мәсьәләгә сәясәт катыштырмыйча гына әйтәм ки:

– Татарча укыту файдалы!

Мәгълүм ки, без ысул җәдидә дәверендә ысул кадимәдән көлгәндә алар гарәп нәхүсарыфын *(синтаксис һәм морфологиясен)* фарсый *(фарсы телендәге)* дәреслектән укыталар дип көләдер идек. «Әгәр гарәп теле татарча дәреслек вә татарча тәкърир *(аңлатып сөйләү)* белән укытылса, тизрәк белер идек», дидер идек; һәм шулай иткәч, белдек тә. Әүвәле 15-20 еллар мәдрәсәдә ятып, гыйбарә укый белми чыккан хәлфәләрдән арттырып, шул ук нәрсәне 3-4 елда белдек вә «моталәгабыз чыкты» *(мәгънәсен аңладык)*. Бу бер тәҗрибә һәм яхшы тәҗрибә. Менә рус вә татар телендә укыту мәсьәләсендә дә шулай ук, бер-бер фәнне укыганда, фәннең әсас *(төп)* мәсьәләсенә караганда, «ничек итеп әйтәсе инде», дип уйлап утыру нәкъ схоластик бер нәрсәдер. Мәсәлән, татар мөгаллиме, миңа Фисагурс *(Пифагор)* теоремасын татарча сөйләде. Мин моны беренчеләй бик тиз аңлыйм, икенчеләй, аңлагач та исбат кыла алдым. Әгәр шул дәресне русча сөйләсәләр, миңа мөгаллимнең нәрсә сөйли икән вә ничек фикер йөртә икән дип тыңларга тырышуым белән бергә, нинди итеп сөйли, нинди сүзләр истигъмаль кыла *(куллана)* вә аларның мәгънәсе ничек, алар мөәннәс *(хатын-кыз җенесен белдерә торган грамматик категория – женский род)* микән, мөзәккәр *(ир-ат җенесен белдерә торган грамматик категория – мужской род)* микән дигән шикелле, һичбер Фисагурс теоремасына бәйләнеше булмаган нәрсә хакында баш ватарга туры килә. Бу мәсьәлә гарәп сарыфын *(фарсы телендәге)* «Бидан» дәреслеге буенча укудан бер дә артык җире юк. Әле дә күз алдымда тора: бервакыт мин мәэмүр *(инспектор)* сыйфаты белән бер техникумда физика дәресенә кердем. Мәсьәлә «Җәзбе гомуми» («Всеобщее тяготение») иде бугай. Дәрес беткәч, мин бер шәкерттән сорадым. Русча сорадым. Шәкерт ык-мык итте; минем күземә вә мөгаллимгә елмаеп, кызганыч сыйфат белән карады; сөйли дә башлады, булдырып чыга алмады; миңа әйләнде дә: «Газиз абый, мин аны русча әйтә алмыйм, әмма татарча булдырам» – диде. Вакыйган *(чынлап та)*, татарча сөйләп бирде. Әмма мөгаллим инде, сорап та белмәгәч, журналга «минус» галәмәтен куеп өлгергән иде. Бигрәк тә бу вакыйга сүз күп таләп кылына торган тарих, җәгърафия, икътисад шикелле голуме мәгънәвиядә *(мәгънәви фәннәрдә)* сизелә.

«Соң бит безгә гали *(югары)* мәктәпкә керергә кирәк, әгәр монда ул дәресләр татарча укытылсалар, анда бит имтихан тотып булмас!» – диярләр. Бу көчле дәлил; ләкин фәннәрне татарча укыткан чакта, бер «лябид минһу» *(котылгысыз)* булган шартны үтәргә кирәк. Ул шарт исә татар мәктәпләренең дәрес программын ясаганда татар хосусияте белән хисаплашу. Бу мәсьәләдә исә иң күп игътибарга алына торган нәрсә – рус телен тел буларак, рус мәктәпләрендәгеләргә караганда ике өлеш күп кертергә

Димәк, фән русча укылсын диген сүз нигезсез вәсвәсәдән башка нәрсә түгел!

һәм фәннәрне татарча укытканда рус истилахатын *(терминологиясен)* әйтеп узарга, һәм русча дәрес укытканда коры «Кәҗә белән мәче» кыйссасын укып, язып кына уздырмыйча, ялгыз рус милләтчесенә генә кадерле булган Державин одаларын, «Бедная Лиза»ның характеристикасын тикшереп уздырмыйча, фәннәрнең төрле бабыннан *(мәсьәләсен)* тәкърыйргә *(аңларга)* өйрәтү һәм шул бабларда доклад, инша вә имлялар яздырудыр. Шулай иткән вакытта шәкерт фәннәрне татарча укып та, русча сөйли беләчәктер. Менә мәсьәлә бары русча дәресне куя белүдә генә. Бу бабта минем бер тәҗрибәм дә бар. 1916 ел мин Тройскида кызлар дарелмөгаллиматында *(хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йорты)* укыттым, «Вазыйфа» исемле семинариядә мөдир булдым. Бер көнне мәшһүр миссионер вә Оренбург учебный округының бер түрәсе килде. Калада хәбәр чыкты: «Менә татарча укытыла торган татар семинарияләрен ревизия ясап, әгәр белмәсәләр, ябылачак икән...»

Теге мөдһиш *(куркыныч)* нәрсә килде. Бездә табигыять татарча укыла иде. Шуннан сорарга тотынды. Кызлар вә егетләр яхшы җавап бирделәр. Түрә гаҗәпләнде; мәктәпне ябарга башка сәяси нәрсәләр генә эзли башлады. Менә бу вакыйга – яхшы гына бер тәҗрибә. Моннан башка да тәҗрибәләр бар. Мәсәлән, рус гимназиясен бетергән рус малае француз, немец телләрен тел буларак өйрәнү белән француз, немец университетларында, лицейларында дәрес укый алмыйдыр идемени? Русиядә әллә никадәр кеше шулай укымыйдыр идемени?

Димәк, фән русча укылсын диген сүз бер юк, әсассыз *(нигезсез)* вәсвәсәдән башка нәрсә түгел!

Менә моннан янә бер нәтиҗә чыга:

– Татарстанда рус вә татарларны бер үк мәктәптә укыту файдалымы, әллә татарлар өчен аерым мәктәпләр ачаргамы?

Мин янә татарлар өчен аерым мәктәпләр файдалы, дим, аның дәлилләре дә шулар:

– Программа ике мәктәптә ике төрле булырга кирәк. Чөнки мәйданда рус теле укытуның тәүмәле (объёмы) һәм аңарга бирелгән сәгатьләрнең саны тора.

– Безнең өчен русларга караганда рус теле сәгатьләре күбрәк кирәк булыр; икенчеләй, ул тел исемендә кергән дәресләрнең укытылуының ысулы вә максуды *(максаты)* башка, безне сөйләргә, укырга вә шул тел белән фәннәрне тәгъриф итәргә *(аңлатырга)* өйрәтергә кирәк. Әмма рус баласы өчен тагы да башка максатлар бар.

– Безгә татар теле вә әдәбияты кирәк. Дөрес, бәлки ул Татарстанда руска да кирәктер. Ләкин алар бу фәнне укуда татар баласы белән бергә бара алмыйлар. Нәкъ рус телендә татар баласы руснықы белән бара алмаганы шикелле.

Әгәр шул дәлилләр өстенә рус вә татар тарихы мәсьәләсен, вә гомуми тарихны укытуда ысул мәсьәләсен вә сәяси мәгълүмат биргән чакта татарга бер якта күбрәк игътибар итәргә кирәк булып та, руска башкасына әһәмият бирүне алсак, аерым мәктәпләр диген фикер тагын да куәтләнә.

Соңгы мәсьәләне бераз тәфсилләп китәргә кирәк. Мәсәлән, дин мәсьәләсен. Монда сәяси фән мөгаллиме динне тәнкыйть кылганда рус өчен аңларлык булган христианлыкны мисал итеп алса, татарныкында исә исламны алырга кирәк була.

Кереш мәкалә һәм текстны басмага
***Раиф Мәрданов** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

Гаяз Исхакый – француз журналында

Ләйсән Галиева

Күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый 1933 елның сентябрь аеннан алып 1936 елга кадәр Ерак Шәрык илләренә сәяхәт кыла. Әлеге сәфәрдән әйләнеп кайту уңаеннан Парижда француз телендә басылып килгән «Prométhée» журналының 1936 елгы 114 санында имзасыз «Гаяз Исхакый Европада» исемле мәкалә басылган. Аның француз теленнән татарчага тәрҗемәсен тәкъдим итәбез.*

N° 114 PROMÉTHÉE 19

cles l'œuvre la plus populaire, la plus aimée parmi le peuple géorgien. Ce n'est pas en vain, croyons-nous que, au cours des siècles, si ce n'est l'unique exemple dans l'histoire des peuples, tout au moins un exemple assez rare, nous voyons dans la liste des présents composant le trousseau des jeunes fiancées géorgiennes, un exemplaire manuscrit du poème de Roustaveli.

Nous avons voulu, dans ce court exposé, donner une idée de quelques traits de caractère du peuple géorgien. Nous avons entre autres signalé l'extrême tolérance dont fait preuve le Géorgien par rapport aux convictions et aux opinions d'autrui, son élévation de sentiments et les égards qu'il professe dans ses rapports avec les femmes et les enfants. Nous pensons que ce qui vient d'être dit suffit pour comprendre combien le régime bolchevik, avec son esprit de violence, d'arbitraire et de mépris envers l'âme humaine, est féroce et inhumain, combien est dur pour le Géorgien un pareil état d'esprit qui ne saurait absolument pas convenir aux traits de caractère du peuple géorgien.

JEANZET.

Ayas Ishaki en Europe

Le chef du mouvement national de l'Idel-Oural, Ayas Ishaki est arrivé à Paris après deux années de séjour en Extrême-Orient. Tous ceux qui connaissent cet infatigable champion de la liberté de son peuple, des idéaux nationaux ont accueilli avec joie Ayas bey.

Au cours de son séjour en Extrême-Orient, Ayas bey se donna entièrement à l'organisation de ses compatriotes dont le nombre atteint la quarantaine de mille.

Après de longs et prodigieux efforts, en butte aux intrigues de l'impérialisme russe de toute couleur, il réussit quand même à organiser ses compatriotes, à les grouper autour du drapeau commun de l'indépendance de l'Idel-Oural. Dispersés sur le territoire du Japon, de la Chine et du Mandchoukouo, les Idel-Ouraliens se sont groupés autour du *Milli-Baïrak*, journal créé par Ayas bey et édité par le mouvement national.

A Moukden se réunit le kouroultaï national idel-ouralien qui eut pour résultat la création d'un « Comité de culture nationale turco-tatare de l'Idel-Oural ». Ce comité dirige actuellement toutes les affaires nationales, culturelles et religieuses des Turco-Tatars en Extrême-Orient. C'est lui encore qui édite l'hebdomadaire illustré *Milli-Baïrak*.

Comme nous l'avons signalé, Ayas bey eut à lutter contre de nombreux obstacles, principalement de la part des milieux russes de toute nuance, assez nombreux en Extrême-Orient pour intriguer contre tout mouvement ayant pour but l'affranchissement des peuples opprimés de Russie. Pour ces Russes, tous les moyens furent bons, mais en dépit de tous ces obstacles, l'énergie d'Ayas bey triompha et il réussit à organiser ses compatriotes.

De nos jours, le mouvement ne cesse de s'accroître, ce qui laisse augurer du succès de l'entreprise.

Cette lutte ébranla sensiblement la

* Мусин Ф. Гаяз Исхакый: (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 118 б.; Мөхәммәтшин З. Гаяз Исхакый: шәхес, әдип, милли рәһбәр. Казан: Җыен, 2011. 28 б.

Г.Исхакыйның «Прометей» хәрәкәте һәм шундый ук исемдә чыгып килгән журналга кагылышлы эшчәнлеге, аерым мәгълүматлар белән журналыбызның алдагы санында танышырга мөмкин булачак.

Гаяз Исхакый Европада

Ике ел дәвамында Ерак Көнчыгышта булганнан соң, Идел-Урал халыкларының милли хәрәкәт лидеры Гаяз Исхакый Парижга әйләнеп кайта. Үз халкының азатлыгы, милли идеаллар хакына армый-талмый көрәш алып барган Гаяз бәйне барлык танышлары шатланып каршы ала.

Ерак Көнчыгышта булган вакытта Гаяз Исхакый үзен тулаем ватандашларын оештыру эшенә багышлый. Биредә аларның саны кырык меңгә якын.

Рус империализмының һәртөрле казынуларына юлыгып, озак кына бик зур тырышлыклар куйганнан соң, ул шулай да үз ватандашларын Идел-Урал бәйсезлегенең уртак байрагы тирәли оештыра һәм берләштерә алды. Япония, Кытай һәм Маньчжу-Го территорияләре буйлап сибелгән идел-уралылар Гаяз бәй нигезләгән һәм милли хәрәкәт тарафыннан нәшер ителгән «Милли байрак» газетасы тирәсендә төркемләшәләр.

Идел-Урал халыкларының Мукден шәһәрендә үзган милли корылтае нәтиҗәсендә Идел-Урал мәдәнияте буенча төрки-татар милли комитеты төзелә. Әлеге комитет хәзерге вакытта Ерак Көнчыгышта яшәүче төрки-татарларның барлык милли, мәдәни һәм дини эшләренә җитәкчелек итә. Нәкъ менә аның тарафыннан атналык иллюстрацияле «Милли байрак» газетасын нәшер итела.

Без алда билгеләп үткәнчә, Россиянең җәберләнгән халыклар азатлагы хакына юнәлтелгән теләсә нинди хәрәкәтне туктатыр өчен Гаяз бәйгә бик күп каршылыкларны җиңәргә, бигрәк тә Ерак Көнчыгышта шактый күп санлы һәртөрле рус даирәләре белән көрәшергә туры килә. Россиялеләр өчен барлык чаралар үтемле булып саналса да, Гаяз бәйнең дәрте җиңү яулый һәм ул үз ватандашларын бергә туплау максатына ирешә.

Хәрәкәт бүген дә үз эшен туктатмый һәм бу кампаниянең уңышына ишарәли.

Билгеле, әлеге көрәш Гаяз бәй сәламәтлегенә шактый йогынты ясый. Әмма бер ай дәвамында диңгез буйлап мәҗбүри ял итеп сәяхәт кылу аның көчен кайтара һәм ул Парижга сау-сәламәт аяк баса.

27 апрель көнне Гаяз бәй Ерак Көнчыгыштагы хәл турында лекция белән чыгыш ясый. Әлеге очрашу бик уңышлы уза: фикер алышу барышында оратор, килеп туган сорауларга аңлатмалар бирер өчен, янәдән чыгыш ясый. Җыелыш «Милли байрак» газетасы редакциясенә һәм «Ерак Көнчыгыштагы төрки-татар комитетына» котлау телеграммасы юлларга карар кыла. Моннан тыш җыелучылар Гаяз бәйнең гаять авыр шартларда, Ерак Көнчыгыштагы рус даирәләренең интригаларына каршы алып барган эшчәнлегенә карата канәгатьләнү һәм теләктәшлек белдереп калалар.

Мәкалә басмага Татарстан Республикасы яшьләр гранты кысаларында әзерләнде.
Проект номеры: 17-100-ч Г 2019. ■

«Күпме яшь күкрәкне изге дип издермәдем»*

Мирхәйдәр Фәйзи

1891 нче ел октябрь 19 (ноябрь 1ендә) рәбигыль әүвәлнең ахыр көнендә, шимбә көн кич сәгать 9да, Орски шәһәреннән 50 чакрымлык җирдәге Хөсәеновларның өлкән утарында дөньяга килдем.

Ата ягыннан нәсәбем: Мирхәйдәр бине Мостафа, бине Әхмәтҗан, бине Фәйзулла, бине Сәйфулла.

Әхмәтҗан бабайның хатыны ягыннан: Мирхәйдәр бине Мостафа, бине Гайнекамал бинте Мөхәммәдьяр мирза Урманчиев.

Фәйзулла бабайның хатыны ягыннан: Мирхәйдәр бине Мостафа, бине Әхмәтҗан, бине Назлы, бинте Сәетборһан.

Ана ягыннан нәсәбем: Мирхәйдәр бине Зәйнәп бинте Гали бине Габделмалик бине Исмәгыйль бине Габдерәзак бине Алма бине Таңчулпан бине Җанегет бине Уразгилде бине Шогай бине Шахҗамал Камаев.

Гали бабайның хатыны ягыннан: Мирхәйдәр бине Зәйнәп бинте Шәһирбану бинте Дауд.

Ата ягыннан баба, әбиләрем Казан губернасының, Чистай өязендәге, Шахмай авылыныкы булып, буыннан-буынга муллалык вазыйфасын тапшыганнар.

Әхмәтҗан бабай 1858 нче ел, апрель 25ендә, җомга көн Шахмайда вафат булган. Гайнекамал әби 1840 нчы ел июльдә вафат булган. Мөхәммәдьяр мирзаның хатыны Камилә әби 1853 нче ел гыйнвар 4ендә; Назлы әби 1852 нче елда вафат булганнар.

Ана ягыннан баба, әбиләрем Оренбург янындагы Каргалы – Сәет бистәсенеке булып, Шәһирбану әби Гали бабайга 35 яшьләрендә барган. Бабай 71 яшендә, ике күзе дә сукыр. Һәр икесенең икенче никахлары. Өч ел гына бергә торганнар. Әби, 38 яшендә тол калып, бабайның: «Миннән соң иргә барсаң, мәңге ризалыгым юк», – дигән сүзе буенча яңадан иргә бармый, 42 ел тол утырып, 80 яшендә чакта өлкән утарда, әти тәрбиясендә вафат булган.

Фәйзуллиннар гаиләсе. Сулдан басканнар: Шакирҗан, Мортаза, Мирхәйдәр. Утырганнар: Мөхәммәтгәрәй, Әхмәтгәрәй, Мостафа, Зәйнәп, Хәлимә Мөхәммәтгәрәй кызы, Шакирә. Шакирҗанның балалары Рәфгать һәм Фуат. 1912 ел

*М.Фәйзинең КФУ Фәнни китапханәсендә саклана торган «Көнлек дәфтәр»еннән

Гали бабай 1774 нче елда туган, 1848 нче ел гыйнвар 16сында җомга көн 74 яшендә Каргалыда вафат булган. Шәһирбану әби 1810 нчы елда туган, 1890 нчы ел, сентябрь 9ында утарда 80 яшендә вафат булган. Кабере утар зиратында.

Әткәем Мостафа 1835 нче ел, гыйнвар 5ендә Шахмай авылында дөньяга килгән. 19 яшенә кадәр шунда яшәп, бодай күмәче ашау идеясе белән, 1854 нче елда кечкенә арба тартып, Орск ягына килеп чыккан.

Әнкәем Зәйнәп 1846 нчы ел, ноябрь урталарында Каргалы шәһәрендә дөньяга килгән. Ике яшендә атадан калып, анасы белән Орскига күчеп килгәннәр.

Әни 17 яшьтә, әти 28 яшьтә булган хәлдә, 1863 нче ел, октябрьнең 28ендә Орскида никах туйлары булган. Корбангали хәзрәт никах хотбәсен укыган. Әти 1878 нче ел Әхмәт, Мәхмүт, Гани бай Хөсәеновларга хезмәткә керешеп, Орскидан 50 чакрымдагы өлкән утар – Күкшелне тәэсис иткән. Унике авыл җирне биләп, унбиш җирдәге утарларны идарә итеп, тоташ 27 ел бик парлак, кыйммәтле хатирәле тормыш белән яшәгәннәр. Үз карамагында утыртып тәрбияләгән агачлык, җиләк-җимеш бакчалары белән җәннәт шәкеленә кергән ямьле утарда яхшы исемнәр, матур, бай тарихлар калдырып, 1905 нче ел байдан чыгып, үзалдына дөнья көтәргә керешкәннәр.

57 ел бергә гомер итеп, әти 1920 нче ел, яңача ноябрь 8ендә (1339 сәфәр 25) дүшәмбе көн көндез сәгать 12дә 86 яшендә Орскида вафат булды.

Әни, әтидән соң сигез айдан артыграк торып, 1921 нче ел, яңача июль 21ендә пәнҗешәмбе көн төнге сәгать 12дә, 74 яшендә Орскида вафат булды.

Бик тату, тыныч, бәхетле тормыш белән яшәп, бөтен тирәгә изге исем калдырып үткән бу картларның рухлары мәңге рәхәттә гизсен!

Әти – мулла баласы заманына күрә яхшы укыган, ничектер урысчадан да беркадәр өлеш алган кеше иде. Озак заман бай хезмәтендә бик зур вә җимешле эшләр башкарып тору аркасында, соңгы көннәрен башы эшләүдән туктаган, алҗыган хәлдә үткәрде.

Әни уку, белем алыш җәһәтеннән заманның алдагы карчыкларыннан иде. «Тәрҗеман» газетасын, чыга башлаган көннән алып туктаган чагына кадәр, калдырмый укып килгән. Тарихтан, дөньяның китешеннән, хәтта сәясәттән дә яхшы ук хәбәре бар иде. Соңгы газеталарны, һәрбер чыккан җитди вә хикәя-роман китапларын калдырмый укый, аңлый һәм башкаларга сөйлидер иде. Госманлычадан зур-зур тарихларны, хыялый рисаләләрне дә тәмам аңлап укый, мин алган һәрбер романны ул миннән алда укып өлгерә иде.

Төскә матур, купшы, тәрбияле холыклы, уңган, аңлы, белемле булган әнкәем үзен белгән һәркемнең күңелендә матур тойгылар калдырып үтеп китте.

Мин әни 45 яшендә чакта, никахларының 28 нче елында унберенче һәм иң кинҗә бала булып туганмын. Иркә булып, матур, бәхетле тормыш эчендә үскәнмен. 29 яшемдә алардан аерылдым. Җылап аерылдым, йөрәгемә бетмәс хәсрәт эзләре ясалган хәлдә аерылдым. Әнинең җеназасы өстендә булып, кулымнан ләхеткә иңдереп, кәфен аша кулын тотып соңгы хушымны әйтеп аерылдым.

15 яшемә кадәр матурлыкка, ямьнәргә бай булган өлкән утарда яшәдем. Оҗмах кебек күренешле җирдә мәгъсуманә уйнап, әти-әни вә туганнарымнан сөелеп, табигать кочагында иркәләнеп үстем. Утарның үзендә бик бәхетле, мәңге якты, матур хатирәле көннәр кичерү өстендә, җылкы бәйләгән җиргә барулар, урманнарга җиләк-җимешкә чыгулар, ашлар белән кырга чыгулар, тирәдәге вак утарларга чыгулар, үзебезнең матур манзаралы тегермәнебезгә барып ятулар, кунакларга бару, кунаклар килү кебек күңелдә тирән эзләр калдырган тарихларның уку яшемә җиткәнгә кадәрен түгел, аннан соңгыларын да көне белән язып күрсәтергә мөмкин түгел.

Тарихы белән беленгән хатирәләремне терким:

1896 нчы елның җәендә, биш яшемдә чакта эти, әни апай белән бабайлар ватаны булган Шахмайга кайтканыбызны хәтерлим. Пароходта баргандагы, Чистайда йөргәндәге, Малмыжда җизниләрдә кунак булып яткандагы күренешләрнең кайсыбер җирләре күз алдыма килеп китә. Шахмайдагы туганнардан берсенең күтәреп кунакка алып баруы; бер иске өйнең яшелле-кызыллы булып торган тәрәзә пыяласы; бабайлар йортының капкасы башындагы өй формасында ясалган сыерчык оясы вә башка күренеш кисәкләре күңелдә нык урнашып калганнар. Казанда Хан мәчетен кереп карап йөрүне дә азрак хәтерлим.

1899 нчы елның көзендә утардагы язу яза белми, фәкать укырлык кына гыйлеме булган Сара абыстайга сабакка йөри башладым. Утарның бөтен ир һәм кыз балалары бергә укыйдыр иде. Тугызда барып, унда чыга, урык-сурык тараладыр иде. Бер дә укыйсым килмәү, фәкать тәти букча, матур тоткычларга кызыгып кына йөреп маташканлыгым исемдә. Апайларым вә башка зур кызларның парлап «Мөхәммәдия» укулары мине дә шул матур көйле зур китапларны күтәреп йөрү бәхетенә ирешүгә кызыктырадыр иде.

Шул ук ел октябрьнең 19ында абыстайдан сигезгә чыккан көнемдә сигез юл сабак алган идем.

Абыстайга ике ел йөрдем. Язу өйрәтү дигән нәрсә юк иде. Өйдәге абзыйлар һәм апайларның ярдәме белән язу өйрәндем. Абыстайдан әлеп-бидән төшеп, иҗек, сүрә, «Һәфтияк», «Бәдәвам», «Кисекбаш», «Ярым алма», «Көреш кадир», «Вакты сәхәр» китапларын үтеп, Коръән укый башлап, туктадым.

1901 нче елның җәендә эти, әни, Мортаза абый белән Малмыжга Сәетгәрәй абзыйның туена бардык. 10ынчы яшемдәге бу сәяхәтне яхшы гына хәтерлим. Казанда әнинең ана ягыннан туганы булган Әхмәт бай Хөсәеновларда да кунак булдык. Малмыжда Фатыйма абыстайларның зур алма бакчалы йортларында алмага гарык булып яшәүләр; әллә кайларга барулар; июньнең 11ендә Түнтәрдә туй булып, кодачалар белән бергә туйга баруым; Ишми ишанның чарлагында, никах укылып әле абзыема күренмәгән кызы – Фатыйма җиңгием белән күрешеп, аның чәй ясап эчерүе; алдыма чикләвекләр ватып куюы. «Ничә җиңгиең бар?» – дип соравына каршы: «Инде бишәү булды», – дип җавап бирүем; туйга Оренбурның Мәхмүт байлар да килүе; Ишмурадовның ике хатыны, пар киемдә һәйбәт атлар белән килү; Малмыждан кайтышлый Чистайга җизниләрдә бергә булган хәлдә килү; шәһәрдәге туганнарда кунак булып Шахмайга бару, төрлечә кунак булулар; этинең школасы, Гобәйдә абыстайлар торган тегермәнгә бару, анда шулпалы тәмле бәлеш ашаулар; ак киез эшләпә киеп кырда йөрүләр; Мәрфуга абыстайларга барулар; пароход, тимер юлларда йөрү кызыклары; күп бүләкләр, күчтәнәчләр төяп утарга кайтулар; Печмән тавыннан курка-курка кичүләр... Бар да, бар да исемдә.

1902 нче ел февральдә әни белән тегермәнгә бардык. Ак көймәгә тройка ат җигелеп, кучерда Ибрай абзый иде. Көн буран булганлыктан куркып барган әнине: «Әнә, көн ачыла, әнә, таулар күренә», – дип җуатып баруым исемдә.

Февраль 2сендә Мөхәммәтгәрәй абзыемның (ул чакта аны «Яңа парай» ди торган идек) Сәлимгәрәй исемле угылы туу мөнәсәбәте белән иде бу барыш, мин кыз балалар кебек курчак уйнарга бик һәвәс идем. Абзыемның кызы Кәримә белән көннәр буе курчак уйныйдыр идек.

1902 нче елның көзендә абыстайга йөреп укый башласам да, этиләр Орскига җибәреп укыту уена төшеп, тормыш күгемә кара болытлар тудырдылар. Минем балавыз сыгуларым илтифатсыз калдырылып, шуңа карар да бирделәр. Эти-әниләр үзләре Оренбурга Мәхмүт бай кызының туена киттеләр. Җылап, озатырга да чыга

алмадым. Ике көннән абзыемның улы белән мине өлкән абзыем (Әхмәтгәрәй) Орскига мәдрәсәгә илтте. Киткән көнне абыстайга күрешә бардык. Манзара авыр булды. Без кергәндә зур кызлардан Шәмсекамал белән Зәлифә бик моңлы иттереп «Мөхәммәдия» укыйлар иде. Абыстайның һәммә кызлардан дога кылдырып хушлашуы безнең витек күңелләрне тибрәтте. Җылап, әлвәле торган букчаларыбызны алып чыгып киттек.

Абзыем Орскида, Габдулла хәзрәт Мәгази мөдәррисенә биреп, Шәрифә исемле бер туганыбызның өенә урнаштырып кайтып китте. Елый-елый калдык. Безнең исебезне китергән абзар кебек кенә бинада Фазылҗан исемле хәлфәдән сабак укый башладык. Бу ят җирнең тормышы бик авыр булды. Әллә ни гомер елап яшәдек. Усал кала балалары безне җәберлиләр иде.

Ураза җиту белән хәлфәбезне утар мәчетенә рамазан үткәрүгә алдылар. Без дә бергә кайттык. Мондагы куаныч, сөенечнең зурлыгын язып аңлатырга диңгезләр – кара, урмандагы агачлар каләм булырга кирәк. Әниләр янында, сыйда, ямьдә, дәүләттә рамазанны үткәреп җылый-җылый тагы калага җибәрелдек. Монысының авырлыгын язып аңлатырга диңгезләр кара, урмандагы агачлар каләм булу гына да җитмәс.

Бик күңелсез... читтә йөрү япь-яшь көйгә,
Уйласам авылымдагы ямьнәрне күздән яшь килә.
Ямьле илдән аерылып мин күпме күз яше түкмәдем,
Җибәрелеп як-якка, ятлар, күпме мин интекмәдем?
Әнкәемнең, бәбкәем, дип җылмаеп эндәшкәнен
Зар булып ишетергә бер мин күпме өзелеп көтмәдем?
Күпме тәртип, күпме хикмәт мәктәптән күрмәдем?
Күпме михнәт, күпме зәхмәтләрне йөкләп йөрмәдем?
Күпме яшь күкрәкне юллар изге дип издермәдем?

Корбан гаетенә тагы утарга кайттык. Ак көймәгә пар ат җигеп, кыңгыраулар тагып ала килделәр. Әй күңелле, әй күңелле!

1903 нче ел март 3сендә Корбан бәйрәмен үткәреп, укуны дәвам иттерергә киттек. Әлбәттә, елап аерылдык.

Март 8ендә әти белән әни, Шакирҗан абзыемның балдызы Нәфисә кодачаның туена дип, Орскига килделәр. Безгә куаныч. Көн алар янында үтә башлады. Кич белән әни янында яттым. Шәрифә абыстайларга кайтып китү генә күңелне җәрәхәтли.

Туйлар үтеп, әтиләр кайтып китәр вакыт җиткәч, минем күңелемдә сафура бураннары купты. Бер унбиш көнгә булса да торыгыз, дип үгетләр дә эшкә ашмады.

Мин инде шытырдатып хатлар язам. Абзыйларым ярдәме белән алынган хикәяләрне бик яратып укыйм. Көйле китапларны укырга да бик яратам. Уенга караганда укып утыру күбрәк вакытымны ала башлады. Моның өчен, уйнарга дип чакырып кергән абзыем улы тарафыннан «кыз тәкә» дип тә аталдым.

Быелның көзендә тагы укырга киттек. Аһ, бу китүләр, авыр буладыр иде соң. Бу мәртәбәдә Мәгазиның яңа салынган мәдрәсәсенә, шунда ятып укырга бирделәр. Бина яңа булса да, уку чыкырдап торган иске булган бу мәдрәсәнең чаршаулар белән бүленеп беткән эчендә без дә ике аршын урын биләдек. Аш пешереп, самовар куярга бер фәкыйрь шәкерт билгеләнде. Ләкин без бу тормышта бер генә атна чыдап тора алдык. Беркөнне нәрсәләребезне күтәрдек тә, үз йортыбызда фатир торучы Гайнулла бабайларга күчеп бардык. Әтидән курыксак та, мәдрәсә тормышы безнең нәзберек табигатьне чыдатмады. Гайнулла бабайлардан йөреп укый башладык. Бу уңайрак булып калды. Хәзрәт белән этинең ачуын да җиңел үткәрдек.

Бу ел мин Зыя исемле бер хәлфәдән укыйм. Аның белән былтыргыча рамазанда

утарга кайтып үткәрдем. Гаеттән соң елый-елый тагы киттем. Корбан бәйрәмендә сөенә-сөенә тагы кайттым. Бу инде 1904 нче елда иде. Февральнең 11ендә бәйрәмгә дип утарга кайттым. Язны Орскида үткәреп кайттым.

1904 елның җәендә, Оренбурдан килеп бездә кунакта яткан туганыбыз Зәйнәп абыстай, Закирҗан абый, Габдулла, мин Оренбурга Мәхмүтгәрәй абзыйларга кунакка бардык. Минем инде кайда гына барсам да, әниемнән аерылганда җылавым җылау иде. Әнигә бик нык бәйләнгән идем. 13 яшьтә булсам да, әнинең итәгеннән яңа төшеп, янында ятудан да яңа аерылган идем әле.

Закирҗан абый Петербургка укырга китте. Без Оренбурда ике айдай тордык. Китергән атлар белән кайтам, дип җыласам да кайтармадылар. Җылата-җылата кунак иттеләр. Шулвакытта Хәдичә җиңгидән Руфгать туды. Шул мөнәсәбәт белән Орскидан безнең атлар белән киткән кодагыйлар белән без Орскига, аннан утарга кайттык.

Көз тагы калага мәктәпкә илтеп тыктылар. Бер генә дә укыйсым килми. Килер дә иде, бәлки, әнидән, утардагы иркә тормыштан аерылуы кыен шул. Җитмәсә, мәктәп сөйкемсез, бер дә күңелемне үзенә тартып тормый.

Мин инде, татар теленекен белмәсәм дә, гарәп теленең сарфын укыйм. Хәер, моны да белмим белүен, әмма укыйм. Фарсы теле белән язылган «Шәрхе Габдулла»ны күтәреп йөрүне бер ганимәт санап, мәгърур булып йөрим. Дәресемне белмәвем өчен шелтәгә очрамыйм. Гәрчә служащий баласы булсам да, бай баласы дип карарга өйрәнгән халык башкаларга төшкән таяктан мине мәгъфу тота (ягъни, хәлфә Мирхәйдәргә сукмаган. – *Р.Ш.*).

Бу ел да рамазанда хәлфәбез белән утарга кайттык. Бәйрәмнән соң тагы килеп, мәктәп юлын таптаудан гыйбарәт булган кәсепкә тотындык. Гайнулла бабайларда яхшы гына торабыз. Бибикамал җиңги – уңган, күңелле генә хатын. Өйдән тәмле мәмиләр, хосусан күңелемә нык сеңгән майда пешерелгән мүк җиләге самсасы, күкәй клендере килеп тора. Әти килсә, югары өйгә менеп аның янында, яңа агылган салкын өйдә тире юрганны ябынып, рәхәтләнеп, өйгә кайткан кебек кунып ятабыз. Идеал йолдызыбыз булып кибетләрдә күзне яндырып торган берсе бер тиенлек ирисны да без әти килсә акча белән бәреп чыгабыз.

1905 нче ел, гыйнвар 26сында, чәршәмбе көн Корбан гаетенә тәгътыйль[1] булды. Өйгә кайтып килдем. Тагы күземнең әллә никадәр яше исраф ителде. Арба юлы белән җәйге тәгътыйльгә кайттым.

Бу ел әти байдан чыкты. Урынына Оренбурдан икенче управляющий килде. Күңелләргә бетмәс-төкәнмәс сөекле, кыйммәтле бизәкләр багышлаган утардан, туган-үскән илдән аерылу көннәре җитте. Бу вакыйга бигрәк минем күңелемне моңландырды. Әтиләр үз йортыбызга күчеп чыгудан алда, миңа Шакирҗан абзыйларым белән Орскига укырга китәргә туры килде. Иртәгә китәбез дигән көннән алып зур тәэсирләр белән һәммә җирләрне бер-бер күреп исәнләшеп йөри башладым. Һичбер ташлап китәргә теләмәү тойгысы уянды. Шулкадәр ямьле, шулкадәр җагымлы җирне, һәр карыш җирне беркадәрле хатирә белән өртелгән мөкатдәс кәгъбәне, матур бакчаларны, ямьле су буйларын, торган өйләрне, балалыктан алып күңелгә гаҗиз булып урнашкан утарны ничек ятларга калдырып китәбез, дип, рухан җылап йөрдем. Кич белән, ахыр кунуларым, дип, өлкән яктагы кәнәфи буеннан җәелгән урында җылап яттым. Кич белән Таифә абыстай ясаган каймаклы катыкларны ашап яткан, җиңгиләрнең шак-шак шакылдатып – сәхәр булды, дип әтиләрне уяткан; өй янындагы гөлбакчасында иртә чәйне эчүләр; Пастухов утарына Әсхәб җиңгиләргә

---

[1] Тәгътыйль – ял итү, каникул.

барып җырлашып, кымыз эчкән хатыннар мәҗлесе; читтән килгәндә җырактан ишетелгән ямьле кыңгырау тавышлары кебек күренешләр чуалып алдыма килә. Моңаям. Бөтенесен сагынам. Калдырырга кызганам.

Иртәгесен сентәбернең 25ендә микән, тагы аръякларны күреп, хушлашып, бәхилләшеп кайттым. Актык чәй дә эчелде. Кыңгыраулары шалтыр-шолтыр итеп көймәгә җигелгән атлар хатыннар ягы ишегалдына килеп туктады. Өлкән якта җыйналып дога кылганда ук мин тирән, эчке тойгы белән яшькә күмелдем. Һушсыз булыр дәрәҗәдә җылап, туган-үскән җирләрне, әти-әни тарафыннан төзелгән җәннәтне ташлап китәм. Утар күздән югалганчы әйләнеп карый-карый:

Безләр утарлардан аерылдык,
Мисле канатлардан каерылдык, – дип җырлап бардым.

Башы исемдә калмаган бу җыр, минем көйле, кафияле әсәрләремнән тәүгесе булса кирәк.

Шакирҗан абзыйлар Орскида үз йортыбызда торалар. Миңа бу ел уңайрак булды. Гел утарны сагынып, моңаеп, әллә нинди җырлар чыгарып йөрим. Уку дәвам итә. Тәркиб укыйм, хәзрәт алдында дәрестә утырам. Гарәп теле белән язылган чуалчык нәхү-мәхүләргә күңелем дә бирмим, белмәем дә. Белмәем, тырышмаем өчен шелтәгә дә очрамыйм. Бөтен шәкертләрдән аерым бер кагыйдәм: чәршәмбе көн хәзрәткә илле тиен садака бирәм дә, шуның шәфәгате беләндерме, аңламаган, аңларга да теләмәгән хәлдә алга барам.

Һәрбер чыгып торган хикәяләрне калдырмый укыйм. Шул ел гына чыга башлаган татар газеталарын яратып, көтеп алып укыйм. Шуларда язылган әллә нинди тәртипле мәдрәсәләрдә укысаң иде, дигән бер тойгы уяна башлады.

Бу ел уразада утарга кайту эләкмәде. Бәйрәмгә генә кайттым. Әтиләр үзебезнең йортта торалар иде. Бу яңа тормыш үзенә аерым бер ямь бирде. Яңа доверенныйның угылы Газиз байлар йортына алып кереп чәй эчерде. Үзебез торган мөкатдәс өйләрне күреп куанып һәм моңаеп чыктым.

Өйдәге тормышта үзгәреш юк. Тирәкләргә күмелгән байлар йорты булмаса да, башка яклар борынгыча. Анда торганда бәйрәмнәрдә пешә торган чәкчәге, чәлпәк, җуача, казан лавашы, майда пешергән самса, паштет, лаваш, баллаган лакша, кош теле, бавырсак, каты, хәлвә, кортлы май, каклы майлар монда да бар.

Бәйрәмнән соң әни белән Сабирә җиңги калага килеп кайттылар.

Бу кыш мин мөхәррир булырга һәвәсләнә башладым. «Татар туе» исеме белән бер вакыйгадан алып язган пьесамны җиңгиләремә укып, аларны хәйран да калдырдым. Бәетләр, шигырьләр язуга да бирелеп киттем.

Җәй көнендә чыгамын мин урманга,
Төрле-төрле матур кошлар була анда,
Кайсы оча, кайсы куна, кайсы сайрый,
Хозурланып, яшь күңелләр тула анда, –

дип бер, гыйшкый шигырь дә тәртип итеп ташладым хәтта. Бу вакыт миңа ундүрт яшь тулган иде.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

ТАССР

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА – 100 ЕЛ

Яшел тышлы китап

Хәбир Ибраһим



Әлеге китапның ничек итеп кулга килеп кергәнен хәтерләмим дә. Өйдә китап күп түгел: эти китап җыйнарга яратмады. Мин әле мәктәп баласы гына, бу дөньяда күп нәрсәләрне аңлап та бетермим. Бер урыннан икенче җиргә, бер киштәдән икенчесенә күчеп йөргән яшел тышлы китап шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең сайланма әсәрләре булып чыкты. Сатып алынган түгел, ә бүләк ителгән. Элегрәк мәктәпләрдә китап бүләк итү йоласы бар иде, чөнки китап – чын мәгънәсендә бүләк булып саналды. Яшел тышлы китапны да Таһир абыема сыйныфташ кызлары бүләк иткән икән. «*Классташыбыз Таһир!* – дип язылган тышлыкның артында. – *Сине бәйрәмебез – Совет Армиясе көне белән тәбрик итәбез. Укуыңда зур уңышлар, алдагы көннәреңдә туган илнең тынычлыгын саклаучы, кыю, сәламәт һәм бәхетле булуыңны телибез! 10 класс кызлары. 23 февраль, 1970 ел*». Абыем минем кебек шигырь укырга яратмады, Совет Армиясе сафларына хезмәт итәргә киткәч тә яшел тышлы китапны үзе белән алып китмәде, йөртмәде, билгеле. Кыскасы, Сәгыйть Рәмиев беркая да китмәде, ул бездә, өйдә калды. Яшем буенча мин абыйдан алты яшькә кечкенә, ике апам да, абыем да өйдән чыгып киткәч, әле миңа үземә озак кына мәктәп юлларын таптарга туры килде...

Яшел тышлы китап минем кулыма килеп кергәндә миңа бер унбер-унике яшьләр булгандыр, шәт. Сәгыйть абзыйның «Сайланма әсәрләре» – шигырьләр, хикәяләр, пьесалар тупланган әлеге китабы Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1969 елда басма рәвешендә чыгарылган, галим М.Гайнуллинның кереш сүзе белән дә баетылган.

Нәрсәсе белән шулай җәлеп итә алды икән соң мине бу басма? Беренчедән, китап эченә куелган фотосурәте белән дер, бәлкем. Сәгыйть Рәмиевнең әлеге гаҗәеп күркәм фотосы шагыйрьлек җене кагылган егеткә тәэсир итми калмагандыр, дип уйлыйм. Әйе, һәркемгә дә мәгълүм: иҗат юлына аяк баскан һәрбер кеше үзенә кумирлар эзли башлый. Гомер юлында, билгеле ки, алар гел алмашынып, үзгәреп тора. Ләкин беренчесен һәм иң кадерлесен беркайчан да оныта алмыйсың. Уйчан күз карашы, дулкынланган куе чәчләр, нурлы йөз, зәвык белән тегелгән модный фрак, бант, – менә ул чын шагыйрь, дигән тәэсирле уйлар тудыра. Икенчедән... шигырьләре... Мәктәп программасына кердеме икән ул шигырьләр, тәгаен генә хәтерләмим. Ләкин совет мәктәбендә «кызыл шигырь»ләр укып үскән гади авыл малаен аның үзенчәлекле «Алданган»,«Син», «Мин», «Ул», «Дөньяга», «Таң вакыты», «Авыл» һәм башка шигъри әсәрләре, бөтереп алып, чын шигърият дөньясына алып керде. Пессимизм – төшенкелек рухында иҗат ителгән әлеге шигырьләр, билгеле, мине ул яктан гына түгел, ә икенче ягы белән дә, йөгерек, үткен теле белән дә җәлеп итте. Алар гаҗәеп төгәл, җанлы, көчле яңгырашлы иде. Мәсәлән:

Бетте, төштем, үлде рухым,
Калмады һич рәхәтем,
Көн авыр, төн бер кабер, бер
Ел тоела сәгатем...
(«Алданган»)

яки:

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда...
Нинди тын һәм нинди буш!
(«Авыл»)

Баштарак мин үзем дә Сәгыйть Рәмиев стилендәрәк яза башладым, 18-20 яшьләрдә язылган шигырьләремдә аның йогынтысы көчле булды. Соңрак, каләмемне чарлап, иҗатта үз юлымны тапкач, мин аңардан әзрәк кенә арындым да кебек. Тик иҗатымда әлеге төшенке рухның эзләре барыбер калды. Тик иң мөһиме: шагыйрьнең йөгерек телен дә саклап кала алдым, дип уйлыйм.

Шагыйрь Сәгыйть Рәмиев үз заманы өчен шактый прогрессив, алдынгы карашлы, халык арасында тансык шәхес була. Ул татар әдәби телен баету һәм аның хәрефләренә реформа кертү мәсьәләләрен күтәреп чыга. Шул елларда ук гарәп хәрефләрен ташлап, латин хәрефләренә күчәргә дигән тәкъдимне дә кертә. Ул халык алдында да, шагыйрь буларак, шактый күп чыгышлар ясый, халык аны үз итә, ярата. Шагыйрь 1936 елның 16 мартында Өфе шәһәрендә үпкә авыруыннан вафат була.

Сәгыйть Рәмиев, әлбәттә, зур һәм үзенчәлекле шагыйрь. Рус тәнкыйтьчесе А.Пинкевич егерменче гасыр башында аның турында: «*С.Рәмиевнең кайбер әсәрләре үзенең юнәлеше белән Аурупа әдәбиятының яңа үрнәкләренә якын*», – дип язып калдырган. Бу, чынлап та, татар шагыйре өчен зур бәя. Һәм без, бер дә тартынмыйча, аның иҗаты да тиңдәшсез һәм мәңгелек, дип әйтә алабыз. ■

Безнең заман
һәм замандашлар

Роза Хәмидуллина

Миләүшә

Күбрәк аралашкан кешеләрем Миләүшә белән Тәгъзимә апа булды. Пляжда мин гел алар янында. Тәгъзимә апа Миләүшәнең әнисе булып чыкты бит! Аларның бик гыйлемле, затлы ханымнар икәнен башта ук тойдым. Миләүшә – ике югары белемле кыз: университетның рус теле, педагогия институтының кичке француз бүлекләрен тәмамлаган. Үзара сөйләшкәндә, өйләрендә калган туннарын көя ашамасын өчен нәрсә кую турында кайгыртуларыннан, тормышлары җитешле икәнен аңладым. Ул вакытта мутон туннар кыйммәт, аны сирәк хатын-кыз кия иде. Миләүшәнең фотоаппараты да бар, анысы да искиткеч кыйммәтле әйбер, бик сирәк кешедә генә. Нәрсә турында сүз китсә дә, Миләүшәнең күп нәрсәдән хәбәрдарлыгын, зыялылыгын тойдым. Алар үзләре күп сөйләшмиләр, мин исә кешедән төпченә белмим, артыгын кызыксынучан әрсез түгел. Шул сәбәпле, Тәгъзимә апаның – атаклы шагыйрь Шәйхи Маннур хатыны, Миләүшә – аның кызы икәнен соңрак белдем.

Бу язмама тотынгач, Миләүшәнең үзен күреп сөйләшәсем килде! Миләүшә Шәйхиевнаның Казан дәүләт мәдәният институтында чит ил әдәбияты буенча укытканын, зур галимә – филология фәннәре кандидаты икәнен белә идем. Моннан илле ел элек язылган адрес та, телефон номеры да искергәнен аңлыйм, билгеле. Ләкин миңа Миләүшә Шәйхиевнаны табу авыр булмады. Беренчедән, ул – республикада танылган шәхес; икенчедән, хәзерге элемтә фантастикага тиң! Телефон номерын җыйдым да дулкынланып көтәм.

Исәнләшеп, кем икәнемне, ни өчен шалтыратуымны аңлаттым. Таныдымы икән, юкмы икән, бик хисләнеп:

– И күңелле чаклар! И яшь чаклар! Бер очрашып, рәхәтләнеп сөйләшергә иде дә... Авырыйм шул әле, – диде.

Озак кына бик якын итеп сөйләштек. Миләүшә Шәйхиевна, Казан дәүләт мәдәният университетында, ачылуыннан башлап, әдәбият һәм сәнгать тарихы кафедрасында эшләве, Идел буе халыкларының культурасы һәм сәнгате, әдәби багланышларның бер-берсенә тәэсире турында фәнни эшләр алып баруы турында сөйләде. Фән белән нәтиҗәле шөгыльләнгән, монографияләр язган, дәреслекләр, методик кулланмалар төзегән. 1971 елда бөек язучыбыз Галимҗан Ибраһимов иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклаган. Бу хезмәт бик күп тырышлык, үҗәтлек сораган: язучының әсәрләрен төп нөсхәдә уку өчен, гарәп язуын, латин графикасын өйрәнгән. Болгариядән башка да бик күп Европа илләренә сәяхәт кылган, күргәннәрен студентлар белән уртаклашкан. Тирән белемле, сөйкемле ханым шәкертләренә гүзәл үрнәк булгандыр, дип уйлыйм!

Миләүшә ханымга рәхмәтле булып, сәламәтлек теләп хушлаштым. Гомер бушка үтмәгән... Чибәр, талантлы татар кызы галимә Миләүшә Маннуровна иленә, халкына гомерен багышлаган, тырышып хезмәт иткән, зур уңышлар яулаган! Замандашым белән горурланып язам бу сүзләрне, үзебез яшәгән заманга хәерхаһлы булып!

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

Бондюг кызлары

Бондюг кызлары – Фаилә, Флера, Миңнур белән бик дуслаштык. Кызларның чит илгә чыгуы беренче генә түгел: алар инде өчәүләп Чехословакиягә, Германиягә барырга өлгергәннәр. Шаяннар, яшьтәшләр, инженерның эш хакы әйбәттер, күрәсең, җәй саен ял алып, дөнья гизәләр икән. Безнең отельдан ерак түгел төзелеш бара – яңа бина төзиләр. Анда эшләүче төрек егетләре минем кызларга гашыйк булдылар. Әбәт вакытында килеп, саклап, көтеп торалар. Бераз русча беләләр. Кызларны рестораннарга чакыралар. Озын гына буйлы, яшькә өлкәнрәк Сәлим исемлесе Фаиләгә үлеп гашыйк булды. Кояшта янып каралган, йөзендә җыерчыклар сизелә. Өйләнмәгән бу егерме сигез яшьлек егет Фаиләгә кияүгә чыгарга тәкъдим ясаган. Беркөн шулай без ресторанннан чыгуга, Сәлим, урта яшьләрдәге абыйсы белән, Фаиләне көтеп тора. Сәлим як-ягына карана, түземсезләнеп, уфтанып:

– Килмәде, килмәде! – ди.

Сәлим җиде класс тәмамлаган, төзелештә эшли. Ул инде план корган: «Фаилә риза булса, аның белән Төркиягә китәбез. Быел ноябрь аенда Болгариядән җиде йөз мең кеше Төркиягә китәчәк», – ди.

– Сез кайда тудыгыз? – дип сорадым.

– Болгариядә.

– Сезгә монда начармыни? Бу бит туган илегез!

– Анда да туган ил!

Менә ничек тарта кешене ата-баба җире! Ничә йөз ел яшәгән төрекләр туган җирләрен ташлап китәләр! Безнең дә дөнья буенча таралган милләттәшләребез Татарстанга кайтса, ничек булыр иде икән?!

– Фаилә Төркиягә барырга теләмәсә, нишлисең? – дип сорыйбыз Сәлимнән.

– Монда калабыз.

– Монда калырга теләмәсә?

– Советлар Союзына барабыз!

Барысына да риза гашыйк Сәлим!

Фаилә килгәнне күргәч, Сәлимнең йөзе балкыды, кулларын өскә күтәреп: «Мәшалла! Мәшалла! Фаилә килде!» – ди. Кыз уңайсызлана, кияүгә чыгу аның уенда да юк, гашыйк та түгел, теләр-теләмәс кенә сөйләшә. Акыл утырткан югары белемле инженер кыз үз илен ташлап нишләп чит илгә китсен! Бондюгта татар егетләре бетмәгән! Бер-ике очрашу – гөнаһсыз курорт романы гына бит ул кызлар өчен! Алай дисәң... Ихтимал, егетнең хисләре бик тирәнгә, йөрәк түренә үк үткәндер?!. Без киткәндә Фаиләне озатырга килгән Сәлимнең йөзе – моңсу, карашы – ялварулы, кара күзләре чарасызлык, өметсезлектән көйриләр иде...

Капут

Безнең пляжга якын гына – немецлар урыны. Беркөн диңгездә йөзеп чыктым да кызынырга яттым. Кемдер кычкырыбрак миңа эндәшкән кебек тоелып күземне ачсам, якында гына бер адәм: «Капут, капут!» – дип, комга төртеп күрсәтә. Күзлегемә яткан-мын икән. «Күзлегеңне ватасың!» – дип кисәтүе икән. Немец абзыйга: «Данке шөн!» – дигән булдым. Мәктәптә немец теле укыган идек. Бик тә юан хатыны белән кызынып яткан карт кына нимес абзыйның ботында тирән яра эзе чокыраеп торганын күрдем. «Безнекеләр тамгасы!» – дип уйладым, канәгатьлек белән. Ул яраның англичаннар яки французлар снаряд ярчыгы булу ихтималы башка килми, «безнең илгә килеп, безнекеләрне үтереп йөргән», дигән уй гына дөрли! Безнекеләр кирәген биргән! Немецларны яратмыйм. Хәтерем әйбәт минем: сугыш башланганда миңа алты яшь иде,

халкыбыз кичергән газапларны белеп, күреп, явыз дошман – немец фашистларына ачы нәфрәт белән үстек без. Ул нәфрәт күңелебезгә гомерлеккә сеңеп калды. Аларны гафу итәрлек түгел...

Болгар акчалары

Болгарларның акчалары лев, дип, вак акча стотинка дип атала. Бүләкләр, сувенирлар алыр өчен, безнең йөз дә ун сум акчаны левларга алыштырдылар. Аларның акчалары безнең рубльдән кыйммәтрәк йөри икән. Килгәнче инструктаж үткәрделәр: фанер чемодан алмаска, артык акчаларны Одессада банкка салырга; баргач та акчаларны тотып бетермәскә, чит ил кешеләре белән элемтәгә кермәскә. Нейлон күлмәкләр модага кергән заман, хатын-кызлар ап-ак ирләр күлмәкләренә, блузкаларга капландылар. Ильясның нейлон күлмәкләре бар, шуңа күрә миңа башка әйбер кирәк. Соңгы вакытта джерси пальто модага керде. Мин иремә пальто алырга булдым. Бер ел элек – 1966 елда Ильяс, Германиягә баргач, бер гүзәл, нәфис нимес кызына кидертеп карап, Лейпциг ярминкәсеннән миңа изүеннән биленә кадәр вак кына ак сәдәфләр тезелгән сыек яшел салат төсендәге искиткеч матур күлмәк, биек шпилька үкчәле көрән замш туфли алып, үзенә берни алмаган иде. Мин бирегә шул күлмәк белән туфлиләрне киеп килдем! Иремә ул пәлтә бик килеште, яратып киде. Чит илгә барып, бүләксез кайталармыни! Болгариягә без Ильяс белән парлап барырга теләгән идек тә, иремә рөхсәт итмәделәр: чит илгә ел саен җибәрмиләр икән!

Онытылмас мизгелләр

«Балчык шәһәренә экскурсия», – дигәч, шаккаттым! Минем Ильясым да Балчык авылында туган, Кама Тамагында!

...Балчыкка экскурсиягә барабыз. Автобусыбыз, серпантин ясап, тауга күтәрелә. Өстә нииндидер сыек-яшел томан җәелгән, хәзер шул томанга якынлашабыз... Барып җитәрәк кенә Христина аңлатты: «Каршыбызда – тәмәке плантациясе. Болгариядә иң югары сортлы тәмәке игәләр. Сигаретлар күпләп экспортка китә. Илнең экономикасы өчен бик әһәмиятле производство. «Күз күреме җирдә зур аш тәлинкәсе чаклы эре, калын, симез-сусыл яфраклы, юан сабаклы тәмәке күкрәп чәчәк атып утыра! Кыңгырауга охшаган вак кына сары чәчәкләреннән куе хуш ис таралган. Кемдер, шаяртып: «Юньле әйбер булса, бу кадәр ук уңмас иде!» – дигәч, рәхәтләнеп көлдек.

Балчык – нәкъ диңгез буенда. Монда безгә Румыния королевасының сараен күрсәттеләр. Кайчандыр бу җирләрне Румыния тартып алган булган. Соңгы сугыштан соң, ул Болгариягә кайтарып бирелгән. Әлеге бина Мәскәү, Ленинград сарайлары белән чагыштырырлык түгел, билгеле. Монда минем исем киткәне – кактуслар бакчасы булды! Шундый матурлык дөньяда бардыр, дип кем уйлар! Ничә төрле, нинди экзотик чәчәкләр, ничек алар һәммәсе шулай берьюлы чәчәк аткан?! Кактус бит чәчәкне сирәк ата. Нинди җете төсләр: кан-кызыллары, алсулары, сарылары, алтын төсләләре... Җаннары бардыр боларның, без сокланганга куаналар бугай! Мондый матурлык яңадан булмас! Көн буе күзеңне алмый карап утырсаң да туймассың! Безнең бәхеткә чәчәк атканнардыр!

Шәһәрдән безне башка маршрут белән алып кайттылар. Христина тыныч кына ял итеп утыра. Менә автобус, тормозларга баса-баса, түбәнгә төшә. Бераздан юл буенда тәбәнәк кенә агачлар арасында кәрҗин тоткан хатын-кызлар күренде. Христина Дмитриевна торып басты да, елмаеп: «Персик плантациясен күрәсегез киләме?» – диде. Бу аның сюрприз ясавы иде. Кемнең инде күрәсе килмәсен! Автобустан тиз генә коелдык. Христина кисәтергә өлгерде: «Агачларга да, коелган җимешләргә дә тимибез, теләсәгез, сатып алырга мөмкин!» Агачларга карап каттык: тәбәнәк

кенә яшь агачларны кызыл-кучкыл персиклар сырган, ботаклар күтәрә алмыйча сыгылган, һәрберсенә терәү куелган, сынганнары да бар. Җир тулы коелган персик... Шаклар каттым! Мин бит «әрәмә корткасы» – җиләк-җимеш җыярга бәләкәйдән үк яратам, җәй буе урманда йөрим, башкаларның чиләге ярты булганда, минеке тула яза! Ә мондагы җиме-е-еш!!! Эх!.. Без чиратка тезелеп бастык. Персик тутырылган тартмаларны озын-озын рефрежераторларга төйиләр. Машиналар турыдан-туры чит илләргә экспортка илтә икән. Тәмәке кебек үк, җимешләр дә Болгариянең бюджетын тулыландыра, дип аңлатты гидыбыз.

Сатучы безгә кәгазь пакетларга салып үлчәде (полиэтилен юк әле ул чакта!). Автобуска кереп утыру белән, кытыршы персикка тешләрне батырдым, ушыңны алырлык сок сыгылып чыкты! И, аның тәмлелеге! Өлгергән, яңа гына җыелган мондый җимешне яңадан очратканым юк. Беркем сөйләшми, сабыйлардай йотлыгып оҗмах җимеше ашыйбыз. Хәзерге кибетләрдә сатыла торганы гел башка... Персик татарча шәфталу икән. Без Болгариядә ашаган кебек булмаса да, хәзер чит илләрдән төрле сортлары кайта! Имин булсын шәфталу бакчалары!

Бөек Октябрь революциясенең илле еллыгы

Мең тугыз йөз алтмыш җиденче елда Октябрь революциясенә илле ел тулды. Бу зур бәйрәмгә хәзерлек СССРда гына түгел, бөтен социалистик илләрдә бара иде. Көчле иде ул лагерь. Без моны Болгариядә тойдык. Шулай беркөнне бездән ерак түгел пляжда бер төркем яшьләр волейбол уйныйлар, көләләр, шаяралар. Кызларның күбесе җирән, сары чәчле, егетләр – кара чәчле, барысы да русча сөйләшәләр, шактый өлеше акцент белән. Кызлар Чехословакиядән килгәннәр, егетләр болгарлар икән. Шәһәргә чыккач, шаккатып йөрибез – бар нәрсә дә бездәгечә: кибеттә – безнең «Мир» холодильнигы, урамда – безнең «Москвичлар», «Волга»лар, хәтта «народная милиция» дә шундый ук формада, төсләре генә зәңгәр, безнекеләрнең – яшел.

***

Болгар халкы безгә бик яхшы мөнәсәбәттә. Россия белән Болгария дуслыгы хатирәләрен болгар халкы бик кадерләп саклый. Төркия коллыгыннан азат итү сугышларында рус солдатлары күрсәткән батырлыклар өчен Шипка тавы өстендә генерал Брусиловка мемориаль һәйкәл куелган. Икенче Бөтендөнья сугышы барышында Германия буйсындырган илләрнең солдатларын көнчыгыш фронтка, Кызыл Армиягә каршы сугышка җибәрә: Италия, Румыния, Венгрия солдатлары безгә каршы сугышалар, әмма Болгария ничек итсә итә, бер солдатын да Кызыл Армиягә каршы сугышка җибәрми. (Ул вакытта Болгария белән Борис патша идарә иткән дип истә калган.)

...Пловдив шәһәре янындагы биек тауда постаментта иңенә солдат шинеле, башына йолдызлы пилотка кигән совет солдаты тора... Болгарияне немец-фашистларыннан азат иткәндә һәлак булган меңнәрчә совет солдатларына куелган бронза солдатны рәхмәтле болгар халкы, яратып, «Алеша» дип атый. (Аңа багышланган җыр да бар.) Балкан тауларында күпме газизләребез башларын салган...

***

Безнең өчен оештырылган мәдәни чаралар Октябрь революциясенең 50 еллыгына багышланган иде. Һәр тамаша алдыннан сәхнәгә чыгып, зур тантана белән шул турыда игълан итәләр. Биредә башка җирдә күрергә мөмкин булмаган сәнгать коллективларының чыгышларын карадык. Минем өчен бу искиткеч зур бәйрәм булды! Зур сәнгать – җыр, музыка, театр – тормыш яме бит ул!

Көндәлегемнән: «23 июль. Яңа гына чехлар концертын тыңлап кайттык. Прагадан килгән яшьләр оркестры хезерге заман көйләрен башкарды. Оркестрда кызлар күп! Искиткеч матур көйләр тыңладык.

27 июль. ГДРдан килгән яшьләр ансамбле концертын карадык. Акапелла! Дулкынландыргыч саф тавышлар, музыка кораллары кушылмагач, ничек матур яңгырый! Кеше тавышы, чыннан да – дөньяда иң камил, иң мөкаммәл инструмент! Халык җырлары аеруча матур, моңлы! Һәрбер халыкның үз моңы: немесләрнең дә халык җырлары күңелнең кылларын тибрәтерлек... Алардан соң Софиядән килгән яшьләр бию ансамбле чыгыш ясады. Күз явын алырдай милли киемнәр кигән кызлар-егетләр – дәртле, уттай кызу биюләр башкардылар! Көйләре безнекенә дә охшап китә! Музыка кызганнан-кыза бара, сәхнәдә өермә, диярсең – аяклар җиргә тими, очалар гына! Могҗиза! Тамашачы хәйран калып, һушы китеп карый. Артистларны җибәрмичә, кабат-кабат сорыйбыз. Яшьләр бит, кыстатмыйлар...»

Андый зур сәнгать кичәләре күп булды.

«Ловци на бисери»

Болгар телендә Ж.Бизе операсы шулай атала, татарча «Энҗе эзләүчеләр» буладыр. Варнага шул исемдәге операны тыңларга культпоход оештырылачагын белгәч, бик сөендем: минем ул операны күргәнем-тыңлаганым юк, ләкин радиодан Надир ариясен еш тапшыралар, миңа бик ошый, яратып тыңлыйм. Спектакль ачык һавада, җәйге театрда булды. Декорацияләр, костюмнар әкияттәгечә матур, сихри музыка тәэсире тамашачыны спектакльгә бөтереп алып керде.

Ләйлә белән Надир партияләрен бик көчле солистлар башкарды. Мин ярата торган арияне башкарганда, солист иң югары нотаны җиңел генә, көчәнмичә генә зеңгелдәтеп тәмамлап куйды, тамашачылар, «бис», кычкырып, алкышларга күмделәр! Нинди театр гастрольләре икәнен хәтерләмим, опера болгар телендә барды. Оркестр җырчыларның тавышын басмый гына бик оста уйный. Бөтен дөньяга данлыклы әсәрне, ниһаять, тыңлавыма, күрүемә шатландым, эчке дөньям байый төшкән кебек булды, гүя рухи мирасыма кыйммәтле энҗе бөртеге өстәлде...

Музейда

Варнада Болгария хәрби диңгез флоты музеенда кызыклы, гыйбрәтле экспонатлар күрдек. Музейга беренче материалларны Россия биргән. Болгарияне төрек изүеннән азат иткәнче, болгарларның бер кораблары да булмаган. Россия Болгарияне азат иткәннән соң (1878), берничә хәрби корабын болгарларга биргән. Менә шуннан Болгария флотының тарихы башланган.

Бер стендта броненосец «Потемкин»нан дүрт матросның фотоларын күрдек. 1905 елда Россия Кара диңгез флотында «Потемкин» дигән корабльдә диңгезчеләрнең восстание күтәрүләрен, восстаниенең канга батырып бастырылуын, бик азлар гына котылып калуын тарих һәм шул исемдәге фильм буенча беләбез. «Потемкин»нан дүрт матрос, Румыния аша качып, Болгариягә чыга һәм калган гомерләрен Болгария гражданнары хокукын алып яши. Болгариянең аларны үз канаты астына алганын белү күңелебезгә хуш килде. Илләребезнең тарихи дуслыгы, уртаклыгы, болгар бабаларыбызның кардәшлеге белән горурланып йөрдек.

Карнавал

Болгариядә һәр елны үткәрелә торган карнавал «Бай-Ганю» дип атала икән. Бу гаҗәп матур халык бәйрәме «Алтын ком» курортында үтте. Барлык шәһәрләрдән, Софиядән халык җыелган. Варнаны Болгариянең җәйге башкаласы, диләр.

Мөслим академик хоры Чехословакиядә. 1976 ел

Туристлар карнавалда катнашсын өчен, Варна театрларыннан бик күп костюмнар китерделәр. Һәркем үзенә ошаганын сайларга мөмкин иде.

Менә көчле прожекторларның уты, диңгез өстен кисеп, ерак-еракка сузылды. Карнавал колонналары урамнар буенча ага: болгар милли киемнәрендәге ирләр, хатын-кызлар, гусарлар, йөгәннәре ялтырап торган тәңкәләр белән бизәлгән атларда борынгы яугирләр, куркыныч Баба-Ягалар, кызыл тәнле индеецлар, авызларыннан ут чәчеп торган өч башлы аждаһалар, алмагач астында – Адәм белән Һәва; төрле рестораннар үз формалары белән чыккан; чегән оркестрлары үз биючеләре белән җырлап-биеп узалар; бик күп илләрдән җыелган туристлар, шул исәптән, безнең ил туристлары – күп меңләгән халык шәһәрнең үзәк мәйданына җыелды. Дистәләгән сәхнәләрдә театральләштерелгән тамаша бара. Бу бәйрәм тантанасы искиткеч сокландыргыч иллюминация белән тәмамланды: кара бәрхет төсле караңгы күк йөзендә әкияти утлар, йолдызлар, чәчәкләр кабынды! Хисләре тулышкан халык, кычкырып, күкләрне тетрәтеп аваз салды! Карнавалны төшерергә Софиядән һәм башка шәһәрләрдән телевидение килгән иде.

«Монастырь гыйбәтчеләре»

Болгарияне төрек илбасарлары яулагач, христианнарны бик эзәрлекләгәннәр. Монах дәрвишләр, качып, тау куышларында яшәгәннәр. Җимерелгән мәгарәләрне хәзер туристларга күрсәтү өчен төзекләндергәннәр. Куышлары (келья) – кечкенә, йокларлык кына урын.

Аннан соң иске монастырьда булдык. Монахлар җыелып догалар укый торган залда ресторан ачканнар. Борынгы күренешен саклап, эскәтерсез такта өстәлләр, урындыклар, сөремле куыклы лампалар, шәмдәлләргә шәмнәр урнаштырганнар, кытыршы диварларга эленгән сарымсак «муенсалар»ның исе әлеге күренешне тулыландыра төшә. Боларның барысы да чит ил туристларын кызыксындыру өчен эшләнүе аңлашыла: Болгариянең бюджетында туризмның ул вакытта ук бик зур роль уйнавын Христина сөйләгән иде. Без биредә күчтәнәч өчен бик матур рәсемле «Монастырь гайбәтчеләре» дигән маркалы шәраб алдык.

Милли үзенчәлекләр

Баргач та болгарларның теле, язмалары белән кызыксындым. Китап кибетендә Яворов дигән болгар шагыйренең кечкенә генә шигырьләр җыентыгын алдым. Алфавитлары – кириллица, нәкъ рус алфавитына охшаган, аерма бары бер билгедә генә – Ъ-(ер) бар: тъмноти, дъждливи, сърце, съблазън.

Славян теле булгач, күп сүзләр тәрҗемәсез аңлашылса да, сөйләмдә, кызу сөйләшкәч, бөтенесенә дә төшенеп бетеп булмый. Яворов шигырьләренең мотивлары – моңсулык, күңел төшенкелеге, туган илне сагыну, ялгызлык турында. Бәлки бу йөз еллар буе изелеп яшәгән милләт хиседер:

Денем призраци мъгливи,
Нощем тъмни тъмноти.
Пъплят облаци дъждливи
В поднебесни висоти.

Бу шигырь язылганда – 1914 елда Европада Беренче Бөтендөнья сугышы кабынган вакыт була. Сугыш – һәр милләт өчен бәхетсезлек, кайгы...

Болгарларның барысы да диярлек русча аңлаша ала. Кояшта каралган, кара чәчле болгар малайлары, кәрҗин тотып, болгарча да, русча да, немесчә дә кычкырып, пляжда туңдырма, җимеш, су сатып йөриләр. Мин аларны Горькийның «Италия турында әкиятләр»ендәге Пепега охшаттым: шундый ук кыюлар, матурлар.

Балалар бөтен җирдә дә бала инде: сөйкемлеләр, кызыксынучаннар. Тодор – ун яшьләр тирәсендәге малай өченче класска күчкән. Русча бик чиста сөйләшә. Аның белән холлда таныштык. Күкрәге тулы значок. Безнең туристлар биргәннәр.

– Ничек болай русча яхшы беләсең? – дип кызыксынам. – Рус теле бишенче класстан гына укытыла башлый бит.

– Минем әнием – гид! – ди малай, горурлык белән. Димәк, әнисе өйрәткән! Тодор Христина Дмитриевнаның улы булып чыкты. Бик тәртипле, дәрәҗәле тота үзен!

– Ничәлеләргә укыйсың?

– Алтылыга. (Болгариядә шундый билге барын белдек.)

– Өчлеләр аласыңмы? – дим. Малай көлә, башын болгый.

– Үскәч кем булырга телисең?

– Гид!

– Ничә значогың бар?

– Җитмеш сигез.

– Бу значокта кем?

– Ленин.

– Тулысын әйтә аласыңмы?

– Владимир Ильич Ленин, – ди. Җавабын белүенә канәгать.

Тодор, үзе белән килгән кызларга тылмач булып, аларга китәргә кирәк икәнен аңлатты. Без, значоклар бүләк итеп, алар белән хушлаштык. Кызларның бик матур мәгънәле исемнәрен көндәлегемә язып куйдым: Величка Върбанова, Искра Николова, Фаня Иванова.

Болгарлар белән аралашырга мөмкинлекләр чыгып торды. Шофер Крум Варнага кинооператор белән карнавал төшерергә килгән. Һашим абыйлар белән сөйләшә. Совет белгечләренең Варнада электростанция төзүләре турында сөйли:

– Бик зур электростанция төзиләр, ул станция күп энергия бирәчәк. Совет специалистларына – инженерларга, эшчеләргә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Яхшы сыйфатлы продукцияне очсыз бәягә алалар, хезмәт хаклары югары, – ди. Крум элек «Шкода»да йөргән, телестудиягә урнашкач, безнең» «ГАЗ-69»да йөри икән. Безнең машинаны бик мактады. Ике илнең хезмәттәшлеге турында яхшы сүз ишетү барыбызга да ошады.

Хуш, гөлчәчәкләр иле!

Ярты гасыр элек булган вакыйгаларның мәгънәсе вакыт үткән саен тирәнрәк, сөйкемлерәк, кадерлерәк тоела.

Кунакчыл Болгария халкына рәхмәттән күңелләребез мөлдерәмә иде! Бу илдә күңелсезлекләргә урын юк, барысы да җайга салынган кебек: салкын җилләрдән саклаучы, яшел урманнар белән капланган мәһабәт Балкан таулары, җимешләре сыгылып торган абрикос (өрек) һәм шәфталу бакчалары, уңдырышлы Добруджа кырлары, гөлчәчәкләр үскән данлыклы Казанлык үзәне, «кәефенә» карап үзгәрүчән сихри диңгез дә – барысын да гүзәл табигать кешегә бәхет өчен биргән!

Без боларның барысын да тойдык!.. Сувенирларыбызны, значокларыбызны таратып бетереп, истәлек өчен дип бер роза да өзмичә, туган илебезгә юл алдык. Зәп-зәңгәр Кара диңгез безгә сюрприз ясады: иртән торуга, бишектәге кебек тирбәтә, идән чайкала, тотынмыйча йөреп булмый, күңел уйный... Төнлә берни сизмичә йоклаганбыз, теплоход командасы исә, йокламыйча, штормга әзерләнгән, шлюпкаларны хәстәрләп куйганнар. Биш баллы шторм булган. Радиодан иртәнге ашка чакыралар, коридорда сузылган бауларга (поручни) ябыша-ябыша бардык. Кайберәүләр «диңгез авыруы» белән ныклап чирлиләр. Бәхеткә, диңгезчеләр тозлы кыяр өләшәләр иде. Тозлы кыяр күңел болганганны баса. Корабльдә шторм булу очрагына тозлы кыяр саклыйлар икән! Өйләгә шторм басылды, кояш елмая, дельфиннар, диңгез дулкыннарын ярып, безне озата бара...

Йомгаклау сүзе

Чит илләргә бару хәзер инде гадәти хәл. Кеше күңеле матурлыкка, маҗараларга, хикмәтле хәлләргә тартыла. Андый кызыксынучан кешеләр бармаган почмак Җирдә калмагандыр да инде! Антарктидага да экскурсиягә йөриләр бит хәзер! Анысы бик әйбәт. Ләкин Мисырга, Төркиягә һәм башка илләргә барган кайберәүләрнең бик тәмләп анданиләр ашаулары, швед өстәлендәге байлык, коньяк һәм ромнарны – кайсын телисең, ничаклы телисең – шулкадәр эчәргә мөмкин икәне турында тыңлавы мәзәк... Кайбер кесәләре калын кешеләрнең отельдән чыкмыйча, беркая бармыйча эчеп ятып, кайтып китүләре турында ишеткән бар. Безнең заманда чит илгә дөнья күрергә, үзеңне күрсәтергә баралар иде. Утызар кешелек төркемнәргә юлламалар хезмәт кешесенә – алдынгы эшчеләргә, колхозчыларга, авыл интеллигенциясенә очсыз бәягә бирелә иде. Безнең Мөслим районыннан гына да бик күп төркемнәр Болгариягә, Югославиягә, Чехословакиягә, Германиягә, Венгриягә күп тапкырлар барды. Мөслимнең Академик хоры тулы составы белән Чехословакиягә барып, Прага, Братислава, Брно шәһәрләрендә Ария Степановна Овчинникова җитәкчелегендә өч атна концертлар куеп, кунак булып кайтты. Бу бит бөтен Татарстан буенча шулай иде! Әлмәттән, нефтьчеләр, бораулау мастерлары, үзешчән сәнгать җырчылары һәм музыкантлары, журналистлар һәм язучыларның Болгариягә сәяхәткә барулары, Софиядә болгар халкы белән якыннан аралашып, җырлап-биеп йөрүләре, анда ниләр күрүләре, кичерүләре турында мәрхүмә Саҗидә Сөләйманованың очеркын укып сокланган идем! Безнең заманда коллективизм хисе көчле иде. Хәзер ул бетеп бара. Инде кеше ялгыз: байлар да, ярлылар да. Һәркем үз казанында кайный! «Череп баеганнар» бигрәк тә ялгыз: үзләрен башкалардан өстен тоялар, шикчелләр, ятлар гына түгел, аларга хәтта туганнар да чит.

Менә шуңа күрә безгә үткәнебез бик кадерле. Без тигез идек, кимсенмәдек, көнләшмәдек, иртәгәге көн өчен борчылмадык, дуслыкның кадерен белдек, иң мөһиме – туган җиребезнең кабатланмас гүзәллеген күреп, илебезне сөеп, горурланып, бәхет тоеп гомер иттек. ■

Пушкин белән шигырь алмашу

Зиннур Мансуров



Безнең балачак җәмгыятьтә «китап бумы» башланып китү, ягъни басма сүзгә игътибар көчәю чорына туры килде. Һәртөрле ашамлык сатылган гап-гади авыл кибетендә дә китап шүрлегенә аулак урын билгеләп куела иде. Өйләрдәге китап почмаклары да күзгә күренеп баеды. Газета-журнал алдыручылар да сизелерлек дәрәҗәдә ишәйде. Ә инде һәркемне үзенә тарткан мәктәп яки авыл китапханәләренең төрледән-төрле басмалар белән даими тулыландырылуын әйтеп тә торасы юк. «Иң күп китап укучы ил»нең варислары буларак, әлбәттә, безләргә белем нурында коеныр өчен иркенлек килде. Китап саны буенча ярыша-ярыша, бер-беребездән көнли-көнли укый идек. Кем әйтмешли, китап мәгарәсендәге киштәләрне аркылыга-буйга сөреп чыктык. Өлкәннәргә тәгаенләп язылганнарын да күздән кичерергә җай таптык. Кыскасы, безгә «китап җене» кагылган иде бугай. Гомерем буена онытылмаслык хәлгә дә китап сайлаган мәлдә юлыктым.

Шулай мәктәп китапханәсендә яңа басмалар белән иркенләп танышкан чакта, бөек урыс шагыйре Александр Пушкинның кайсыдыр томын кулыма алдым. Нәрсәдер эзләгәндәй, битләрен актарам. Чү, шулчак ни күрим: «Мансурову» дигән шигырь! Йөрәгем ешрак тибә башлады. Үземнең фамилияне шәйләгәч, күзләремә ышанмыйча тордым. Әлеге шигъри багышлауның беренче юлларын укыйм:

Мансуров, закадышный друг,
Надень венок терновый!..

Дөресен генә әйткәндә, күктән иңгән ниндидер серле хәбәр сымак тоелучы бу шигырь мине – иҗат эше белән шөгыльләнә башларга батырчылык кылган малайны тәмам әсәрләндерде. Кара әле, безнең нәсел йөрткән фамилияне хәтта Пушкин хәзрәтләре дә белгән! Сабакташлар алдында горурлыгым уянды. Күрче, Хәбибрахманов яисә Насыйбуллин дип язмаган бит, нәкъ менә Мансуровка турыдан-туры мөрәҗәгать иткән... Мин әлеге җыентыкны өйгә алдым һәм аны үземдә шактый озак тоттым. Теге багышлау урнашкан битләр арасына кипкән әрем тәлгәшен салып куйдым. (Ул елларда безнең кебек бала-чага куян үрчетү белән мавыкты, әрем ише үлән кул астында еш була торган иде.)

Хыялыйлык шаукымыдыр: буй җитмәслек мәшһүр шагыйрьнең «Мансуровка» исемле шигырен мин үземә юлланган фатиха сүзләре рәвешендәрәк кабул кылдым. Кулыма алган каләмне ышанычлырак тота башладым. Күңелдәге иҗат дәрте дә отыры көчәйгәннән-көчәйде. Язганымны көндәлек матбугатта ешрак бастыруга ирештем. Һәм кайбер газеталарда рәсемнәрем дә чыккалады – Пушкинның да мондый шөгыле булган ич. Һәрхәлдә, аның дәверләр кичеп килгән «дустанә сәламе» самими табигатемә тылсымлы йогынты ясамыйча калмагандыр, дип уйлыйм.

Аңлашыла ки, көтмәгәндә туган тәэсирләрем күңел катламнарында бераз утыра төшкәч, мин нәселебез шәҗәрәсе турында күбрәк белергә тырышып карадым. Шигъри багышлау героена әйләнгән Мансуров безнең берәр «чыбык очы» түгелме, янәсе. Юк, бу хакта әти белән әни дә, туган-тумача да хәбәрдар түгел иде. Үсә төшкәч, барысы да аңлашылды: баксаң, ил тарихында төрле сәбәпләр аркасында урыслашып киткән һәм Мансуров фамилиясен йөрткән зыялы затлар байтак исәпләнә икән. Мәгълүм шигырьнең үзәгенә алынган адашымның исә урыс армиясе офицеры, «Яшел лампа» дип исемләнгән театр җәмгыяте әгъзасы булганлыгы ачыкланды.

Хакыйкать ачылуга карап, бәгырем суынмады. Балачагымның беркатлы ышануына хыянәт итмәскә ният кылдым. Әйдә, серле хатирә рәвешендә шулай рухландырып яшәсен. Әнә бит, үтә горур Тукаебыз да Пушкинга ихтирамын белдергән, аның исемен үзенең берничә әсәрендә телгә алган... Шәхсән үземә корифейның «надень венок терновый» дигән кәлимәләре иҗат юлының кыенлыгы хакында да кат-кат искәртеп торды. Чыннан да, әдәбиятта тыйнак кына уңышың өчен бирелгән чәчәкләр дә кайвакыт үзләренең чәнечкесе белән йөрәкне канаткалый икән. Ә менә әрем кыстырылган китап битендәге шигырь уңаеннан җавап сүзен язуга килгәндә, күңелем түрендә йөргән ошбу теләкне гамәлгә ашырыр өчен шактый еллар кирәк булып чыкты. Мин аны азмы-күпме шагыйрьлек тәҗрибәсе туплагач кына, төгәлрәк әйткәндә, 1998 елның 12 декабрендә генә кәгазьгә төшердем.

Балачагымның менә шундый истәлеге кальбемдә әледән-әле яңарып куйгандай була. Хыял томанына өртелгән әлеге очраклылыкка рәхмәтле икәнлегемне янәдән искәртеп узам, чөнки ул миңа Пушкинның үзе белән шигырь алмашырга этәргеч бирде.

ЧӘРКӘДӘГЕ ЧӘНЕЧКЕ

Мансуров, закадышный друг,
Надень венок терновый!..
А.С. Пушкин

Сәламеңне алдым әлмисактан –
ничә еллар, ничә яздан соң!
Аллаһыдан узып... Әүлиядай,
язмышыма өстәп язгансың.

Фәрештәләр шигъри фатихаңны
пышылдаган миңа бишектә.
Алмашынган төсле, адашларым
елагандыр шулчак биш йортта.

Шигъриятләр сыя шәригатькә,
тотыйк, диеп, шушы бер денне, –
шәрафәтле Хәйям шәрабенә
имезлегем манып бирдеңме?

Вәсвәсәгә салды «вәхи»ләрең –
(мин дә Раббымызның бер колы).
Тыгылгансың минем тәкъдиремә
башланмаган гасыр аркылы...

Китабыңны кат-кат актарганда,
үз-үземә әллә фал ачтым?!
Ырымланган битләр арасында
гөлчәчәген күрдем... Парнасның.

Тамгаланган серле такыядай,
агып төшкән күпме җәй аша!
Язмышыма үзем җайлашаммы,
әллә язмыш миңа җайлаша?!

Исемемне атап искәрткәнсең,
хәбәр биргән кебек гаиптән.
Чәнечкеле таҗның сөенчесе
тоташ газап, тоташ гамь икән.

Карулашмыйм хөкем карарыңа –
тоеп яшим аның бар ямен.
Чәркәмдәге һәрбер чәнечкене
йөрәгемә күмеп барамын...

Исемемне укып исәйгәнмен,
рәхмәт инде сиңа, җан дустым!
...Әлмисактан килгән сәламеңне
чынга алып әллә ялгыштым?! ■

«ТАТМЕДИА» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Татарстан китап нәшрияты,
«Безнең мирас» журналы редакциясе

ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс 2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр үткәрелә.

Конкурска үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

Конкурска юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

Изге көндә – изге гамәл

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Йокохама. XIX гасыр

ЯПОННАРНЫҢ БӘЙРӘМЕ

Бервакыт мине шактый кеше белән таныштырганнан соң, Токотоми җәнаплары чыгыш ясады. Чыгышының кыскача эчтәлеген газетасының иртәгесе көнге номерында бастырып та чыгарды:

«Без, японнар, гыйлем һәм мәгърифәт җәһәтеннән ихтыяҗларыбызны тәэмин итәр өчен, Аврупага таба чаптык. Аврупаның купшы сүзләренә, тыштан ялтыравыклы мәдәниятләренә гашыйк булып, баш иярга җитешеп түбәнәйдек. Шул рәвешле, матди барлыгыбызны гына уйлап, рухи көчебезгә таяныч була алачак кан кардәшләребез турында уйлап та карамадык, аларның яшәешеннән хәтта хәбәребез дә булмады. Мәдәният, дип, лаф ордык, ләкин кешелеклелекне читкә этәрдек. Кардәшләребез булган татарлар турында бернинди

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

мәгълүматыбыз да юк. Менә бу юлы, шул без оныткан кардәшләребезнең берсе – Габдерәшит Ибраһим җәнаплары – Ерак Көнчыгыштагы кардәшләрен эзләп, бирегә килгән, таныш булыгыз. Хөкүмәтле милләт булганыбызга күрә, бу күп золым күргән кардәшләребезне эзләп бару безгә тиеш иде. Шулай була торып та, бу юлы атабыз, олы башын кече итеп, улларын оялтып, үзе килгән, аны сезгә танытуымнан горурлык тоям».

Чыгышыннан соң, Токотоми җәнаплары шунда булган тагын шактый кеше белән мине шәхсән таныштырып чыкты. Кара мыеклы яшь кенә бер әфәнденең кулыннан тотып, минем янымa китерде һәм: «Бу безнең газетабызның икенче мөхәррире Казими кардәшебез. Рус телен камил дәрәҗәдә белә. Кирәк булганда, Сезгә тәрҗемәче була алачак. Хезмәтегезгә әзер», – диде.

Мин мондый дәрәҗәле һәм бушлай хезмәт күрсәтәчәк тәрҗемәчеле булуым сөенеченнән шунда ук аягүрә торып бастым да япон кардәшләремә булган хиссиятемне белдердем:

«Япон милләтен, ягъни сезләрне без ишетеп белеп ихтирам итәбез. Сезне милләт буларак бик яхшы танымасак та, безнең мөселманнар, бигрәк тә без – татарлар японнарга карата рухи якынлык тоя идек. Рус-япон сугышы башланып китүгә, бөтен мөселманнар, бернинди мөнәсәбәтләре булмаган японнарның өстен чыгуын теләп, дога кылдылар. Безнең татарларда аеруча көчле хиссият уянды һәм Порт Артур турында үзенә аерым бер аһәң белән сөйләнә торган шигырьләр язылды.

Мин бу хиссият бары тик безнең тарафтан гына булгандыр, дип уйламыйм. Үзләре күргән кешеләр, Себер аркылы үтеп баручы япон әсирләре, Себер тимер юлындагы станцияләрдә татарларны күргәндә, аларга аерым бер мөлаемлык белән карыйлар, берәр нәрсә сатып алырга теләсәләр, татарлардан сатып алалар иде, дип сөйлиләр. Омск станциясендә бер-ике көн туктап торган поезддагы япон әсирләре, безнең татар балаларын күреп, аларга акча таратканнар, кайбер шәхси әйберләрен истәлек итеп татар кешеләренә өләшкәннәр. Болар һәммәсе безнең арабызда рухи бәйләнеш барлыгына дәлил булып тора. Мин үзем шәхсән бик күптәннән бирле японнарга тартылам. Япон кардәшләремне үз күзем белән күрү теләгемнең, ничәмә-ничә еллар дәвам иткәннән соң, ниһаять тормышка ашуына никадәр горурлансам да урынлы, никадәр сөенсәм дә аз булыр».

Боларны рус телендә сөйләдем, Казими әфәнде тәрҗемә итте. Тыңлаучылар әледән-әле алкышладылар, соңыннан тагын яныма килеп, миңа таныклык (визиткаларын) бирүчеләр күп булды. Каһвәләр, чәйләр эчеп, татлылар ашаганнан соң ук, йөрергә чыктылар. Кагыйдәсе һәм тәртибе буенча төрле-төрле җирләргә бардык, бик күп мөхтәрәм шәхесләр белән күрештек.

Шул рәвешле, көндез, кич, төн урталарына кадәр бөтен шәһәрне әйләнеп чыктым. Бөтен җирдә халык шулкадәр күп: көне буе иңбашларыбыз ышкыла-бәрелә авырта башлады, дисәм дә дөреслектән ерак булмас. Шулкадәр йөреп, ни көндез, ни кич, ни төнлә, бер генә сәрхуш кеше дә күрмәдем. Гомумән, Япониядә айлар буе ил гизеп, шәһәрләрдә, авылларда йөреп, бер исерек кеше дә очратканым булмады. Бу кадәр кеше ташкынында бу дәрәҗәдә тәртип булу шаккатарлык иде. Биредә дә бернинди дә тәртипсезлек күрмәдем. Ул гына да түгел, иртәгесе көн, андый-мондый хәлләр юк микән, дип, газеталарның хәбәрләр бүлемен махсус укып чыктым: берни юк иде. Бары тик алты яшьлек бер баланың адашып калган булуы турында бер хәбәр укыдым. Баланың куен кесәсендәге адресыннан, аның авыл баласы булуын белеп алып, ата-анасына тапшыру өчен шул районның полиция идарәсенә китерелүе турында бер хәбәр бар иде. (Японнарда кечкенә балаларның куен кесәләренә адреслары язылган такта

кисәге куела һәм бу күркәм гадәт бөтен Японииядә таралган. Чынлап та, кечкенә балалар өчен бу бик яхшы кагыйдә, югала калса, шунда ук гаиләсенә хәбәр бирергә мөмкин. – *Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе*).

Японнарның бу бәйрәмнәре бик зур бәйрәм һәм, шул ук вакытта, берничә истәлекле көн дә әлеге бәйрәм эченә кергән булып чыкты: Конституцияле идарә игълан ителгән көн, Микадо җәнапларының тәхете Киото шәһәреннән Токио шәһәренә күчкән көн, Япония хөкүмәте оешуга 2660 ел тулу да шул ук көнгә туры килгән иде. Мондый бәйрәмнәр никадәрле тантаналы булса да урынлы, никадәрле хөрмәт күрсәтелсә дә лаеклы иде. Бу бәйрәм вакытында мин бик күп кеше белән таныштым һәм, үземә даими тәрҗемәче булачак, Накайама исемле тагын бер япон кешесен таптым. Бу кешенең рус теле дә бик яхшы һәм иң мөһиме – буш вакыты күп иде. Шулай итеп, моннан соң миңа кайчан тәрҗемәче кирәк булса, вазгыятькә күрә, һәрчак бер тәрҗемәче әзер була иде. Бик еш кына, Токиода булганда, Накайаманың йортында кич кунарга да кала идем.

ЭЛЕККЕГЕ ЧИТ ИЛЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЫ КОНТ ОКОМА[1]

Япон сәясәтчеләреннән иң беренче Конт Окома белән күрештем. Бу мөхтәрәм зат – японнарның иң бөек сәясәтчеләренең берсе. Мин бу кешенең өенә бардым. Башта таныклыгымны биреп үземне таныттым һәм кабул ителдем. Бераз гына тәрҗемәи хәлемне сөйләдем. Конт Окома җәнаплары: «Танышуыбызга бик шатмын. Улларым кебек ике яшь егет бар. Рөхсәт итсәгез, мин аларны да бирегә чакырыр идем. Алар да Сезнең белән танышсыннар һәм сөйләгәннәрегезне ишетсеннәр иде», – дип, стенадагы кыңгырау төймәсенә кулын сузды. Шунда ук ишектән ике яшь егет керде. Конт Окома җәнаплары, безне таныштыргач, миңа: «Рәхим итеп дәвам итегез!» – диде.

Мин сүз башладым:

– Җәнабыгызга үтенечем бар: Япониянең киләчәге турында берничә сорау бирергә һәм Сезнең фикерегезне ишетергә телим. Беренчесе: японнар кинәт кенә кояш кебек чыктылар һәм беренче хәрәкәтләре белән үк, Шәрык милләтләренең мәдәниләшү сәләтенә ия булуларын бөтен дөньяга исбат иттеләр. Бу исә Аврупа дипломатларының Шәрык турындагы, йомшак итеп әйткәндә, ялгыш фикерләренә һәм түбән мәнфәгатьләренә һич кенә дә туры килми һәм бүгенге көнгә кадәр алып барылган сәясәтләрен дә һичшиксез үзгәртәчәк. Бигрәк тә, Кытай базарында болай кинәт кенә пәйда булган көндәшкә Көнбатышның риза булып карап тормаячагы ап-ачык уртада. Бу мәсьәләдә аврупалылар японнарның кытай җирләрендәге рухи мәнфәгатьләренә каршы төшмәсләрме? Икенче: бүгенге көндә японнар, җир шарында урнашкан урыннары белән бәйле рәвештә, Кытай дәүләте белән берләшү ихтыяҗы тоялармы? Бу берләшү нинди мәнфәгатьләрне тәэмин итә алачак, берләшә алу ихтималы бармы? Өченче: японнарның америкалыларга карата фикерләре нинди? Дүртенче: япон милләте дин мәсьәләсендә ничек фикер йөртә? Төп дин булган Будда динен саклау японнарның мәнфәгатьләренә күбрәк ярарлыкмы? Яисә яңа дин кабул итү фикерендә булган кешеләр дә бармы?

Конт Окома боларны бик игътибар белән тыңлады һәм болай диде:

– Мин башта Сезнең дүртенче сорау итеп биргән соңгы соравыгызга җавап бирәчәкмен.

– Алай булса, өстәп, тагын бер-ике сүз әйтергә телим, рөхсәт итегез. Сез миңа үз динен җәелдерергә килгән кешегә кара-

[1] Окума Сигэнобу (1838-1922) – дәүләт эшлеклесе һәм сәясәтче, дипломат, финансист һәм педагог, Васэда университетына нигез салган шәхес. 1888-1889 һәм 1896-1897 елларда Япониянең Чит илләр эшләре министры вазыйфасын башкара. Текстта аның фамилиясе янында Конт/Кунт рәвешендә бирелгән сүз япон телендә ихтирамны белдерә торган кун кисәкчәсе булырга тиеш (тәрҗ. иск.).

Токио.
XIX гасыр

ган кебек карый күрмәгез, чөнки безнең динебез – хакыйкатьнең нәкъ үзе, ә хакыйкатьне эзләү һәр кешегә кирәк. Без аны беркемгә дә тәкъдим итмибез. Эзләгән үзе таба.

– Мин Япониядә Сезгә кадәр өч мөселман күрдем. Берсе Истанбулдан килгән иде, безгә, бердән күбрәк хатын алу гадәте турында сөйләде, шуны тәкъдим итте. Мин моның төп кануныбызга каршы төшүен, Япониядә бу гадәтнең беркемгә дә тәкъдим ителә алмаячагын, әгәр Исламият күпхатынлылыктан гыйбарәт булса, японнарның Исламияткә һич ихтыяҗлары юклыгын әйтеп кенә калмадым, язып, кулына да тоттырдым. Тагын бер мөселман кешесе Мисырдан килгән иде. Микадога Исламиятне таныту фикерендә иде. Ул да кабул күрмәде. Аннары бер һинд кешесе килде, галим кешегә охшаган иде. Ул да биредә озак калмады дип беләм. Хәзер инде үз фикеремне әйтәм: безнең японнар дин мәсьәләсенә артык зур әһәмият бирмиләр. Японнарның диннәре гаять мөкатдәс, инанулары бик нык. Алар бары бер нәрсәне таныйлар – японлык. Япон кешесе, нинди генә динне кабул итсә дә, аның асыл дине барыбер японлык булып кала, ул бар нәрсәдән дә артыграк японлыгын изгеләштерә. Рус-япон сугышы шуны күрсәтте: христианлыкны кабул иткән японнарның барчасы да, беренче адымнарында ук, иңнәренә корал алып, япон гаскәренә барып кушылдылар. Японнар, диннәре белән түгел, япон булулары белән горурланалар. Шул ук вакытта, Япониядә дин мәсьәләсе гаять ирекле, һәркем теләгән динен сайлап кабул итә һәм аны җәелдерә ала.

– Сез бөек затның бу сүзләре минем соравыма җавап дәрәҗәсендә булмады.

Мин японнарның мәнфәгатен күз алдында тотам, башкаларның мәнфәгате турында сорамыйм.

– Японнарның мәнфәгатьләре милли әхлакларын саклау белән бәйле. Милли әхлаклары юкка чыккан мәлдә японлыклары да юкка чыгачак.

– Мин дә шулай уйлыйм. Минем әйтергә теләгән фикерем дә шул: Конт Окоманы, адмирал Тогоны, принц Итоны тәрбияләп үстергән аналар, христианлык басып ала калса, шул ук мизгелдә юкка чыгачаклар. Чөнки милләтпәрвәрлек бары тик нәсел буенча гына дәвам итеп килә ала, нәселе билгесез кешедә милли горурлык хисе була алмый, милли хисе булмаган кавемнәрнең киләчәге була алу бик икеле. Минем менә Сезнең шул хактагы фикерләрегезне беләсем килә.

– Әйе, болар, минемчә дә уйланырлык нәрсәләр. Бу хакта уйлаучылар юк, дип әйтмәс идем. Нәкъ менә бу фикергә нигезләнеп, Конфуций мәзһәбен яңартырга теләүчеләр бар.

Мин Конт Окоманың бу сүзләреннән япон милли әхлагының христианлык белән саклана алмаячагын ахыргача аңладым. Моннан соң гел милләтнең киләчәге өчен милли әхлакның саклануы кирәклеге турында сүз алып бардым. Бу минем эшемә бик ярады.

Конт Окома сүзен дәвам итте:

– Американлылар, әлбәттә, зур һәм бай милләт, ләкин һичбервакыт сугышчы милләт була алмаячаклар. Сугыш кешеләрнең яшәешен саклау коралы булса, милләтләрнең яшәешен саклап калу өчен милли хисләренең уяу булуы кирәк. Американлылар милләтләренә булган хис белән түгел, мал-мөлкәткә булган хис белән горурланалар, шуңа күрә бервакытта да сугышчы дәүләт сыйфатын ала алмаячаклар. Әйе, акчалары күп, бик көчле хәрби флот оештыра алырлар. Теләсәләр, бүгенге Англиянекеннән ике тапкыр зуррак флот оештырсыннар, ләкин ул бронялы крейсерлар, кораблар, фәләннәр үзләре сугышка бара алмаслар шул, аларның эченә гаскәриләр, сугышчылар кирәк. Ә сугышыр өчен милли хисе булган кешеләр кирәк, ә американлыларда ул юк, чөнки американлыдан сугышчы чыга алмый. Бронялы крейсерны банкирлар белән тутырып диңгезгә чыгару сугыш өчен җитәрлек түгел. Шуңа күрә американлылар безнең каршыбызда беркем дә түгел. Ләкин бүгенге көндә американлылар кытай һәм япон милләтләренә дәвамлы куркыныч тудырып тора алачаклар. Чөнки бу ике милләт гел ач һәм мохтаҗ, ә Америкада исә акча һәрвакыт бар. Кеше, никадәр сабырлы булса да, ачлыкка сабыр итә алмый. Күршесендә икмәк булганда, ачлыктан үлә алмый. Шулай булгач, американлылар һәрвакыт безнең икмәгебезне хәзерләп тора алырлар, тик безнең белән сугыша алмаслар. Тагын шунысы да бар: американлыларның хәле безнең өчен сер түгел, бүген Американың һәр тарафында йөз меңләп япон кешесе бар, алар Американың бөтен җирен беләләр, кешесен таныйлар.

Инглизләр кайчандыр дан-шөһрәтләре белән дөньяны тетрәткән булсалар да, аларның чын көчләре билгесез, тышкы яктан диңгез көчләре буенча Англия иң бөек дәүләт булып санала. Ләкин ул бронялы крейсерлар белән идарә итәрлек сугышчысы бармы Англиянең, юкмы – моны кистереп кенә беркем дә әйтә алмый. Бары сугыш корабларын, бронялы крейсерларын бар дөнья белә – куркытканнар чөнки. Англиядә бу диңгез көчләренә инглиз буларак хезмәт күрсәтерлек кешеләр бармы? Инглизләр әлеге сугыш корабларын көне-төне үз золымнары астында яшәткән һиндләрнең, Мисыр гарәпләренең кулына тапшыра алачакларммы? Боларны белә алучы юк. Инглизләр хәзерге вакытка кадәр өсте ябулы шөһрәткә ия булып торалар, Әмма американлылар безнең өчен алай түгел, чөнки американлыларның олысынкечесен, барын таныйбыз, алар безгә каршы бервакытта да сугыш ача алмаячаклар. Конт Окома бераздан сүзен түбәндәгечә дәвам итте:

Токио. XIX гасыр

– Японнарның кытайлар белән берләшүе мәсьәләсенә килсәк, бу – безнең өчен гаять мөһим мәсьәлә. Японнарның ихтыяҗлары зур булган кебек, кытайларның да ихтыяҗлары зур. Тик кытайлар үз ихтыяҗларын аңлый алмыйлар, мәнфәгатьләрен кайгыртмыйлар. Төп бәла бу. Ул максатка таба хәрәкәт итәчәкбез, тырышачакбыз. Бу безнең өчен үлү-калу мәсьәләсе булып тора, дисәм дә арттыру булмас.

Минем үзем оештырган уку йортым бар. Бу университетта хәзерге вакытта биш мең укучы укый. Уку йортының лицей өлешендә тагын өч мең укучы бар, ягъни һәммәсе сигез мең укучы. Боларның бер меңе – кытай яшьләре. Теләсәгез, бу уку йортын барып күрә аласыз. Кытай студентлары арасында диндәшләрегезне дә очрата алачаксыз.

Мин, бик сөенеп:

– Йа! Һичшиксез барып күрәчәкмен, – дидем. Конт Окома исә сүзен дәвам итте:

– Менә шул уку йортын оештырып ачуымның максаты – япон һәм кытай яшьләрен, бергә укыту-тәрбияләү аша, бер-берсенә якынайту иде. Ачылганда, уку йортында бары тик йөз иллеләп кенә бала укый алырлык иде. Хәзер исә сигез меңгә җитте. Моннан өч ел элек аерым кызлар уку йорты ачтым. Ирешә алсак, бу ике уку йортын берләштерергә телибез. Кытайларда да мондый хис туса, мәсьәлә үзлегеннән барлыкка килер, максат үзлегеннән хасил булыр иде. Тик бу эшкә каршылыклар да бик күп. Сезнең беренче соравыгыз тәмам ачык, әзер. Аврупалылар моны бездән алдарак уйлаганнар һәм уйлыйлар.

Шулай булса да, бүген безнең Япониянең башка дәүләтләр арасында үз урыны бар. Япония беркайчан да бүгенгедән кечерәк дәүләт хәленә килмәс. Бүгенге урынын саклар өчен исә бүгенге көче җитәрлек. Әгәр дә зуррак дәүләт булырга теләсә, кытайлар белән берләшергә мәҗбүр булачак. Шуны да өстәп әйтим: япон милләте, үзара тыныч яшәү тарафдары булса да, сугышырга кирәк була калса, һичбервакыт сугыштан качмаячак.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

ХӨСӘЕН МИРЗА

Борынгы татар тормышыннан трагедия

Фәтхи Бурнаш

Сара һәм башкалар.

Сара. Ах, әткәй! Мин сине ничек көттем!

Хөсәен. Син мине генә көткәнсеңдер әле, кызым. Ә мин сине шулай яратам, һәрвакыт сиңа көтелмәгән кадерле кунаклар белән кайтырга тырышам.

Сара. Рәхмәт, әткәем!

Красильников. Помещик Василий Никандрович Красильников. Сәламәтлек телим сезгә!

Сара. Мәрхәмәт итегез – утырыгыз!

Красильников. Менә сезгә тагын бер яңа кеше... *(Мусага күрсәтә.)* Аны, кунак, дисәң – кунак дияргә, бүләк, дисәң – бүләк дияргә була. Хөсәен Айдашович, ул сезгә ун кеше урынына торачак. Дөрес, туташ, сирәк очрый торган бер хәзинә. Ул сезнең өчен гомергә сагынмалык булсын.

Хөсәен. Мин бары Сезнең сүзегезгә ышанып кына алып калам. Югыйсә, миндә

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

менә бу ике аяклы хайваннарның очы-чиге юк... Тик файдалары гына бер тиен бакыр йөрми.

Сара. Ул соң нинди егет?

Красильников. Сез аның үзеннән сорагыз.

Хөсәен. Син кайсы якныкы?

Муса. Кояш ягыныкы.

Хөсәен. Ничек кояш ягыныкы?

Муса. Шулай... Ә дөресен әйткәндә, бер якныкы да түгел.

Хөсәен. Ә... синең атаң-анаң бармы соң?

Муса. Һичшиксез булган булырга кирәк. Югыйсә, муеныма бу башны асып йөрмәгән булыр идем.

Хөсәен *(Красильниковка)***.** Ул нәрсә сөйли?

Красильников. Сез тыныч булыгыз. Ул шулай туры һәм кызык сөйләргә ярата.

Сара. Син, егет, кайда үстең?

Муса. Урманда. Дөресрәге, далада.

Сара. Ничек алай?

Муса. Шулай. Әллә Сезнең далада үскән кешеләрне бер дә күргәнегез юкмы?

Сара. Әллә син табылдыкмы? Сине кайдандыр тапканнар, шулаймы?

Муса. Әйе, шулай булырга кирәк. Йә кешеләр мине тапкан, йә мин кешеләрне тапканмындыр. Ләкин анысын анык белмим.

Хөсәен. Син соң урысмы, әллә мөселманмы?

Муса. Урыслар мине – мөселман, ди, мөселманнар – керәшен, ди. Ә үзем әле берсен дә сайлаганым юк.

Сара. Ул нинди кызык кеше. Үзенең динен дә белми.

Муса. Алай да минем анда гаебем юк. Аның өчен минем үземне дә, динемне дә бирәү дә белми. Ә мин үзен аны кайдан белим?

Сара. Ул нинди кызыклы!

Красильников. А, сөйләрлекме? Шуның өчен мин сезгә китердем дә аны.

Сара. Рәхмәт Сезгә! Әткәй! Син аны аласың бит?

Хөсәен. Белмим әле. Ә Василий Никандорович бик мактый үзен. Әй, ябалак! *(Малай керә.)* Кәгазь, кара чыгар хәзер монда!

Сара. Егет, синең исемең ничек?

Муса. Мине Муса, диләр. Ә бояр биргән билетта Моисий диелгән, песи, дисеннәр, минем өчен барыбер.

Сара. Ха-ха-ха! Син нинди потешный! Кара әле, син ничә яшеңдә?

Муса. А, мин карт. Менә бу халыкның һәммәсенең яшьләрен бергә җыйсаң да, өстәвенә синекен дә кушсаң, мин шуңардан да картырак.

Сара. Бу ничек була?

Красильников. Муса!

Муса (*Сарага)*. Алай да картлар миңа 23-24тән артык бирмиләр.

Хөсәен *(Красильниковка)*. Ярый... без Сезнең белән килешербез. *(Мусага.)* Син бездә калырсың, егет.

Муса. Сездә соң мин ни эшләрмен?

Хөсәен. Мин сине управляющий кулына тапшырырмын. Әгәр яхшы хезмәт итеп китсәң, менә бу халык өстеннән карарга куярбыз үзеңне.

Сара. Сиңа яхшы хезмәт булыр.

Муса. А, юк, мин, кеше өстеннән карау түгел, караучыларның якынында да булырга яратмыйм.

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

Сара. Анда сиңа яхшы булыр. Алар бит иртә таңнан кара кичкә кадәр авыр, пычрак эштә газаплаланалар. Көн буе кояш астында интегәләр.

Муса. А, юк, апай, син кайгырма! Безнең өчен кояш эссесе сезнең өчен өстәл көзгесе кебек кенә ул. Мин аңардан курыкмыйм. Миңа ташып торган эш булсын да арысландай дуслар булсын... *(Шакирның җилкәсенә сугып.)* Шулай бит, егет?

Шакир *(сискәнеп)*. Ә... нәрсә?

Муса. Юк, бернәрсә дә юк.

Хөсәен. Муса! Ә синең нинди һөнәрең бар?

Муса. Һөнәремме? (*Уйлап.)* Ә... Сез мине ат дагалаучы итеп алыгыз. Мин ул эшне яхшы беләм.

Хөсәен. А, минем тимерчеләрем җитәрлек.

Муса. Мин Сезгә кирпеч суга алам.

Хөсәен. Миндә алар да бар.

Муса. Алайса, мин сабын кайнатырмын.

Хөсәен. Ул да кирәкми.

Муса. Мин Сезгә дегет чыгарырмын.

Хөсәен. Алар да җитәрлек.

Муса. Һөнәрчеләрегез алай күп булгач, сезгә бит бер һөнәрсез кеше дә кирәк булыр. Алайса, Сез мине туп-туры кара хезмәткә генә алыгыз.

Красильников. Ул нәрсә генә эшләсә дә сезгә ун кеше урынына торыр. Сез аны алыгыз.

Хөсәен. Әй, ябалак! *(Малай керә.)* Безгә бал чыгарсыннар! *(Малай китә.)* Ә... алырга дисезме?

Муса. Әйе, алыгыз. Мин халыкка зарар итәргә яратмыйм. Ә файда китерә алмасам, карарсыз... (*Бикморзага.)* Шулаймы, карт?

Бикморза *(салкын)*. Нәрсә?

Муса. Син, карт, печән чабарга остасыңдыр...

Бикморза. Нигә? *(Бал кертәләр.)*

Муса. Болай. Син бар нәрсәгә дә оста булырга охшыйсың. Бар нәрсәне дә белгәч, печән чабарга гына беләсеңдер инде. Мин синең кебек картларны күп күрдем. Аларны мин бер күз карауда таныйм.

Бикморза. Син, малай, кайсы авылныкы? (*Пауза.)* Белмисеңме әллә?

Муса. Белер өчен аның авылы булырга кирәк.

Бикморза. Нигә, авылың юкмы әллә?

Муса. Бар.

Бикморза. Кайда?

Муса. Бүген монда, ә иртәгә, шайтан белә кайда...

Бикморза. Җә, аннан суң?

Муса. Аннан суң... сөйләшербез әле... Сез барыгыз да шул авылданмы?

Бикморза. Шуннан.

Муса. Барыгыз да татарлармы?

Бикморза. Татарлар... Нигә?

Муса. Болай гына...

Бикморза. Син үзең йөргән егеткә охшыйсың.

Муса. Мин ишеткәнне – күрергә, күргәнне белергә яратам, шуңа күрә бик күп юлларны шомарттым да бугай. Син ярыйсың, карт, бервакыт шулай Кавказда чакта...

Бикморза. Син анда да булдыңмы?

Муса. Ә... юк... мин анда бояр белән барган идем...

Бикморза. Җә?

Муса. Анда да шундый картлар бар, димәкче идем.

Бикморза. Син шомартасың, малай... кара...

Муса. Ә нигә сине мирза яратмый?

Бикморза. Син нигә алай уйлыйсың?

Муса. Мин сизәм... Ярый... Ә кешеләр?

Бикморза. Ничек, кешеләр?

Муса. Тынычмы?

Бикморза. Көтүдә терлекнең төрлесе була...

Муса. Ярый... Без сөйләшербез әле...

Бикморза. Кайчан?

Муса. Иртәгә. Менә шунда.

Бикморза. Иртән булса гына...

Муса. Мин, әтәчтән элек тормасам да, кояштан соңга калмам.

Красильников. Сез аның болай ачык булуына карамагыз. Кайвакыт шулай була – ул атналар буенча бер сүз эндәшми. Әлхасил, ул сезнең өчен җанлы театр булачак.

Хөсәен. Ярый... Муса! Хәзер сиңа Иргали йоклар өчен урын күрсәтер.

Муса. Иргали, ау, Иргали! *(Иргали чыга.)*

Иргали һәм башкалар.

Иргали. Нәрсә бар?

Муса. Син буламсың Иргали?

Иргали. Әйе, мин. Нәрсә бар?

Муса. Бернәрсә дә юк.

Иргали. Бу нинди саташкан кеше тагын?

Сара. Муса! Әгәр сиңа анда салкын булса, мин сиңа яхшырак урын табарга әмер итәрмен.

Муса. Һа, кайгырма, апай... Салкында чебеш туңа, ди.

Сара. Син нинди кызык кеше...

Муса. Әйе, мин шулай кызык туган да... Миңа 25 яшькә якын булса да, дөньяда тора бшлавыма 10 елдан артык юк әле.

Сара. Ха-ха-ха! Нинди күңелле егет... *(Керә.)*

Хөсәен. Әй, ябалак! *(Малай чыга.)* Әйт, хәзер үк миңа Актырнакны китерсеннәр!

Иргали. Әй, Шәрифҗан! Тиз бул – Актырнакны чыгар монда! *(Артка китеп югала.)*

Красильников. Ә Сез егеттән мең кат разый булырсыз. Ул сезнең өчен күрек кенә булачак.

Хөсәен. Шулаймы... *(Этне кертәләр.)* Әнә, аны китерделәр... *(Эткә.)* Ну ка... иди сюда... дай лапу... җә, җә...

Красильников *(этне сөеп)*. Матур, матур... Ләкин Сез аз гына арттырырга тиешсез.

Хөсәен. А, юк, юк...Минем Актырнагым берүзе сезнең биш егетегезгә тора.

Красильников. Егет кенә түгел бит ул минем Мусам, аның торганы алтын.

Хөсәен. Юк, ни булса да, артык юк.

Красильников. Булмаса, унбишне генә арттырыгыз.

Хөсәен. Баш на баш булса – бара, булмаса, кирәкми.

Красильников. Ну, унны гына арттырыгыз.

Хөсәен. Булмый, арттыра алмыйм.

Красильников. Алайса, килешә алмадык. Хәерле булсын.

Хөсәен. Ярый, алайса, бишне арттырам.

Красильников *(кул сугып)*. Әйдәгез, хәерен күрегез! Хәзер инде Сезнең кешеләрне күрик... Миңа кирәк... бер, йә ике балта остасы... бер, йә ике тимерче... аннан соң... Аннан суң... менә болардан... Кая югалдылар әле кызлары?

Хөсәен. Кайда үзләре?

Иргали *(халыкка)*. Әй, һәммәгез дә монда керегез.

Муса. Әйдәгез, монда сезгә канат куярга хәзерләнәләр, егетләр...

Бикморза. Бу халык аны күп татыган инде... *(Бер егеткә.)* Сыз тизрәк моннан, күрмисеңмени!..

Красильников *(кызлар арасында йөри)*. Менә болардан... Болар арасыннан...

Хөсәен. Имениедә хезмәт итәр өченме?

Красильников. Әйе, иң матурын, иң булдыклысын... *(Гайшәне күрсәтеп.)* Менә шундыен...

Гайшә. Абау! *(Кызлар арасына сырыша, шаулашалар.)*

Хөсәен. Ярый... ансын берсүзсез алырсыз... Ләкин һөнәрчеләремне бирә алмыйм. Алар бөтен авылда да егермедән артмыйлар.

Красильников. Егермедән? Егерме булса, әле мин бөтен тирә-юньгә җиткерер идем... Беләсезме миндә нинди хәл? Шушы качып беткән йөзгә якын кешенең яртылабы – һөнәрчеләр. Хәзер бит помещиклары да настоящий жуликлар... Бер җан очтымы – икенче берсесенә килә дә куна. Шуңардан чирканмыйлар да. Ә Сез миңа 4-5 кеше генә бирә аласыз, әлбәттә.

Кызлар. Гайшә, җылама! Җылама, Гайшә!

Бер егет *(көйләп)*. Үз башыңа хәсрәт өчен.

Бөдрәләнгән чәчләрең...

Гайшә. Кыерсытмагыз әле ансыз да борчылган күңелне. *(Сөйләшәләр.)*

Хөсәен. Ярый, бетте. Тик хакыннан гына тартынмассыз.

Красильников. Күпме сорарсыз бит...

Хөсәен. Җан башына 200 тәңкә.

Красильников. Сез нәрсә сөйлисез? Минем аена 200 сум килерем юк та, ә Сез...

Хөсәен. Ул турыда инде Сез миңа түгел, башка берәүгә әйтегез... Җә, алдыгызмы? Җә, алдыгызмы?

Красильников. Юк, булмый.

Хөсәен. Алайса, 150 булыр, алдыгызмы?

Красильников. Менә, теләсәгез алыгыз 100не.

Хөсәен. Юк, булмый. Аларның һәркайсы аена 40-50 сумлык хезмәт китерә. Ә ул кызның торганы чәчәк.

Красильников. Ул турыда сүзем юк. Алай да кыйммәт.

Хөсәен. Кыйммәт түгел. Мин Сезгә – үз итеп кенә.

Красильников. 110га бирәсезме?

Хөсәен. Соңгы сүз – 125.

Красильников. Алайса, килешә алмадык. Калсын. Рәхмәт!

Хөсәен. Әйдә, хәерен күрегез булмаса... үз итеп кенә... Иргали, чакыр үзләрен...

Иргали. Абдулла! Тимербулат! Батырша! Гайшә! Килегез бирегә!

Гайшә. Дусларым! Мине нишләтәсез?..

Иргали. Җыламыйча гына!

Хөсәен. Кем җылый? Нигә җылый. Шундый шатлыклы бер көнне нигә ул җылый?..

Гайшә (*Хөсәеннең алдына тезләнеп).* Хуҗам! Падишам! Зинһар, дип әйтәм, кабер янына баскан атам белән анамны кулсыз-аяксыз калдырмагыз.

Хөсәен. Нигә миңа синең атаң? Нигә синең анаң? Алыгыз җүнсезне!

Гайшә. Иргали ага! Картлар хакына...

Иргали. Сарылма миңа! Барыгыз, өегезгә кайтып әзерләнегез дә, бирегә килегез.

Хөсәен. Барыгыз – моннан соң сезнең хуҗагыз сөекле Василий Никандрович булыр.

Карт. Хуҗам! Мин кырык ел гомеремне синең юргаларыңны дагалау белән кичердем. Шул үнәрне өйрәтүем өчен алтын алма кебек ике баламнан яздым. Өем тулган бала-чагаларым... уникедән югарысы юк. Син миңа соңгы гомеремдә үз балаларым янында булырга рөхсәт итсәнә.

Хөсәен. Нигә мондый җылаш? Нәрсәгә борчылырга... Мин, мәрхәмәт итеп, сине иң сөекле дустыма бирәм. Бар, кит! Хуҗаңа рәхмәт укы!

Иргали (*картны күтәреп*). Калдыр урынсыз зарларыңны, картлач!

Карт. Умарта кортлары кебек шаулап торган балаларымны урамга ташламагыз. Аларга икмәк валчыкларын канга манып ашатмагыз.

Иргали. Җитәр, җитәр, әйдә, эшеңдә бул!

Гайшә. Хуҗам! Ата-анамның үлгән сәгатьләрендә аларның авызына кем су салыр! Мәрхәмәт итегез!

Хөсәен. Син үзеңнең алдагы хезмәтең турында уйла, кызый. Бар, мәрхәмәтле хуҗаңа буйсын!

Иргали. Файдасыз, Гайшә, синең бу вайларың. Бар, ата-анаң белән күреш тә, юлга хәзерлән!

Абдулла. Без – егет кешеләр. Сатылып йөрү никадәр кыен булса да, мәрхәмәт эстәү аннан да кыенрак...

Хөсәен. Ә... нәрсә, ди?

Абдулла. Ә соң нигә Сез чәчәк кебек кыз балаларны болай җылатасыз?

Иргали. Бас урыныңа, җүнсез...

Шакир. Хуҗам, тыңлагыз минем дә бер сүземне. Гайшәне коткарыгыз да, аның урынына менә мине сатыгыз! Теләсәгез кемгә, теләсәгез кая сатыгыз! Тик аны гына сатмагыз.

Хөсәен. Күрсәтмәгез бу ахмакны тагын минем күземә! Алыгыз! *(Иргали егетне алып ташлый.)*

Карт. Ак сакалым хөрмәтенә мәрхәмәт итегез.

Хөсәен. Калдырыгыз мине! *(Тора.)*

Иргали. Тавышламагыз, югыйсә, минем камчыларымны өзгәләрсез...

Хөсәен. Ун минуттан һәммәгез дә юлга хәзерләнегез! Әй, ябалак! (*Малай чыга.)* Бар, әйт, беседкага өстәл хәзерләсеннәр! (*Красильниковка*). Әйдәгез, дустым, Сезнең дә карыныгыз ачкандыр. (*Керәләр.*)

Хөсәен һәм Красильниковтан башкалар.

Гайшә. Ай, дусларым! Мин анда нишләрмен...

Шакир. Гайшә! Җылама, түз, җанкисәккәем!

Гайшә. Нигә тудым мин анадан?

Карт. Нигә озын гомер сорадым Алладан?

Абдулла. Сау булыгыз, туганнар! Бәхил булыгыз, дуслар! Картлар, безне яманлык белән искә алмагыз! *(Күрешәләр.)*

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

Бикморза. Барыгыз! Беркемгә ялвармагыз! Беркемнән ярдәм көтмәгез. Үзегезгә таяныгыз да, сабыр итегез.

Муса. Боекмагыз, егетләр! Аша китсә, беглец булырсыз да, иркен далаларга, урманнарга китәрсез.

Карт. Гайшә! Җылама, кызым! Без бергә булырбыз. Мин картайдым инде. Син миңа – бала, ә мин сиңа ата булырмын.

Гайшә. Әйдә, бабай... Мин карт көнеңдә синең таянычың булырмын. Ак сакалларың чыланганда яшьләреңне сөртермен...

Карт. Әйдә, кызым, әйдә... Син минем яшьләремне сөртерсең, ә мин сиңа, төн утырып, борын заманнарның хәлләрен, бабаларның кичергән зарларын сөйләрмен.

Гайшә. Сау булыгыз, туганнарым!

Халык. Сау бул, Гайшә!

– Бабай, сау бул!

– Боекмагыз, туганнар!

(Халык чыга, сәхнә буш кала, бераздан музыка уйнала, Сара белән Дивана чыгалар.)

Сара, Дивана.

Сара. Дивана! Бу нинди тавыш! Кемнәр анда җылыйлар?..

Дивана. Адәмдә иман юк,
Иманда – хәйя.
Галимнәр, хәкимнәр
Кая сез, кая!
Чукынган хәзер
Һәр укынган бояр.
Сиңа зар җылыйм, дип,
Торам мин – дивана.

Сара. Әйдә, диваначыгым... Кеше-кара күргәнче, мин сине озатып җибәрим.

Хор. Йөрәгем яна ла,
Күзем кан ала,
Кыз балаларга
Авыр замана.
Абау ла!
Зифа буем михнәт өчен үстеме!..
Баш очыннан хәсрәт җиле истеме...

(Сара, Дивана сулга китәләр. Уңнан Муса килеп чыга.)

Муса ялгыз.

Муса *(уйланып)*. Бер яктан күз яшьләре... Икенче яктан ачу зарлары... Эх, карыйк әле тартып җепләрен...

Әй, Иргали!

Тавыш. Ә-ү-ү!

Муса. Кая, сез миңа яңа гостиницамны күрсәтегез!.. *(Сара чыга.)*

Сара, Муса.

Сара *(нәрсәдер әйтергә тели)*. Муса! *(Муса, аны күрмичә, артка китә, Сара крыльцога сөялеп карап кала.)*

Пәрдә

Икенче пәрдә

Тегермән алды, артта, уң кулда – амбарлар, уңда, алгы планда – зур көпчәк, улак, урталыкта – кечкенә күпер, сул кулда – берничә агач. Еракта авыл күренеп тора.

Пәрдә ачылганда су, тегермән тавышы гына. Бераздан Бикморза белән Муса чыгалар.

Бикморза, Муса.

Бикморза. Алай да мин бернәрсәгә һаман төшенә алмыйм. Алар шулкадәр күп халык җыелган җиргә килергә базарлармы икән...

Муса. Мин, Бикморза ага, шикләнмим. Без бу эшләрне никадәр яшерен итәргә тырышсак та, барыбер аңа моны җитештерерләр. Һәм ул килми калмас.

Бикморза. Һәм син шулай уйлыйсыңмы?

Муса. Әйе. Орлык кибәксез булмый... Бигрәк тә мондый эшләрдә иң ышанычлы кешеләрдән дә сакланырга туры килә.

Бикморза. Алай да миңа бу җирдән китеп торырга кирәк. Югыйсә, кояш чыгу белән бер кашык он эзләп килгән карт-корының иге-чиге булмас, баш-күз алырга ирек бирмәсләр.

Муса. Ашатучылары бер син генә булгач, нишләсеннәр соң мескеннәр.

Бикморза. Ә Хөсәен мирза ачларга бирелгән онның һәр кадагы өчен миңа йөз камчы ашатырга да вәгъдә итә... ха-ха-ха! *(Солтан керә.)*

Солтан, Муса, Бикморза.

Бикморза. Ә, Солтан! Син кайттың!

Муса. Нәрсә бар? Нишләдең, дустым?

Солтан. Һәммә нәрсә без дигәнчә. Хәзер, намаздан чыгуга, хәзрәт бөтен халыкны ияртеп чыгар. Галәүләргә, Баһауларга, Тимершаларга, Батыршаларга, теләүдән соң, монда килергә икәнне белдердем.

Муса. Кирәкле кешеләрнең барына да хәбәр иттең?

Солтан. Барына да.

Муса. Һәммәсен дә сизелмәслек эшләдеңме?

Солтан. Мин барысын да төн каралыгы кебек яшерен эшләргә тырыштым. Сез ул яктан хафа булмагыз.

Муса. Без сиңа, ышанганга күрә, моны тапшырдык.

Бикморза. Син монда булырсың, Солтан. Без хәзер Муса белән китәбез, озакламый килербез.

Солтан. Барыгыз, хафа булмагыз.

Муса. Ә кем анда килә? *(Читкә карый.)*

Солтан. Ә, ул – дивана. Сез аңардан курыкмагыз. Ул акылында түгел. Ул ярты гомереннән бирле, хатыны үлгән сагыштан думбыра кагып йөрүдән башка бернәрсә дә белми.

Муса. Ярый, әйдә, Бикморза ага... *(Китәләр.)*

Солтан ялгыз.

Солтан. Бу эшләр барлыгын да керпе күзен яшергәндәй яшерен итәргә кирәк. Ходa сакласын, ул эшләрнең күләгәсеннән бер чите генә ачылса да, аның җәзасы җан казасыннан авыррак булачак. Сакланырга кирәк – Алла сакланганны саклый, диләр.

(Сара белән Дивана чыгалар.) ■

Сара, Солтан, Дивана.

ГОМӘР БӘШИРОВ
көндәлегеннән[1]

ШӘЙХИ МАННУР (1905-1980)

Шәйхи Маннур. 1939 ел

Бу араларда тагын бер фаҗига булып алды. Мирсәйне күмгәннән соң озак та үтмәде, ашказанына ясалган операциядән соң июньнең 10сында Казанның 10 нчы шифаханәсендә Шәйхи Маннур вафат булды. Минем өчен бу бик зур фаҗига. <...>

1980, 22 июнь

Шәйхи Маннур белән без 1936 елның көзендә, мин «Совет әдәбияты» журналының җаваплы сәркатибе итеп билгеләнгәч очраштык. Мин ул вакытта әдәбиятта яңа кеше идем әле. Көндәлек матбугатта чыгып килгән очеркларым, мәкаләләрем белән генә азмы-күпме танылып килә идем. Шәйхи исә ул вакытта ук шактый танылган шагыйрь иде инде. Без аның белән күбесенчә редакциядә генә очраша идек. Ул очрашу да эшлекле мөнәсәбәттән узмады кебек. <...>

Турыдан бәрүне һәрвакытта да кулай адым, дип әйтеп булмый. «Туры әйтәм, гадел булам», – дип, кешенең йөрәгенә авыр яра салырга мөмкин. Менә шул гадәте аны иптәшләре арасында түгел, читрәк кешеләр арасында кырыс, кеше белән бик үк исәпләшмәүче төрпә холыклы кеше итеп танытты. Әмма, асылда, Шәйхи алай түгел, ул кешегә яхшылык эшләргә әзер торучы киң күңелле кеше иде. Холкының шулайрак булуы аркасында ул Бөек Ватан сугышы чорында да шактый ук кыенлыкларга дучар булды. Фронт газетасында эшләгәндә, бер капитан белән милли мәсьәләдә сүзгә килешеп, аңа, гадәтенчә, һич юл бирмичә каты гына әйткән. Нәтиҗәдә, аны дивизия газетасына хезмәт итәргә җибәрделәр. Ул, татар газетасында үз телендә эшлисе урында, урысча язарга мәҗбүр булды.

Язучылар съездында Афзал Шамов турында каты гына әйтеп, соңыннан Шамов аның үзен шактый ук кыен хәлгә куйган иде. Мин соңыннан аңа: «Съезддагы чыгышларың бик үк уңышлы булмады, үзеңне кимсетә торган сүзләр әйтергә юл ачтың. Үкенмисеңме?» – дидем. Ул, юка иреннәрен кысып: «Юк, үкенмим», – диде.

Җыелышларда ул усал тәнкыйть белән чыккалый иде. Үзенең дә әйткәне бар: «Мин җыелышта җенемне чыгарырлык берәр хәл булса гына сөйлим», – дигән иде. <...>

1980, 23 июнь

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 8 нче санында.

[1] Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кулъязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 464 б.

Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур дусларымның вафат булуларына берсенә – бер ел, икенчесенә ике ел тулып килә. Шул уңай белән «С.Т.» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Миргалим Харисовка аларга багышлап әдәби сәхифәләр чыгарырга киңәш иттем. Каршы булмады, хуп күрде. Шундый тәкъдим кузгатканмын икән, үземә дә катнашырга кирәк бит. Ш.Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән повесте хакында матбугатта берни дә булмавы борчып тора иде. Шушы арада әлеге повесте турында газетага рецензия яздым: «Бар ул чын мәхәббәт, бар!» дип атала. Казанга кайткач, Ш.Маннурның каберенә таш кую мәсьәләсен тизләтәсе булыр. Ай-һай калын тиреле дә инде без! Ике ел тулып килә бит үлгәненә, ә без аның каберенә шул ташны гына да куя алмыйбыз. Оят! <...>

1982, 3 июнь

Сулдан уңга: Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов (утырганнар); Хәмит Ярми, Шәйхи Маннур (басканнар). 1979 ел

Бүген Шәйхи Маннурның туган көне. Аның васыяте буенча өч премия билгеләп, аны Маннур туган көндә авылына[2] барып тапшырырга хәзерләндек. Жюри оештырдык, премияләрне кемгә бирү мәсьәләсен хәл иттек. Берсе – Ринат Мөхәммәдиевкә, икенчесе – Зөлфәткә, өченчесе алдынгы колхозчыларга биреләсе иде. Премия алырга тиешле кешеләргә дипломнар яздырдык. Әмма кичә, 14 гыйнвар көнне мин авырып киттем, ашказаныма әллә ни булды, төнлә температура күтәрелде. Өйдәгеләр дәваладылар. Әмма бүген иртә торгач, миңа Мамадышка бармаска әйттеләр. Минем хәлем чынлап та яхшы түгел, кичә бик какшап калганмын, йөрәк сикерә, баш әйләнә иде. Шулай да, һәммәсе көйләнеп беткәннән соң бармыйча калуы бик кыен булды. Иптәшемнең туган көнендә аның авылында булып, васыятен үз кулым белән үтәгән булсам, бераз күңел тынычланган булыр иде. Үкенечтә калды. Күрәсең, картлык баса башлагандыр инде. Аяныч.

1983, 15 гыйнвар

Бүген, исән булса, Шәйхи дустыма 90 яшь тулган булыр иде. Ул 1905 елның 15 гыйнварында туган. Миңа һәм шагыйрь Илдарга[3] васыятьнамәсен (үзенең күзе йомылгач ачу шарты белән) 1970 елның 12 гыйнварында биргән иде. Безнең Киров районындагы 10 нчы шифаханәгә операциягә керүенә каршы килүебезгә карамастан, шунда керде һәм 1980 елның 12 июнендә, ашказанына операция ясалганнан соң, операция вакытында үпкәсенә салкын тиюдән, бик азапланып, шунда вафат булды. Васыятьнамәсендә язылуы буенча без аны Илдар белән 1980 елның 13 июнендә туган авылы Тулбайга алып кайтып, анасының кабере янында күмдек.

Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун.

Урыны оҗмахта булсын.

1995, 15 гыйнвар ■

[2] Хәзерге Мамадыш районының Тулбай авылы. – Редакция.

[3] Илдар Юзеев (1933-2004).

Безнең мирас №9 сентябрь 2019

СӘЕР ДУСТЫБЫЗ ШАМИЛ

Әгъзам Фәйзрахманов

Шамил Рәкыйпов исеме укучыларга яхшы таныштыр, дип уйлыйм. Төрле жанрларда иҗат итсә дә, Бөек Ватан сугышы кырларында тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән милләттәшләребез, якташларыбыз турындагы әсәрләре аңа популярлык китерде. Шамил сәнгати чаралар ярдәмендә реаль каһарманнарның характерларын зур осталык белән ачып бирә алды. Бу әсәрләрне укыганда үзеңне шул каһарманнар белән янәшә сизәсең, аларга сокланасың. Әлбәттә, образларны шул дәрәҗәдә тудыру өчен осталык та, ныклы әзерлек тә кирәк. Хәтерлим, Шамил архивларда казына, геройлары узган юллар буйлап та уза иде, туган-тумачалары, аларны яхшы белүче затлар белән дә кат-кат очрашырга тырышты. Гадәттә, шуннан соң гына өстәл артына утырып язарга керешә.

Ш.Рәкыйпов моңарчы киң катлау халыкка бик үк мәгълүм булмаган фактларны да, архив материалларына таянып, укучыларына җиткерде. Әйтик, фашист амбразурасын беренчеләрдән булып күкрәге белән каплаган Алесандр Матросовның милләттәшебез Шакирҗан Мөхәммәтҗанов булуын ул ачыклады. Шушы ук батырлыкны кабатлаган Газинур Гафиятуллин турындагы язмасын да тыныч кына укып булмый. Шундый ук батырлык авторы Барый Шәвәлиев турында Шамилнең «Чәчәкләр сөйли белә» повесте дөнья күрде.

Республикабыз укучылары Ш.Рәкыйпов тырышлыгы нәтиҗәсендә якташыбыз Гази Заһитовның фашистлар оясы Рейхстаг өстенә Җиңү байрагын беренче булып кадаганын белде. Безне мәктәпләрдә байракны Рейхстагка беренче булып рус һәм грузин егетләре күтәргән дип өйрәттеләр. Мөгаен, пропаганда өчен шулай кирәк булгандыр. Чөнки руслар – илнең төп милләте, ә илнең башлыгы – грузин.

Советлар Союзы Геройлары – очучы Мәгубә Сыртланова белән керәшен кызы Ольга Санфирова турындагы «Кызлар-йолдызлар» трилогиясе, дәһшәтле сугыш еллары инде бездән ерагая барса да, укучыларыбызның һаман сокланып укый торган китабы булып кала. Сугышка кадәр Казанда трамвай йөртүче булып эшләгән легендар партизан Иван Кабушкин, Советлар Союзы Герое Гыйлфан Батыршин, аның хәрби дусты Иван Чернопятко кебек Шамил иҗат иткән үлемсез образларны күпләп санарга була.

Хәтерем ялгышмаса, Советлар Союзы Герое, генерал-полковник, иң авыр чорда, иң хәтәр участокларда җитәкчелек иткән Василий Гордовка багышланган «Берәү дә мәңгелек түгел» повесте – язучының соңгы әсәре. Исемен дә нindине куйган бит! Бәлки ул үз гомеренең дә күп калмаганын сизенгәндер. Гомеренең соңгы елларында

Шамил каты авырды, дөньяга чыгып йөри алмады, өендә генә ятты. Кичләрен миңа шалтыратып, озаклап сөйләшергә ярата иде ул. Үзенең хәле бик авыр булса да, миңа бер үк сүзләрне кабатлый иде: «Үзеңне сакла, син редакциягә кирәк, халыкка кирәк».

Матбугатта эшләү чорында миңа Шамилнең туган ягы Чүпрәледә берничә тапкыр булырга туры килде. Мөмкинлек чыккан саен, бергә кайтырга тырыша идек. Туган авылы Яңа Чокалыда булганда, Ш.Рәкыйпов иң башта зиратны әйләнеп чыга. Һәр кабер янында туктала, эченнән генә нәрсәдер пышылдый. Вакыт-вакыт күзләреннән яшь тама. Мин, аңа комачауламаска тырышып, читкәрәк китәм. Күрәсең, ул андый чакларда бакыйлыкка күчкән туганнары, якташлары белән сөйләшеп йөргәндер, дога укыгандыр.

Яңа Чокалыда соңгы вакытларда туганнары юк иде аның. Инде нык искергән, җиргә сеңеп бара торган туган йорты йозакта булды. Йорт тирәли кат-кат әйләнеп чыккач, ул капка алдында ятучы черек бүрәнәләр өстенә килеп утыра иде. Сәгатьтән артык беркем белән дә сөйләшми, аның янына килергә ярамый. Соңгы кайтуыбызда фотохәбәрче Нурислам Исмәгыйлев Шамилне шунда утырганда төшереп алган иде. Йорты кебек, үзе дә нык таушалган; картайган, хәлсезләнгән булуы йөзенә чыккан. Бу фото төшерелгәннән соң ел ярым үткәч, Шамил бакыйлыкка күчте. Кызганыч, без зур талантны иртәрәк югалттык.

Белмим, бүрәнәләр өстендә нәрсә турында уйланып утыргандыр ул. Аның авылдагы тормышы авыр да, фаҗигале дә була. Мөгаен, шул вакыйгаларны хәтер сандыгыннан актарып утыргандыр. Аның яшьлеге дәһшәтле сугыш елларына туры килә. Укытучы гаиләсендә туган малай яшьтән үк колхоз эшендә тир түгә: сукалый да, тырмалый да, чәчә-ура да, атлар да көтә. Тырышлыгын исәпкә алыптыр инде, аны амбар җитәкчесе итеп билгелиләр. Менә шул чорда җавапка тартыла да инде Ш.Рәкыйпов. Ач халыкка хезмәт көне исәбенә бераз ашлык бирүне зур җинаятькә саныйлар, 1950 елда ун елга мәҗбүри хезмәт колониясенә җибәрәләр.

Ничек шулай килеп чыккандыр, әйтүе кыен. Авылда амбар мөдире әллә ни зур җитәкче түгел. Колхоз рәисе, аның урынбасарлары, агрономнар, партком секретаре, эреле-ваклы башка җитәкчеләр бар. Әмма, ничек кенә булмасын, Ш.Рәкыйповка Красноярск крае шахталарында чиләнергә туры килә. Бу гаделсез бәладән Сталин культы фаш ителгәч, 1954 елда гына котыла ул.

Үзенә карата гаделсезлек йогынты ясагандыр, Шамил, сөргеннән кайткач, авылда калырга теләми, Казанга китеп бара. 1 нче трамвай-троллейбус паркында эшләп ала, 1957 елның көзендә «Татарстан яшьләре» газетасына күчә. Шамил Рәкыйпов калган гомерен тулысынча мәдәниятка, әдәбиятка, журналистикага багышлады. 1966-1993 елларда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясен, 1993-2000 елларда «Шәһри Казан» газетасы редакциясенең әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкләде. Һәр җирдә мишәрләрчә үҗәтләнеп эшләде.

Гаҗәп үзенчәлекле, шул ук вакытта бераз сәеррәк тә кеше иде ул. Гаилә тормышы барып чыкмады. Ул, инде шактый олыгая төшкәч, киемнәрен генә алып, фатирыннан чыгып китә. Үзенә куыш тапканчы, ярты елдан артык, «Шәһри Казан» редакциясенең архив бүлмәсендә яшәп торды. Һәркемгә бары яхшылык кына эшләргә тырышса да, вакыты белән бик сәер кеше булып тоела иде. Нинди дә булса язманы тикшереп утырганда сүзне бөтенләй икенчегә борып, туган авылы Яңа Чокалы табигатен мактарга керешә. Янәсе, аннан да матуррак авыл беркайда да юк. Була да алмый. Гадәттә, авылы турында сөйләп аргач, Шамил сүзен: «Һавасын сулап кара син аның, баш авыртуның нәрсә икәнен белмичә рәхәтләнеп йөрисең», – дип тәмамлый иде.

Озак еллар якын дуслар булып яшәсәк тә, мин аны барыбер аңлап җиткерә алмадым. Бервакыт шулай туган авылына кайткач, ул мине болынга алып китте. «Әйдә, барып, бераз утырып кайтыйк әле, андагы кебек матур чәчәкләр бүтән бер җирдә дә юк», – ди бу. Бардык. Әмма гап-гади болын иде ул. Чәчәкләре дә юк диярлек. Мин үзебезнең авыл чәчәкләре турында сөйләргә җыенгач, Шамил мине бүлдерде: «Сөйләшми генә утырыйк әле, җилнең ыңгырашуын тыңлыйк», – ди. Тыныч кына шактый озак утырдык. Шулай да мин бернинди ыңгырашу ишетмәдем.

Шамилнең безнең арадан китүенә 13 ел чамасы вакыт үтте. Мин аны һаман юксынам. Кинәт кенә килеп чыгар да, җилнең ыңгырашуын, яфракларның гәпләшүен тыңларга тәкъдим итәр кебек тоела. ■

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ОЕШУЫНА 85 ЕЛ

Сурәтле хатирә

Совет Армиясенең 60 еллыгына багышланган «Әдәби җомга» кичәсеннән соң. Беренче рәттә сулдан уңга: Габдулла Шәрәфетдинов, Зәйни Шәһиморатов, Атилла Расих, Госман Бакиров, Сибгат Хәким, Нури Арслан, Әхмәт Исхак; икенче рәттә: Г.Шәрәфинең хатыны Сәйдә, Туфан Миңнуллин, Хәй Вахит, Сафа Сабиров, Нур Гайсин, Хатип Госман, Кояш Тимбикова, Мөршидә Хәкимова (С.Хәким хатыны), Ә.Исхакның хатыны Гөлсем; өченче рәттә: Мөхәммәт Садри, Геннадий Паушкин, Лирон Хәмидуллин, аның хатыны Дания,Мәҗит Рәфыйков, аның хатыны Раушания, ... Яхин, Нәби Дәүли, Мария Елизарова, Гариф Ахунов, Шәһидә Максудова (Г.Ахуновның хатыны), Әбрар Шамин, Әхмәт Рәшитов. Тукай клубы. 24 февраль, 1978 ел

Татарстан Язучылар берлегенең Сигезенче съезды вакытында. Сулдан уңга: Разил Вәлиев, Фәннур Сафин, Лирон Хәмидуллин, Празат Исәнбәт, Зәет Мәҗитов, Мирсәет Яруллин, Миргалим Харисов, Ризван Хәмид, Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт. 1974 ел

Фотолар Лирон Хәмидуллин архивыннан алынды.





Тарих шаһитлары

«Фотосурәт барлыкка килү кешелек дөньясы өчен китап бастыру кебек әһәмиятле».

С. Вавилов

Казандагы Воскресенская (Спас, Чернышевский) урамы. «Оптика» кибете

Караңгы бүлмәгә кечкенә генә тишектән кояш нурлары төшкән яссылыкта тышкы дөньяның сурәтләре күренә. Бу сурәтләр шул ук формада, шул ук төсләре белән, ләкин чынлыктагы күренештән бик күпкә кечерәк һәм кирегә әйләндерелгән кыяфәттә. Караңгы бүлмәнең бу үзенчәлеген (камера-обскура) безнең эрага кадәр IV гасырда яшәгән борынгы грек фәлсәфәчесе Аристотель дә белгән. Камера-обскураның эш принциплары турында бөек итальян галиме, Яңарыш чоры рәссамы Леонардо да Винчи да үзенең хезмәтләрендә яза. Геофизик, астрономик һәм башка төрле оптик приборлар барлыкка килү камера-обскураның камилләшүенә этәрә. Алгы өлеше ике якка кабарып торган линзалы, ә арткы өлешендә үтә күренмәле кәгазь яисә тонык пыяла куелган тартманы камера-обскура дип йөртә торган заманнар килеп җитә. Бу прибор тышкы дөньяны механик рәвештә сурәтләү өчен хезмәт иткән. Кирегә әйләндерелгән сурәтне күзге ярдәмендә дөресләгәннәр һәм карандаш белән кырыйларыннан йөртеп чыкканнар.

Бу инде «фотосурәткә кадәрге фотосурәткә төшерү» булган. Кешеләр, яктылыктагы сурәтне камера-обскурада бер ноктага җыеп кына калмыйча, аны яссылыкка ышанычлы итеп беркетү юлларын эзләгәннәр. Ләкин, оптика буенча уйлап табулар бик күп гасырлар элек башланган булса да, химия өлкәсендәге мондый ачышлар, химия шактый алга киткән чорга, XVIII гасырга гына карый. Фотосурәткә төшерү буенча иң бөек ачыш рус һәвәскәр химигы, дипломат А.П.Бестужев-Рюмин белән немец анатомы һәм хирургы И.В.Шульце тарафыннан ясала. А.П.Бестужев-Рюмин 1725 елда сыек дарулар кушылмасы ясаганда кояш нурлары төшү нәтиҗәсендә тимер тозлары эремәсенең төсләрен үзгәртүенә игътибар итә. Ике елдан Шульце да бром тозларына

Маякчы гаиләсе. Чулман (Кама) елгасы. XX гасыр башы

яктылыкның тәэсир итүен исбат итә. 1818 елда рус галиме Х.И.Гротгус фотохимиянең төп законын ача: матдәләрдә фотохимик процесслар яктылык тәэсирендә бара. Соңрак, Гротгуска бәйсез рәвештә, әлеге үзенчәлекне инглиз галиме Д.Гершель һәм америка профессоры, химик Д.Дрейпер да исбатлап чыкты. Шуңа күрә хәзер фотохимиянең төп законы Гротгус-Гершель-Дрейпер законы дип атала.

Рәсми рәвештә фотосурәтнең туган елы дип 1839 елны саныйлар. Физик Д.Ф.Араго Париж Фәннәр академиясендә, уйлап табучы Л.Ж.Дагер хөрмәтенә аның исемен биреп, сурәт ясау ысуллары турында доклад ясый. Бу өлкәдә Дагерга кадәр Ж.Н.Ньепс та тәҗрибәләр ясый, ул инде 1827 елда ук үзенең «Гелиография турында язма» дип аталган хезмәтен һәм эш үрнәкләрен Британия корольлек җәмгыятенә җибәрә. 1829 елда «Ньепс-Дагер» коммерция предприятиесе оеша, алар бу өлкәдәге иҗади эшне бергәләп башкарган, күрәсең. 1841 елда Англиядә фотосурәткә төшерүнең тагын бер алымы – калотипиягә (грек сүзе *калос* – матур, *типос* – басылган дигәнне аңлата) па-

I гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтрәхим Юнысов (рәсемдә уртада) замандашлары белән

Татар руханилары

Урта хәлле татар гаиләсе

Туйдан соң: С.В.Салихов һәм аның хатыны Зөһрә. 1906 ел

тент бирелә. Бу ачышның авторы В.Г.Талбот була. Ньепс-Дагер ысулы белән сурәтләр дөрес формада барлыкка килә, Талбот ысулы, сурәтләрне кире итеп күрсәтсә дә, уңай ягы да була: сурәтне күпләп бастыру мөмкинлеге бирә. Шулай итеп, Ньепс, Дагер һәм Талбот хаклы рәвештә фотосурәткә нигез салучылар булып санала.

Камера-обскурадан хәзерге заман фотоаппаратларына кадәр бик зур юл узылган. Фотоаппаратны, фотосурәтне камилләштерү белән төрле илләрнең тикшерүче-конструкторлары – французлар Ф.Физо, А.Клоде, мажар Й.Петцваль, рус А.Греков, америкалы С.Морзе һәм башкалар шөгыльләнгән.

XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында фотосурәткә төшерү бик дәрәҗәле, иң мөһиме: керемле эш саналган. Әмма ул – күп көч, басылып эшли белү, чисталык һәм түземлек

сорый торган авыр хезмәт. Мондый эшне бөтен кеше дә ерып чыга алмый, шуңа күрә фотосалоннар еш сатылган, яңа хуҗалар, яңа исемнәр барлыкка килгән.

Фотосурәтләрдә кешеләрнең күңел халәте чагыла һәм фотога төшерү объектларын да һәр кеше үз күңел халәтеннән чыгып сайлый. Гадәти фотолар – истәлеккә төшерелгән портретлар, гаилә фотолары белән беррәттән, кеше тормышында әһәмиятле урын алган вакыйгалар – туй фотолары, хәрби хезмәт вакытындагы, дуслар очрашкандагы күренешләр төшерелгән фотолар да бихисап.

Игътибарлы караштан берсе дә читтә калмый: тирәяктагы әйберләр – матур аяклы өстәлләр, чын тиредән ясалган затлы канәфиләр, вен урындыклары һәм, әлбәттә, фотога төшүченең кыяфәт-торышы.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов һәм Әминә Гомәр кызы Измайлова (кыз чагындагы фамилиясе – Баязитова). 1935 ел

Фотосалоннар фото төшерүчеләр уңайлы шартларда сыйфатлы, әйбәт фотосурәтләр ясасын өчен ачылган һәм алар күпмедер дәрәҗәдә мәдәни оешма хезмәтен дә үтәгән. Фотога төшү һәркемнең тормышында, бик зур булмаса да, әһәмиятле, истәлекле вакыйга булган.

Казанда Зур Проломный урамында – А.Г.Шумиловның, Адмирал бистәсендә – К.Т.Сафоновның, Черек күлдә, Гостиный дворда – А.П.Вяткинаның, Лобачевский урамында – С.И.Ивановның һәм А.П.Колокольниковның , Воскресенская урамында (бишәү!) – В.П.Бебин, В.Г.Федоров, Г.В.Локке, И.М.Якобсон һәм С.Фейзерларның фотога төшерү йортлары булган. А.А.Несмелов, А.Ф.Соловьев, А.Ф.Мухиналарның фотосалоннары бик популяр саналган. Түбән Новгород фоторәссамнары һәм иҗтимагый эшлеклеләре М.П.Дмитриев, В.И.Бреев та Казан фото тарихында үз эзләрен калдырган.

Казан күренешләрен чагылдырган открыткалар меңнән артык. Бу открыткаларда урамнар, аерым йортлар, шәһәр чите, Идел, Кама пейзажы, шәһәребезнең үзәген күрә аласыз. Бигрәк тә Воскресенская урамы (Спас, Чернышевский, Ленин, хәзер Кремль урамы), Зур Проломный урамы (Бауман урамы), Грузин урамы (К.Маркс урамы), Театр урамы (Ирек Мәйданы), Иванов урамы (1 май урамы), Рыбноряд (Кооператив, Куйбышев, хәзер Тукай мәйданы) урамы открыткаларда еш чагылыш тапкан.

Хаҗи ***Абдулла Дубин****,*
тарихчы, төбәкне өйрәнүче.
Фотолар А.Дубин архивыннан алынды. ■

МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ САБАКТАШЛАР

Ләбиб Лерон

Олы Имән авылы күренеше

Ания апа турында тәфсилләбрәк сөйлим әле.

Ания Нуретдин кызы 1933 елның 10 сентябрендә Калинин районының (хәзерге Актаныш районы) Иске Айман авылында туган. 1934 елда алар гаиләсе шул ук райондагы Киров авылына күчә. Ания апа башлангыч белемне шул авыл мәктәбендә ала. Аннары Иске Сәфәр авылының җидееллык мәктәбендә укый.

1948-1952 елларда Ания апа Минзәлә педучилищесында һөнәри белем ала. Читтән торып Алабуга институтының татар теле факультетын тәмамлый. 1952 елда Киров мәктәбендә рус теле укытучысы булып эшли башлый. 1953 елдан пенсиягә чykканга тиклем мин үскән Олы Имән (халык теленә Олыймән дип кергән) авылының башлангыч мәктәбе укытучысы вазыйфасын башкара.

1955 елда Ания апа Әнвәр Хәтимовка кияүгә чыга. Аларның бер-бер артлы дүрт баласы дөньяга килә: Раушания, Җәмилә, Илдар һәм минем булачак сыйныфташым Айзирәк. Ни кызганыч, язмыш кайчагында шундый аяусыз, рәхимсез: яраткан ире, дүрт бала атасы Әнвәр абый, көтмәгәндә, 1966 елда бакыйлыкка күчә. Без, бала-чагалар, өлкәннәр белән бергә, вафат булган бихисап авылдашларны мәңгелек йортларына озатыштык. Кемнәрне озатканыбыз инде хәзер истә калмаган, әмма Әнвәр абыйның вафат булган көнен, нигәдер, мин әле дә яхшы хәтерлим. Ания апа бүген дә сөекле ирен – Әнвәр абыйны сагынып яши, шигырьләр яза:

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

Еллар үтте, балаларың үсте –
Укып, таралышып беттеләр.
Ә аңынчы, таңнар аткан саен,
Әткәй кайтыр, диеп көттеләр.

Хәсрәтемне тышка чыгармадым,
Сиздермәскә тырышып яшәдем.
Яшем белән юдым хәсрәтемне –
Хәзер инде кипте яшьләрем.

Үкенмәдем үткән гомеремә,
Бирешмәдем көчле җилләргә.
Үз-үземне яклый алдым, шөкер,
«Аш» булмадым усал телләргә...

Ания апа Әбүярова

Өч яшьтән – ятим, утыз өч яшьтән тол калган Ания апага дүрт баланы тәрбиләп үстерү, шул ук вакытта мең төрле холыклы бездәйләрне укыту җиңелдән булмагандыр. Әмма, ничек итсә итте, Ания апа дүрт баласын да аякка бастырды, укытты, кеше итте. Олы кызы Раушания, ике институт тәмамлап, Югары Яхшый авылы мәктәбендә пенсиягә чаклы тарих фәнен укытты. Ире Марат белән өч бала үстерде. Бүген аларның биш оныгы бар. Җәмиләсе исә, Минзәлә техникумын тәмамлап, Олы Имән авылында бухгалтер булып эшләде. Бүгенге көндә лаеклы ялда. Җәмилә апа ире – миңа Асия җиңги ягыннан туган тиешле Ирек абый белән өч бала үстерде. Аларның дүрт оныгы бар. Илдар Минзәлә техникумында укып, агроном булды. Хәзерге вакытта Чаллыда – «Горзеленхоз»да эшли. Хатыны Гөлсинә белән ике кыз үстерде. Өч оныгы бар аларның. Ания апаның кече кызы Айзирәк, шулай ук Минзәлә техникумын тәмамлады, юрист һөнәрен үзләштерде, Чаллыда тикшерүче ярдәмчесе булып эшләп, пенсиягә чыкты.

Ания апаның кече кызы Айзирәк

Кыскасы, Ания апа бүген хезмәт ветераны. Аның дүрт баласы да исән, шөкер! Укытучымның сигез оныгы, унике оныкчыгы-торыны бар. Хәзерге вакытта Олы Имән авылында, кече кызы Айзирәк тәрбиясендә яши. Хәтере бик шәп Ания апаның. Дөньялыктан хәбәрдар: бөтен татар матбугатын укып бара. Күрешеп, хәл-әхвәлләр алышуга, минем гаиләм турында, балаларым һәм оныкларым хакында сөйләргә тотына. Каян барысын да белә, ничек исендә тота икән, дип, таң калып тыңлыйм үзен...

Ания апаның улы Илдар

Мәктәп укучысы Ленарис (Лемон, Ләбиб) сыйныфташы Данир Сафин белән

1971 елда без таш мәктәптә укый башладык. Мәктәпне беренче сыйныф укучысы, әнием ягыннан туган тиешле Лена апа белән Мөдәррис абыйның (алар вафат булганга да ун ел вакыт узган икән инде, урыннары җәннәттәдер, шәт!) олы улы Рафис Әһәзов ачты. Таш мәктәп – таш мәктәп инде: якты, матур, иркен. Шулай да агач мәктәбем хәтеремдә якты хатирә булып урын алды. Ул агач мәктәп юк инде, ә менә таш мәктәп бар. Дөрес, хәзер инде анда белем алучы бала юк: киләчәге юк, балалар саны аз, дип аны яптылар да куйдылар. Хәерлегә булсын... Хәзер балалар сигез чакрым ераклыктагы Киров мәктәбенә барып укый. Кайчандыр мин укыган мәктәптә.

Ания апа мәктәп эше белән районга-фәләнгә барган чакта, безне фронтовик Шәрип абый Каюмов (сыйныфташым Азатның әтисе) белән Югары Яхшый мәктәбендә укыганда безнең класс җитәкчесе булачак, татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирәчәк Әбугали абый Вәлиевнең хатыны, классташым Илһарның әнисе Тәнзилә апа Ситдыйкова да укытты.

Тәнзилә апага бәйле бер хатирә.

Өченче класста, әлеге дә баягы таш мәктәптә укый башлаган чак. Бер дәрес вакытында ул безгә җырлар өйрәнеп килергә кушты. Мин «Нәниләр шатлана» дигән китаптан (төзүчесе Нәкый Исәнбәт дип истә калган) бер шигырь таптым. Икенче көнгә шуны ятлап килдем. Чират миңа җиткәч, шул шигырьне үземчә көйли башладым:

Зәңгәр күлмәгеңне киеп,
Кая бардың син бая?
Әй, дубыр-дубая,
Кая бардың син бая?..

Тәки ерып чыктым мин моны. ХәзерТәнзилә апа мине үтереп мактый инде, дип көтеп торам. Ә ул, җырлап бетерүгә:

– Син моны бүтән җырлама инде, җәме?! – диде.

– Нәмәгә? – дидем мин.

– Сиңа иртә әле мондый җырлар җырларга, – диде Тәнзилә апа. Балаларга мәхәббәт турында җырларга ярамый иде шул ул елларда... Хәзерге балалар нинди җырлар гына җырламый – исләрең-акылларың китәрлек!

Ания апа белән хатирәләр яңартабыз. Ул сөйли, мин тыңлыйм. Минем исемдә калмаганнарны да хәтерли укытучым. Картайдым инде, туксанга якынлашам бит, ди. Быел гыйнвар аенда язган шигырен яттан сөйли башлый:

Йөгерә – чаба эшләп йөри
Һәркем дә яшь чагында.
Картлык-явыз егып сала
Карават кочагына.

Картлыкны көтеп алмыйсың,
Эзләп таба, чукынчык.
Яшьлекне күрәсең килсә,
Хәлең булса, йөгереп чык...

Олы мәктәбе. Ания апа. Сыйныфташлар...

Сыйныфташлар, дигәннән... Сыйныфташым Индус Хәйретдиновның әнисе Гөлсимә апа Олы Имәндә фельдшер булып эшләде. Бик мөлаем, күркәм апа. Тумышы белән Минзәлә районының Бикбау авылыннан дип беләм. Бикбау авылы кешеләре очраганда, әйтик, шул авыл тумасы, күренекле җырчыбыз, искитмәле тавыш-моң иясе Рөстәм Маликов белән күрешкән чакта, сүз уңаеннан, мин аңа: «Сезнең авыл кызы Гөлсимә апаны безнең Фидус абый Олыймәнгә кәләш итеп алып кайткан. Аларның улы Индус белән без мәктәптә укыганда аерылмас дуслар идек!» – дип әйтеп куйгалыйм. «Чәчәк авыруы»на каршы укол кадаган вакытта, без – Индус белән икәү, Гөлсимә апа хозурында (медпунктта, ягъни мәсәлән) күренмәскә тырышып, үзебезчә егетлек күрсәткән булып, шактый качып йөргән идек. Соңыннан барыбер укол кададылар анысы...

Һәммәсе – күңелдә, хәтердә. Күңелдә йөргәннәр, хәтердә сакланганнар, азлап-азлап булса да, ак кәгазь битләренә күчә...

Фотолар Ания Әбүярова һәм Ләбиб Лерон архивларыннан алынды. ■

Истә, һаман да истә!

Композитор Шамил Шәрифуллинның тууына 70 ел



Композитор, педагог, фольклорчы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге (2005) һәм РСФСРның Д.Шостакович исемендәге (1985) Дәүләт премияләре лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1992) Шамил Камил улы Шәрифуллин 1949 елның 13 сентябрендә Төрекмәнстан ССРның Чарджоу өлкәсендәге Фараб бистәсендә туган.

«Баян» белгечлеге буенча Ашхабад музыка училищесында, соңрак Казан музыка укуханәсендә белем ала.

Ш.Шәрифуллин 1974 елдан СССР Композиторлар берлеге әгъзасы иде.

Әсәрләре: «Йосыф һәм Зөләйха» (балет), «Диалоги сфер» (симфония), «Татар биюләре» (симфония), «Татарские буколики» (симфония), «Җыен» (оркестр өчен концерт), «Дала» (симфоник поэма), «Мөнәҗәтләр» (хор өчен acapella концерты), «Авыл көйләре» (хор өчен концерт), «Сары сандугач» (хор өчен концерт), «Чәчәк турында җыр» (оратория-балет) һ.б.

Ш.Шәрифуллин 2007 елның 22 декабрендә вафат булды.

Артист Әнвәр Фәсхетдиновның тууына 100 ел

Театр артисты, ТАССРның халык һәм РСФСРның атказанган артисты Әнвәр Сәгъди улы Фәсхетдинов 1919 елның 19 сентябрендә Минзәләдә туган.

1933 елда җиде классны тәмамлаганнан соң, төрле оешмаларда эшли, бер үк вакытта үзешчән сәнгать түгәрәкләренә дә йөри.

1940 елда Совет Армиясе сафларына алына. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1946 елга кадәр хәрби хезмәттә була. Сугышта кылган батырлыклары өчен «Дан ордены», шулай ук «Батырлык өчен» һәм «Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Сугыштан кайтуга, ул Минзәлә драма театрына эшкә урнаша.

Ә.Фәсхетдинов бик күп спектакльләрдә уйный. Мәсәлән, Х.Ибраһимов пьесасы буенча куелган «Башмагым» спектаклендә – Галимҗан, «Алтын көз»дә (Г.Насыйри әсәре) – Гариф, «Акчарлаклар»да (Ә.Фәйзи) – Зиннәт, «Зәңгәр шәл»дә (К.Тинчурин) – Булат, «Тамырлар»да (Ю.Әминев) – Гомәр, «Утлы өермә»дә (Ә.Мирзаһитов) Айтуган рольләрен башкара.

Ә.Фәсхетдинов 1995 елда вафат булды.

Язучы Шамил Рәкыйповның тууына 90 ел

Язучы, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979) Шамил Җиһанша улы Рәкыйпов 1929 елның 22 сентябрендә Татарстанның Чүпрәле районындагы Яңа Чокалы авылында игенче гаиләсендә туган.

1942 елда авыл мәктәбенең җиде сыйныфын бетерүгә үк, хезмәт юлын башлап җибәрә: әүвәл туган авылында гади колхозчы, трактор бригадасы учетчигы, аннары 1950-1954 елларда Донбасста һәм Урал белән Красноярск якларында таш чыгаручы, шахтада бурильщик, балта остасы, бетончы, электросварщик хезмәтләрендә була.

1955 елда Казанга килә һәм 1957 елның җаенә кадәр трамвай паркында электрик-моторист булып эшли. Аннары аны, сәләтле журналист буларак, «Татарстан яшьләре» газетасына эшкә чакыралар. Монда ул башта әдәби хезмәткәр, аннары тәрҗемәче вазыйфаларын башкара.

Шамил Рәкыйпов 1966 елда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире итеп билгеләнә.

Беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре – очерк, хикәя һәм сәхнә әсәрләре – матбугатта 1956 елдан күренә башлый.

1967 елда аның татар халкының тугрылыклы улы Барый Шәвәлиев турында «Чәчәкләр сөйли белә» исемле повесте басылып чыга. Шулай ук Иван Кабушкин турындагы «Кайдан син, Жан?» (1968), татарлардан беренче буларак Советлар Союзы Герое исемен алган Гыйльфан Батыршин турындагы «Таңнар һаман матурмы?» (1969), данлыклы хатын-кыз очучы Мәгубә Сыртланова белән аның полкташлары батырлыгына багышланган «Кызлар-йолдызлар» (1972) һ.б. әсәрләрен дә укучылар яратып каршы алды.

Ш.Рәкыйпов 1966 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Ул 2005 елның 17 февралендә вафат булды.

Режиссер Габдулла Йосыповның тууына 120 ел

Режиссер, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957) Габдулла Фәтхулла улы Йосыпов 1899 елның 27 сентябрендә туган.

Ул иҗади эшчәнлеген 1929 елда башлый. Мәскәү, Ленинград, Архангельск театрларында эшли.

1948-1961 елларда – Татар дәүләт академия театры һәм 1963-1968 елларда – Әлмәт татар драма театрының баш режиссеры.

Г.Йосыпов куйган кайбер спектакльләр: «Чын мәхәббәт» – Т.Гыйззәт (1948), «Рәйхан» – Н.Исәнбәт (1952), «Зәңгәр шәл» – К.Тинчурин (1966).

Г.Йосыпов 1969 елда вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

«ӘНВӘР»

Әхтәм Зарипов

«Нурлы», «нур көлтәсе» дигәнне аңлатучы шушы гарәптән кергән сүзне ислам динен тотучы милләтләр яңа туган малайларына исем итеп кушалар. Күп очракта бу исемнең хуҗасы сүзнең мәгънәсен аңламаганлыктан, алар арасында аны акламаганнары да очрый. Без язасы очракта «Әнвәр» исеме җисеменә муафыйк булганлыктан, сүземне озынга сузмый, исем хуҗасы белән таныштыруга күчәм.

Әнвәр Фәсхетдинов – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты – бөтен гомерен Минзәлә театрында иҗат итеп, Татарстан, Башкортстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан һәм Себердә гомер иткән татарларга кешелек нуры тараткан зат буларак хәтерләрдә яшәүче шәхес.

Аны беренче тапкыр кайда, нинди рольдә күрүемне төгәл генә әйтә алмыйм. Әмма аның «Галиябану»да – Хәлил, «Башмагым»да – Галимҗан, «Алтын көз»дә Гариф исемле җырлы рольләрдәге чыгышларын үзебезнең авыл сәхнәсендә күрүемне хәтерлим.

10 нчы сыйныфны бетереп, өлгергәнлек аттестаты алып чыккач, агитбригадада баянчы булып йөргәндә, язмыш мине Минзәлә театры белән таныштырды. Кыюлыгымны җыеп, мин әлеге театрда эшлисе килүемне белдерергә җөрьәт иттем. Бу – 1955 елның декабрь аенда, Минзәлә театрының Актаныш районындагы Аеш авылында А.Островский әсәре буенча куелган «Бирнәсез кыз» спектакле белән гастрольләре вакытында иде. Икенче көнне үк мин, агитбригадада эшләп йөрүемне ташлап, Минзәлә театры эшчесе буларак, аларга ияреп киттем. Кемнәр белән сөйләшеп, нинди шартларда эшләргә алынуым турында элек язып чыкканлыктан, кабатлауны кирәксез санап, Әнвәр абый белән танышуымның хәтердә калган мизгелләрен генә язып узам.

...Ачы буранлы көн иде. Театр «Пучы» авылыннан «Аю»га күченергә тиеш. Тик, атларыбыз арып, юллардагы көртне ерып бара алмаганлыктан, театр маршрутында каралмаган «Матвеевка» дигән урыс авылында кунарга мәҗбүр булдык. Ягылмаган клубка урнашып, буран тукталганчы шунда калырга тиеш идек. Йокы, кайнар чәй турында тәҗрибәсез мин генә түгел, хәтта гастрольләрдә йөреп «чарланган» артистлар да хыяллана алмый: кем кайда сөялә ала – шунда вакыт уздырырга тырыша. Үч иткәндәй, вакыт та чиксез акрын уза, буран да тукталмый. Шунда мин гомеремдә күрмәгән бер шөгыльнең шаһиты булам: спектакльдә Карандашев ролен башкаручы артист абый, кулындагы кара савытның бөкесен борып, капкачына буы чыгып торган чәй агызды да, аз-аз гына кабып, эчә башлады. Чәй өмет итеп түгел, капкачлы савытын гына күрергә дип, аңа карадым. Ә артист абый: «Разве у тебя нет

«Ярым ятларга килә»дә Харамша ролендә

«Һәйкәл». Арслан

своего термоса?» – диде. Мин югалып калдым. Беренчедән, термосым юк, икенчедән, җавапны нинди телдә бирү дөрес булырын белмим: дәшмәдем.

– Извини, браток, делить не могу. Үземә дә берничә генә йотымлык калган, – диде ул, татарчага күчеп. Аннары, сүзен дәвам итеп:

– Син кем соң? Инде атна буе безнең белән йөрисең, үзең белән таныштырмыйсың? – дип сорады.

– Мин театрга артист булып урнашырга Минзәләгә барам.

– Артист булып урнашыр өчен нинди базовый һөнәрең бар?

– Нәрсә соң ул базовый?

– Җырлыйсыңмы, биисеңме?

– Баянда уйныйм.

– Безнең баянистларыбыз бар шул.

Шуның белән сүз өзелде, бу абый миңа дошманым кебегрәк күренә башлады. Мөмкин булганча, аның белән очрашулардан кача башладым...

...Ләкин аның белән «Зәңгәр шәл» спектаклендә бергә уйнау очрагы безне якынайтты һәм дуслаштырды. Чөнки миңа, качкыннар пәрдәсендә шәкерт ролен башкарып, «Иске карурман» көенә җырларга да кирәк иде. Ул, нота танып, гитарада да уйный белә торган җырчы буларак, миңа вокал буенча дәресләр биреп, җырлавымны тыңлаучыны колагын томаламаслык итте.

1955 елның җәе аның белән бергә гастрольләрдә йөреп узды. Никадәр генә

«Кара бүре». Пасут

якынайсак та, бер-беребезне өйрәнсәк тә, бу артист мине тиешеннән тыш артык якынайтмады, ягъни «панибратство» дигән нәрсә аңа ят иде. Әмма ул кыланчык, «эре» холыклы, тәкәббермасаючан кеше түгел иде. Мәскәүгә укырга китәр алдыннан хушлашу өчен очрашканда ул миңа: «Укып диплом алгач, син инде безгә артист булып кайтмассың, бәлки, режиссер буларак, спектакльләр куярга килгәндә сәлам бирергә тартынмассың», – диде.

Аның шаяру аша әйткән әлеге сүзләрен чынга алмасам да, язмыш миңа Минзәлә театрында өч спектакль кую бәхетен татытты. Ул спектакльләрнең беренчесе Гогольнең «Өйләнү» әсәре буенча иде. Әнвәр Фәсхетдинов анда Подколюсин ролен башкарып, хәтерләрдә калырлык образ тудырды. Театрның ул чактагы директоры Анатолий Богатырев Подколюсин роленә артист Фәиз Бәдриевне билгеләгән иде. Режиссер хокукыннан файдаланып, мин бу рольгә Әнвәр Фәсхетдиновны куюны сорадым. Фәиз Бәдриев үпкәләмәде, киреләнмәде – Әнвәр абыйга бирелгән рольне уйнап, оригиналь образ бүләк итте. (Ул спектакльнең язмасы «Татарстан» телевидениесе фондында саклана.)

Подколюсинның Әнвәр абыйга бирелүенең төп сәбәбе – аның бу рольне 50 нче елларда уйнаганлыгыннан, текстны ятлауны җиңеләйтү өчен булса, икенче сәбәбе – Подколюсин итеп башка артистны күрә алмавым, ягъни икенче төрле әйткәндә, иҗади мөмкинлекләремнең ярлылыгы булгандыр. Башка спектакльләрдә Әнвәр абыйны еш күрсәм дә, мин куйган «Өйләнү»дәге роле соңгысы һәм бердәнбере булып калды.

Яраткан, таныш артистым буларак күрешкәләсәк тә, сәхнәдә бүтән очрашмавыбыз бик үкенечле. Сәхнәдән тыш, Әнвәр абыйның дачасындагы бер очрашуны язып узу, артистлыкка бәйләнешсез булса да, гыйбрәтле булыр.

Телевидение эшләре белән Минзәләгә баргач, ул мине дачасына, мунча керергә дип чакырды. «Мунча» дигәне – керосин мичкәсен тишеп, торба үткәрелгән, мич капкачы куелган такта куыш-шалаш. «Мунча»ның зурлыгы 2 метрга 1,5 метр чамасы. «Мунча» керүнең бөтен хикмәте шунда – мич буларак кыздырылган мичкәгә ялгыш тән тиюдән һәм пар чыгарам, дип, су сипкәндә пешүдән сакланырга кирәк. Бик аңларлык итеп сөйләсә дә, мин аннан пешеп чыктым. Дачаның «кунак бүлмәсе» дигән почмагына урнашкач, Әнвәр абый мине үзе ясаган шәраб белән сыйлап, «пешкән, янган» яраларны оныттырырга керешә. «Шәраб» дигәне бакчасында үскән җимешләрне әчеткән эчемлек булып, градус дигәненең «г» хәрефе дә юк иде. Әнвәр абый кыстый: «Эчмәсәң, үпкәлим», – дип куркыта. Мин һаман бер сүзне кабатлыйм: «Градусы юк бит», – дим. Әнвәр абый: «Градусы булмаса, анда башкасы бар», – ди.

«Язылмаган законнар». Самат

«Мылтыклы кеше». Ленин

Нәрсәсе булуын ул чакта да, хәзер дә хәтерли алмыйм. Әмма утырган килеш йоклап калуым онытылмый.

Әнвәр абый мине кич белән театр машинасында өеннән килеп алды, токмачлы аш белән сыйлады. Озатканда: «Онытма, эчә белүнең дә хикмәте бар, шәрабның да сере градуста гына түгел», – диде.

Хәзер инде шәрабны түгел, шуны эчә алган чакларны хәтерләргә тырышып утырганда градустан тыш шәрабта ул чак тагын ни булуын белә алмавыма гаҗәпләнәм. Ни булсын – чүпрә дә колмак кына бит югыйсә! Үзем өчен кадерле хатирәләр белән мавыгып, Әнвәр абыйның артист, кеше буларак нинди сыйфатларга ия булуын, холык-фигыльләрен хәтерләүдән читкә тайпылып барам икән. Бу мәсьәләдә Әнвәр абый белән бер сәхнәдә иҗат иткән артистларның хатирәләренә таяначакмын. Минем фикеремчә, бу плагиатлык түгел, ә чынбарлыкка, хакыйкатькә таяну гына. Ә хакыйкать-чынбарлык, кем авызыннан чыкса да, хатирәләргә нигез ул.

Менә Әнвәр абый турында аның сәхнәдәшләре Татарстанның халык артисткалары Разилә ханым Муллина һәм Мөнәвәрә Нигъмәтҗанова истәлекләреннән өзекләр:

«Әнвәр абый – кеше буларак булдыклы егет, кешелекле, ярдәмчел, чиста. Өс-башын бик пөхтә йөртә. Шул ук вакытта самими иде. Дөресен сөйләсәң дә, ялганласаң да, юкка-барга ышана. Соңыннан, дөресен белгәч: «Ну, егетләр», – дип башын чайкап куя иде. Әнвәр абый кайвакыт гитара чиртеп, уйга калып утыра. Бәлки сугыш вакытында солдат иптәшләре алдында чыгыш ясаган чакларын күз алдына китергәндер?! «Мин фронтта да спектакльләрдән өзекләр уйнадым», – дип искә ала иде ул. «Берәүнең дә хатын-кызлар киемен киясе килми. Ә мин ризалашам. Бервакыт, без уйнаганда, бомбага тота башладылар. Шартлау дулкыны мине алып аткан, балчык астында күмелеп калганмын. Ничек тыным бетмәгән, диген?! «Итәкләрең күренеп калган, шуны күреп

таптык», – диләр сугышчылар. Ярый әле сугыш кырында хатын-кыз киеме белән үлеп китмәдем, түшлекләр киеп үлеп ятсаң, оят булыр иде», – дип искә ала иде Әнвәр абый. Сугышның үзәгендә, ут эчендә кайнаган шул ул. Җиңүче булып кайтты да!

Бервакыт, тиешле авылга барып җитә алмыйча, урыс авылында туктыйлар. Икенче авылга күчәр өчен транспорт (ат яки сыер) кирәк. Концерт куйсагыз илтәбез, диләр. Ә концерт русча булырга тиеш. Әнвәр абый русча нинди генә җырлар җырламый. Ул елларда Әнвәр абый Азәрбайҗанның популяр җырчысы Рәшид Бәйбутов репертуарыннан күп җырлар башкара. Әнвәр абый бик шәп рәссам да иде. Үсмер чагында акча ясый бу. «Ясау берни түгел, сбыть тяжело», – дия иде. Ул, фальшивомонетчик булып, Нижний Тагил шәһәре янындагы балалар колониясендә утырып чыга. Гастрольгә баргач, үзе «ял иткән» колонияне карап, балачак хатирәләрен искә төшереп йөри.

Әнвәр абый иртән йокыдан авыр уяна икән. Артистлар килеп туктагач кына йокысыннан айный, йөгереп чыга бу, кулында – кайнар коймаклар. «Аларны миңа тоттырды да калган әйберләренә кереп китте, – дип сөйли Мөнәвәрә апа. – Әйберләрен урнаштырып бетергәч, миннән коймакларын сорый. Мин аларны балаларга өләшеп бетердем, дим (гастрольдә балалар үзебез белән). Шунда гомер булмаганны, әй, кабынып китте Әнвәр. Мин бит ашамаган, юлда ашармын, дип алдым аларны, дип көйсезләнә, сезнең балаларга түгел иде ул, ди. Балалар нишләргә белмичә аптырап карап тора, коймаклар сыпыртылган, кулда майлы эз генә калган! Артистлар исә көлә: булган ризыкларыбызны бирәбез, ул алмый, миңа коймак кирәк, ди, шул коймакны гомер буе искә алды. Ул сөйләгән саен, без рәхәтләнеп көләбез, үзе дә көлә. Әнвәр абый, чыннан да, якты күңелле, эчкерсез шәхес иде».

Юлда барганда төрле хәлләр килеп чыга, кызык сүзләр сөйләнә. Әйтик, мондый хәл. Шулай ферма яныннан узып баралар, Әнвәр абый баскан да, сокланып: «Авыл матур, һавасы да саф», – ди. Мөхит абый исә: «Әнвәр, бу бит тавык фермасы, син һаваны дөрес суламыйсың», – дип, эче катып көлә.

Узган күңелле, рәхәт мизгелләр арасында төрле хәлләр булган. Бервакыт хатыны Хәкимә апа Әнвәр абыйга кызлары Альмираны балалар бакчасына илтергә куша. Егет бит инде, ничек бала ияртеп йөрсен?! Чанага утырта да кызын, тиз-тиз генә урау урамнардан бакчага йөгерә Әнвәр абый. Барып җитеп, артына борылып караса, чанада бала юк, әллә кайда ук төшеп калган.

Тагын бер очрак. Октябрь революциясенең 50 еллыгына Погодинның «Мылтыклы кеше», «Кремль курантлары» әсәрләре сәхнәләштерелә. Әнвәр абыйга Ленин образы йөкләнә. Аның магнитофоны бар иде (ул хәзер музейда), шунда яздыра, тыңлый, сыздыра, дөресләп тагын яздыра, образларын шулай җентекләп эшли иде ул. Әнвәр абый эшләгәндә бүлмәсе янына да килмичә, гаиләсе аңа шундый шарт тудыра. Ленинга яраклы кепка таба гына алмыйлар бит. Материалы да юк, төсе килми. Хәкимә апа үзенә кара кашемир пальто алып кайтып, шифоньерга элә. Моны күргән ире пальтоның артын кисеп ала да Ленинга кепка тегә.

Әнвәр абый бәхетле ир иде. Меңәрләгән хатын-кыз аңа гашыйк булса да, ул бердәнберен кадерләп яшәде. Хәкимә апа гомер буе медицина хезмәткәре булды. Әнвәр абый, аны яратып, Хакимка дип йөртте. Юлдан җылы, чиста, тәмле ашлар әзерләнгән сый-хөрмәтле фатирга кайтып керә. Хәкимә тәүлекнең һәр сәгатендә аны санлап, көйләп-кадерләп торды. Артистка түзәргә дә кирәк бит.

Артистка үзеңне контрольдә тота белү дә кирәк. Уңыш, танылу белән сыналу – авыр әйбер. Аны бөтен кеше дә күтәрә алмый. Ә Әнвәр абый гади, бөек артист дигән дәрәҗәне горур йөртте. Тәкәбберлеге юк иде.

Театрның бу бөек артисты пенсия яшенә кадәр егет булып йөрде. Уйнаган образлары яшь булгач, мин 1919 түгел, 1936 елгы, дип йөргән чаклары да булды. 30 ел буе яшь герой образларын иҗат иткән бердәнбер артисттыр ул.

Әнвәр абыйны яратмау мөмкин түгел иде. Җансыз булырга кирәк иде аңа күз ташламас өчен. Уңайлы кеше иде. Гомере буена фронтовик булып калды. Папиросын яртылаш кына тарта, аны бармагын төкрекләп сүндерә дә кире портсигарына урнаштырып куя. Сакчыллыкмы, гадәтме? Ризыкларның бозылмый торганын сайлый, ит киптереп алып чыга да шуны кабып-кабып йөри иде. Без сагыз чәйнибез, ә ул ит чәйни. Аның мактап ашый торган гадәте бар иде. Ризыкны мактый белү дә осталык бит.

Фатирларга тукталганда ирләр фатир хуҗасына тавык пешертәләр (итен, тавык, сөт, май, онын колхоз язып бирә иде). Ашны авызга алырлык түгел, әллә нинди әчкелтем тәм килә. Утырабыз каранып. Әнвәр абый мактый-мактый аш ашый: «Чудесный суп булган, рәхмәт», – ди. Менә хуҗабикә өстәлгә тавык китереп утырта. Турый башласалар, тавыкның ашказаны алынмаган икән. Менә нигә әче булган шулпа.

Әнвәр абыйны гел сыйлап кына торалар. Эчертеп түгел, хәмергә исе китми иде аның. Сәхнәгә киясе аяк киеме эченнән кайнар пәрәмәчләр, өчпочмаклар, пешкән чебиләр дә таба иде ул. Кем куйганын берәү дә белми. Авылга килгәч, клуб ачык бит. Керүчеләр табылган инде, күрәсең. Мәхәббәт төенчеге иде ул. Вазелин, мамык юк вакытлар күп булды. Ә грим салырга кирәк. Безнең ханымнар даруханәгә кереп сорыйлар икән, тик җавап: «Юк бит». Шунда Әнвәр абый кереп китә күзләрен кыскалап, кашларын уйнатып, бу сатучыга русчалатып сүз куша. «Мөмкин булмас микән, хәлегездән килсә, мин канәгать булыр идем», – дигән җөмләләр белән бу йомышын җиткерә... Һәм мамык, вазелин, бинт төяп тә чыга.

Аның авырганын, дублер белән уйнаганын беркем хәтерләми. Булмаган андый хәл. Үз эшендә алыштыргысыз иде ул.

Бөек Ватан сугышын Көнчыгыш Пруссиянең Кенигсберг шәһәрендә тәмамлап, 1945 елда – күкрәгендәге Дан ордены янына тагын биш медален тагып, Минзәләсенә кайтып төшкәндә нинди егет иде икән ул? Их, күрәсе иде!..

Әнвәр Фәсхетдинов башта рус театрына эшкә урнаша. Моны С.Өметбаев күреп ала да үзенә – татар труппасына чакыра. Бу чая егетне ничек ычкындырсын ди остаз? 1945 елдан ул – колхоз-совхоз театры артисты. Әнвәр абыйга ертык фуфайка да, шәп смокинг та бертигез дәрәҗәдә килешә, ул иҗат иткән образлар арасында нинди генә характерлар юк. Ышандырып, чын итеп уйный. «Аның амплуасы юк. Ул, амплуа киртәләрен атлап, һәр җанга туры китереп, нечкәлекләрен белеп уйный», – дип яза театр сәнгате белгече Һәнүз Мәхмүтов. Әнвәр абый кебек уйнаган, төрле образлар тудырган, сәхнәне үз тормышы иткән артистлар мактауга лаек. Ул театрда уйнар өчен түгел, ә җаны теләгәнгә, иҗат итми тора алмаганга эшли. Режиссерлар репертуарны аңа карап төзи. Нәтиҗәдә, мөмкинлекләре елдан-ел арта, киңәя бара.

...Әнвәр Фәсхетдинов дигән егет театрга 1945 елны алына, ә гомере 1995 елда санаторийда дәваланганда өзелә. Аның нур сипкән 50 еллык иҗат гомере шушы ике сан эченә сыйса да, аннан калган иҗат һәм оригиналь яктылыгы бүгенге театр әһелләрен дә нурландырып, яхшылыкка өндәп яши һәм яшәр... ■

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

ГӨСЛӘ

Күп кенә кыллы уен коралларының килеп чыгышы гап-гади җәягә охшаган бер кыллы инструментка барып тоташа. Аннан соң барлык кыллы уен кораллары ике юнәлештә камилләшә башлый: беренчесе – кылларның санын күбәйтү аша (арфа, кифара, кыл кубыз, ятаган, гөслә), икенчесе – кылга лад аралыклары ясап уйнау аша (шертер, думбыра, кыл кубыз, саз).

Гөслә һәм аңа охшаш уен кораллары дөнья халыкларының һәрберсендә бар, диярлек. Аны һәр халык үзенчә атаган. Фин-угырларда гына да аның дистәгә якын атамасы бар: финча – *кантеле*, эстонча – *каннели*, латышча – *кокле*, литвача – *канклес* һ.б. Ә менә *гөслә* сүзе төрки һәм славян халыкларында гына очрый. Урыс галимнәре *гусли* сүзен «гудеть» сүзеннән алынган, диләр. Минемчә, аның төрки атамасы дөреслеккә күбрәк туры килә. Белгәнебезчә, бөек Туран дөньясы Тын океаныннан алып Дунай буйларына кадәр җәелгән. Дунай болгарларында, сербларда, хорватларда элек сызгыч белән уйный торган *guzla, guzli, guzle* дип аталган уен кораллары булган. Күрәсез, болар *гузләү, үзләү* (бугаз белән җырлау) сүзләренә бик охшаш.

Танылган рус фольклорчысы А.Маслов та: «Татарларда гөслә еш очрый... ләкин гөсләгә кадәр аларда җиде кыллы уен коралы булган», – дип яза.

Биредә сүз, тәгаен, ятаган турында бара. Әмма җиде кыллы ятаган, гомумән, көй уйнарга исәпләнмәгән. Садко исеменә бәйле урыс гөсләләрендә дә көй уйнамаганнар, ул нинди дә булса җырга, сөйләмгә яисә үзләүгә (горловое пение) өстәмә музыкаль бизәлеш булып кына торган.

Идел буенда яшәүче фин-угыр халыкларының да, Владимир, Түбән Новгород тирәсендә яшәүче славяннарның да гөсләләре форма буенча ярым ай рәвешендә эшләнгән. Ә менә XI-XII йөзләргә караган Бөек Новгород, Псков шәһәрләре тирәсеннән табылган урыс гөсләләре, *гусли* дип аталса да, ни сәбәпледер, фин, Балтыйк буе халыкларының уен коралларына охшаган.

Шунысы да игътибарга лаек: Идел буенда яшәүче урыс, чуаш, мари, удмурт гөсләләренең тавышлары диатоник лад аралыгына көйләнелә. Ә татар гөсләсе – пентатоник ладка.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

Бүгенгәчә сакланып калган гөсләчеләр ансамбльләре башкарган көйләргә игътибар итик әле. Мәсәлән, иң күп уйнала торган «Арча», «Субаш», «Минзәлә», «Шахта» кебек көйләрне гөсләдән дә матуррак итеп бер уен коралында да уйнап булмый. Курай яисә гармун бизәкләүләрен бирә алмаса да, ул үзенчә искиткеч моңлы уен коралы. Анда аңлатып булмый торган эчке моң бар. Гөсләгә бу моңны кичә-бүген генә салмаганнар, ул гасырлар буе җыелган. Шушы фикерләргә таянып, татар гөсләсенең дөнья халыклары арасында үзенә генә хас йөзе бар һәм ул чын татар музыка коралы, дип ышанып әйтергә мөмкин.

XVI йөздә билгесез урыс авторы татарлар арасында егерме еллар чамасы яши, шул чорда Казан татарларының гореф-гәдәтләрен, көнкүрешен өйрәнә. «Казанлылар... үзләренең гөсләләрендә һәм прегудницаларында уйнап күңел ача, бии, тирә-юнь шаулап, гөрләп тора», – дип яза ул.



Иске гөслә

Тарихи истәлекләрдән күренгәнчә, татар гөсләсенең берничә төре булган. Таҗетдин Ялчыгол егерме дүрт кыллы зур гөслә турында яза һәм аның сызымын сызып калдыра. Андый гөсләләр хәзерге көнгә кадәр сакланмаган. Безнең чорга ярым ай формасында ясалган унике кыллы кече гөсләләр генә килеп җиткән.

Узган гасырның илленче-сиксәненче елларында кече гөсләләрдә уйнаучы ансамбльләр дә бар иде әле. Арча районының Сәрдәбаш авылы гөсләчеләр ансамбле хәтта 1957 елда Татарстанның сәнгатъ декадасы көннәрендә Мәскәүдә чыгыш ясый. Балтач районының Субаш авылы гөсләчеләр ансамбле уйнаган дистәләгән көйләр әлегәчә Татарстан радиосы фондында саклана. Ул елларда гөслә ясаучы осталарның да кайберләре исән-сау иде әле. Ананий Семенов (Субаш), Сарафьон Архипов (Сәрдәбаш), Григорий Волков (Әгерҗе), Ринат Алмаев (Арча) кебек алтын куллы кешеләрдән мин үзем дә гөсләләр ясатып алдым.

Бу гөсләләрнең тышкы кыяфәте дә, ясалышы да артык зәвыклы түгел. Әмма тупас, калын такталардан эшләнгән булса да, аларның тавышы искиткеч көчле, тембрлары соклангыч матур иде.

Бая телгә алынган агайлар гөсләне кипкән чыршы яисә өрәңге агачыннан, элекке осталарның традицияләрен саклап, үзләре булдыра алганча ясады. Шуңа да ул гөсләләрнең үлчәмнәре дә, формасы да бер-берсеннән аерыла. Үзгәрешсез ягы шул – алар унике кыллы һәм пентатоник лад аралыгына көйләнгән. Әүвәл кыллар сарык эчәгесеннән бөтереп ясалса, соңга таба металл җепләр кулланыла башлый. Озынлыгы – 85-92 см, киңлеге – 35-40 см, калынлыгы 13-15 см арасында тирбәлгән. Боргычлары каен, алма, имән агачыннан эшләнгән. Кайберләрен бизәкләп тә ясаганнар. Шулай итеп, гөслә уен коралын ясау һәм аңарда уйнау алымнары өлешчә генә булса да безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

1990 елдан бирле Казанда, этнографик төсмерләрен саклап, шундый ук гөсләләрне



Таһир Вәлиуллин ясаган гөслә

фольклорчы-оста Геннадий Макаров ясый башлады. Үзе ясаган гөсләләрдән мәктәп ансамбльләре оештырып, төрле конкурс-фестивальләрдә катнашып, ул гөслә уен коралында уйнауны тагын да җанландырып җибәрде.

2000 нче елларда татар фольклор ансамбльләренә сыйфатлы, зәвык белән эшләнгән уен коралллары җитенкерәми башлады. Һәм бу саваплы эшкә Казанда халык музыка уен коралллары ясау остасы Таһир Вәлиуллин алынды.

Гөслә күләгәле урында кипкән ак чыршы, өрәңге агачларыннан (2-3 мм калынлыктагы такталардан) ярым ай формасында эшләнә. Озынлыгы – 82 см, киңлеге – 37 см, тирәнлеге – 10 см. Аңа гитара боргычлары ярдәмендә 12 металл кыл тарттырыла. Кылларының арасы – 2 см. Башкарыласы көйгә карап, кылларны пентатоник мажор һәм минор лад аралыкларына болай көйләргә мөмкин:

– *ре мажор:* ре – зур октава; соль, ля, си – кече октава; ре, ми, соль, ля, си – беренче октава; ре, ми, соль – икенче октава;

– *ре минор:* ре – зур октава; соль, ля, до – кече октава; ре, фа, соль, ля, до – беренче октава; ре, фа, соль – икенче октава.

2013 елдан алып мондый гөсләләрне Йошкар-Ола каласында яшәүче оста Гәрәй Мәгъсүмҗанов ясый.

Гөсләне утырган килеш, тез өстенә куеп, ике кул белән уйныйлар. Гәүдәне төз, иркен тотарга, башны аска бик имәскә кирәк.

Гөсләдә уйнауның берничә алымы бар:

1) түбән тавышлы биш кылда (бака кыллары) сул кул белән аккордлар, калган сигез кылда (көй кыллары) уң кул белән чиртеп көй уйнау;

2) берничә кылны берюлы чиртеп (аккорд) уйнау;

3) аккордларны таркатып (арпеджио) чиртеп уйнау;

4) файдаланылмаган кылларны сул кулның бармаклары белән каты басмыйча гына тотып, «сүндереп», уң кулның имән бармагы яки чирткеч (медиатор) белән өскә һәм аска шудырып (глессандо) уйнау. ■

ЯКТЫ КҮҢЕЛЛЕ ҖЫРЧЫ

Лирик колоратуралы якты сопрано тавышка һәм югары башкару осталыгына ия булган күренекле җырчы, Татарстан АССРның халык артисты Наҗия Теркулованың тууына быел 90 ел тулды.

Наҗия апа бик үзенчәлекле холыклы, кәефе тиз үзгәрүчән, әмма самими, эчкерсез кеше иде. Гастрольләргә чыкканда сәхнәдәшләре аның еш кына соңга калуын, көтеп аруларын, кайвакыт көтмичә китеп тә баруларын елмаеп искә алалар. Шул ук вакытта, гадел, кешеләргә карата яхшы күңелле булуын да сагынып сөйлиләр.

Соңгы елларда җырчының өендә иҗади тәртипсезлек хөкем сөрсә дә, ул һичнәрсәне җыярга яки ташларга рөхсәт итмәде. Тормышын сәнгатькә, халыкка хезмәт итүгә багышлаган Наҗия апа түр башындагы пианиносына бер бөртек тә тузан кундырмады, аны өф итеп тотты, элгәрерәк килгән чакларда әле шунда уйнап, җырлап та ала, яшьлек елларын сагынып искә төшерә иде...

Җырчы 2016 елның 14 октябрендә бакыйлыкка күчте. Киндерле бистәсе зиратында җирләнде.

Наҗия Теркулова 1929 елның 25 июлендә Әстерхан шәһәрендә туа. Әтисе Габдрахман абый заводта шофер булып эшли, юлда гел җырлап йөрергә ярата. Аларның өендә бабайлары алып биргән пианино тора, әбиләре мандолина белән скрипка чиерткәли, тальянда тезмәләр уйный. Әниләре Мәрьям дә моңлы тавышлы була.

Наҗияләр гаиләдә өч бала үсә. Җырчының Тәскирә апасы медицина училищесын тәмамлый, энесе авиаторлык хезмәтен үзләштерә.

Татар сәнгатенә гашыйк югары культуралы Габдрахман абый һәрчак иҗат әһелләре белән аралашып яшәргә тырыша. Мәсәлән, аларда композитор Салих Сәйдәшев еш кунак була. Рәссамнар да өзелми. Утызынчы елларда Әстерхан гөрләп тора: биредә «Вулкан» исемле татар драма театры эшли, «Кандыр буе», «Наемщик» кебек музыка әсәрләре зур уңыш белән куела...

Мәрьям һәм Габдрахман Теркуловлар. Әстерхан шәһәре. 1924 ел

Сугыш башлангач, Габдрахман абый фронтка китә, 1943 елда, Ростов өлкәсендә барган яуларда яраланып, һәлак була. Тол калган Мәрьям апа фабрикада хәрбиләр өчен киемнәр тегә, икешәр смена эшли, шул рәвешле, бик зур авырлыклар белән, балаларын аякка бастыра.

Наҗия кечкенәдән рәсем ясарга ярата, яшьтәшләре арасында саф, яңгыравыклы тавышы белән аерылып тора. Мәктәпне тәмамлагач, Әстерхан музыка училищесына укырга керә. Бөек Ватан сугышы елларында Халык иҗаты йорты оештырган концертларда катнаша, госпитальләрдә яралы солдатлар алдында чыгышлар ясый.

Уфа шәһәрендә. 1956 ел

Татарстан районнары буйлап гастрольгә чыккач... Чанада – композитор Заһид Хәбибуллин, җырчылар Эмиль Җәләлетдинов, Нажия Теркулова. 1967 ел

Уку йортында ул М.Корженян һәм В.Сластникова классында белем ала, классик юнәлештәге җыр сәнгатен өйрәнә.

Нажия Теркулова училищены уңышлы тәмамлап, Мәскәүгә, П.Чайковский исемендәге консерваториягә юл тота. Имтихан вакытында Н.Римский-Корсаковның «Снегурочка» операсыннан ария башкара, аны вокал бүлегенә укырга алалар. Ләкин ярты елдан соң биредәге милли музыка факультеты ябыла, укуын дәвам итү өчен аңа Казан дәүләт консерваториясенә юллама бирәләр. Әбисе: «Казанда татарлар күп яши, алар бик матур сөйләшә, анда укуың белән уңарсың», – дип, оныгын канатландыра.

Нажия 1957 елда Казан дәүләт консерваториясенең вокал бүлеген (Е.Абросимова

Нажия Теркулова – Казан дәүләт консерваториясенең 3 нче курс студенты. 1954 ел

классы) тәмамлый һәм Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә җибәрелә. 1957 елда Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты буларак катнаша. 1958 елда эстрада артистларының Бөтенсоюз конкурсында көч сынашып, дипломант исемен яулый һәм СССР Мәдәният министрлыгының мактау гармотасы белән бүләкләнә.

1959 елда яшь җырчы Наҗия Теркулова Абай исемендәге Казакъ дәүләт опера һәм балет театрына (Алма-Ата) солист итеп чакырыла. Биредә ул Н.Тлендиевның «Алтын таулар», Е.Брусиловский сәхнәләштергән «Кыз-җибек» операларында катнаша.

1962-1965 елларда Калинин өлкә филармониясендә эшли.

1966 елда, Татарстан АССР Мәдәният министрлыгы чакыруы буенча, Казанга кайта һәм эшчәнлеген филармониянең әдәби-музыкаль лекторий бүлегендә дәвам итә. Җырчыны гастрольләргә бай иҗади тормыш үзенә тарта. Ул Татарстан сәнгать осталарының Мәскәү, Ленинград, Уфа һәм башка шәһәрләрдә узган концертларында җырлый, чит илләргә чыга.

Наҗия Габдрахман кызы данлыклы дирижерлар Натан Рахлин, Олег Лундстрем, Георгий Гаранян җитәкләгән оркестрлар белән бергә чыгыш ясый...

Аның репертуарында бик күп халыклар композиторларының әсәрләре урын ала. Ә татар сәнгатькярләренең җырларын ул аерым бер җылылык, эчкерсезлек белән башкара. «Беренче мәхәббәт» (С.Садыйкова көе, Ә.Рәшит сүзләре), «Йолдызлы кичтә» (Җ.Фәйзи көе, Ф.Яруллин сүзләре), «Оныта алмыйм» (Р.Яхин көе, М.Ногман сүзләре), «Яшьлек вальсы» (З.Хәбибуллин көе, М.Хөсәен сүзләре), «Җырлама син, иркәм» (М.Мозаффаров көе, А.Пушкин сүзләре), «Былбыл» (Л.Хәмиди көе, Г.Әхмәтҗанов сүзләре), «Өзелгәнсең сиреньнән» (Н.Җиһанов көе, С.Хәким сүзләре) кебек җырларны иң беренче ул сәхнәгә чыгара. Аның башкаруында яңгыраган байтак җырлар бүген татар музыкасының алтын фондына керә.

Наҗия апага күренекле сәнгать әһелләре язган хатлар, автографлар хәзер Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музеенда саклана.

Композитор Ринат Еникеев «Үрләреңне менгәч» дигән җыентыгына мондый

Композитор, СССРның халык артисты Рөстәм Яхинның юбилей кичәсеннән соң. Сулдан уңга: Эмиль Җәләлетдинов, Камил Гатауллин, Вафирә Гыйззәтуллина, Рөстәм Яхин, Гали Ильясов, Наҗия Теркулова, Хәйдәр Бигичев. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры. 1982 ел

сүзләр язып биргән: «Нәҗия ханымга, әсәрләремне җиренә җиткереп башкарганга рәхмәт йөзеннән, гомумән, җырлау осталыгына гашыйк булып, киләчәктә тагы да зур биеклекләргә күтәрелергә теләп калучы Р.Еникеев. 2 февраль 1975 ел».

Композитор Сара Садыйкова «Татарстан – минем республикам» дигән җыентыгын ихлас теләкләр кушып бүләк иткән: «Моей любимой певице, соловью Татарстана, милой Наджие! На долгую память от автора Сары Садыковой. Казань, 1971 год».

Композитор Заһид Хәбибуллин имзалаган җыентыкта: «Хөрмәтле Нәҗия. Син бик матур җырлыйсың! Һәрвакыт шулай матур җырлавыңны телим. Хөрмәт белән, Заһид Хәбибуллин. 19 гыйнвар, 1972 ел», – дигән сүзләр бар.

Нәҗия Теркулова

Рөстәм Яхинның «Ак җилкән» исемле җырлар һәм романслар җыентыгы мондый автограф саклый: «Хөрмәтле Нәҗиягә. Аның шатлыклы көннәрендә Татарстанның халык артисткасы исеме алуы белән чын күңелдән котлап, нык сәламәтлек, зур уңышлар теләп, Рөстәм Яхиннан. 9 гыйнвар, 1983 ел».

Нәҗия Теркулова композиторлар, әдипләр белән якыннан аралаша. Шул рәвешле яңа җырлар да иҗат ителә...

«Нәҗия дус! Менә сиңа вәгъдә иткән җыр тексты – «Кем минем чибәр». Аны, үзең теләсәң, композиторга тәкъдим итеп, үзеңә кирәк музыканы яздыр. Мәхмүт Хөсәен, 1969 ел».

«Хөрмәтле Нәҗия! «Якты таң»ны яңадан язарга туры килде. Берсе үзгәрсә, икенче юлны да үзгәртергә туры килә. Механик рәвештә тезеп барып булмый. Настроениесе, ритмика һаман искечә калды. Бу вариант хәзер миңа күбрәк ошый, хисләргә баерак. Сез шул сүзләрне яздырсагыз яхшы булыр иде. Сезгә уңышлар теләп, ышанып, сәлам белән Сибгат Хәким. 18.11.1981».

Филармониядә озак еллар эшләп, 1991 елда лаеклы ялга чыккач та, Нәҗия Габдрахман кызы Теркулова иҗади эшчәнлеген туктатмый. Төрле мәдәни чараларда, концертларда катнаша.

Гомеренең соңгы елларында ул, катлаулы операция кичерүенә карамастан, рухи яктан бирешмичә, зур сәхнәгә чыгу, концертлар оештыру теләге белән илһамланып яшәде. Без аның белән көн саен телефон аша хәбәрләшеп тордык. Ул үзенең 85 яшьлек юбилеен да зурлап уздырырга, оркестрга кушылып чыгыш ясарга хыялланды...

Татарстанның халык артисты Нәҗия Теркулова, һичшиксез – милләтебезнең асыл бер җәүһәре иде.

Алсу Хәкимова, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музее мөдире ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

МИНИАТЮР ҺӘМ КЕЧКЕНӘ ФОРМАТЛЫ КИТАПЛАР ТУПЛАНМАСЫ

Кечкенә китапчыклар матур бизәнгеч, кыйммәтле әйбер кебек. Алар фәнни һәм әдәби кызыксыну әсбабы гына түгел, алар – сәнгать әсәре дә. Матур итеп ясалган, төпләнгән һәм яхшы бизәлештәге мини-китап асылташка охшый.

Л.Бонди (мәшһүр инглиз коллекционеры, китап сатучы һәм эксперт)

Миниатюр басмалар – матбагачылар могҗизасымы, әллә җитди китап продукциясеме? Алар укучыны үлчәмнәре һәм полиграфик эшләнешләре белән җәлеп итә, шуның белән яшәүгә хаклы булуларын да исбатлый.

Миниатюр китаплар матбагачылык барлыкка килгәнче үк булган. Гомер иҗат иткән мәшһүр «Илиада» поэмасының микроскопик кульъязмасы безнең эраның беренче гасырында күчерелгәнлеге билгеле. Ул бик кечкенә һәм юка пергамент төргәккә язылган һәм аны чикләвек кабыгына сыйдыра алганнар.

Һәрбер кечкенә китапның да миниатюр булып саналмавын искәртергә кирәк. Россия стандартлары буенча миниатюр басманың үлчәмнәре 100х100 ммдан артмаска тиеш.

Мини-басмалар тупланмасы китапханәнең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана һәм XX-XXI гасырларга караган 800 данә миниатюр һәм кечкенә форматлы басманы үз эченә ала. Нигездә, болар – совет чорында чыккан китаплар, күбесе – рус телендә.

Миниатюр басмалар диңгезендә югалып калмас өчен, үзенә күрә «маяклар» – миниатюр китапларның шундый ук кечкенә форматта чыгарылган библиографик күрсәткечләре бар. Ул күрсәткечләрнең бер өлеше безнең тупланмада да саклана. Беренче тапкыр 1975 елда «Книга» нәшриятында бик нәфис ике мини-томда «Миниатюрные книги СССР» дигән күрсәткеч дөнья күргән. Аның беренче томына революциягә кадәрге миниатюр басмаларның, икенче томына совет чоры мини-китапларының тасвирламалары тупланган. 75×50 мм форматындагы икетомлыкның авырлыгы бары тик 120 грамм һәм ул ирләр пиджагының түш кесәсенә иркен сыя. Миниатюр китаплар библиографияләре башка елларда да чыккан, Е.Л.Немировскийның «Миниатюрные книги: вчера, сегодня, завтра» (Мәскәү, 1977) дип аталган күрсәткече дә бар.

Рус классикасы әсәрләре дә кечкенә форматта күп басылган, алар арасында

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.





А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.А.Некрасов, А.В.Кольцов, А.И.Герцен, А.И.Куприн, Н.В.Гоголь, А.А.Блок, С.А.Есенин һ.б. китапларын очратабыз.

Безнең миниатюр Пушкиниана да шактый бай. «Евгений Онегин» шигъри романының берничә варианты, шулар исәбендә 1837 елгы факсимиль басмасы да бар. Соңгысын төсле форзацлар бизи, алар коңгырт төстәге тышлык капкачлары белән бик матур ярашып тора, битләренең аркылы киселе алтынга манылган. «Пиковая дама»ның бик кечкенә басмасы да (Мәскәү, 1967) җете рәсемнәр белән бизәлгән, хәрефләре шул дәрәҗәдә вак ки, текстын зурайткыч пыяладан башка һич укып булмый.

Тупланмада М.Ю.Лермонтов иҗатына багышланган китапчыклар да аз түгел, аларның Ставропольдә нәшер ителгәннәре исә аеруча күркәм. Боларның берсе – М.Ю.Лермонтовның үз рәсемнәреннән репродукцияләр белән бизәлгән өч томлык «Сайланмалар»ы (1977). «Лермонтов и Кавказ» (1988) дигән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы М.Врубель «Демон» әсәренә ясаган иллюстрацияле супертышлык белән нәшер ителгән. П.Селегей, шагыйрь иҗатын бик яратып, аның «Последние стихи» (1975) китабын төзегән. Кечкенә сувенир китапчык, төзүченең әйтүенә караганда, «даһи иҗат җимешләрен чагылдырып кына калмый, бу – шагыйрь тормышының кешеләргә бүләк итеп калдырылган бер кисәкчеге».

Мәкальләр, афоризмнар һәм фикерле өземтәләрнең кечкенә формат белән чыгарылган җыентыклары да күзне иркәли. Шундыйларның берсе – Козьма Прутковның



Китап кибетендә акылны да акчага сатып алып була.

Татар халык мәкале





«Плоды раздумья: мысли и афоризмы» (Пермь, 1973) китапчыгы, үлчәмнәре 50×40 мм, төпләменә түгәрәк лупа бәйләп куелган. Беренче битеннән соңгысына кадәр китапчык рәссам В.Вагин тарафыннан язылган һәм рәсемнәр белән бизәлгән. Шул рәвешчә, К.Прутковның үзе язган төп нөсхә кесә дәфтәрен торгызуга омтылыш ясалган кебек. Рәссам, бик төгәл итеп һәм бөтен ваклыклары белән, әлеге шәхеснең язу үзенчәлекләрен сурәтли: башлары бөтерелгән хәрефләр, ышкып бозылган кара таплары, бит саннарын дөрес куймау – ырым-шырымга ышанучан Козьма 13 нче битне «12+1» рәвешендә билгели. 1974 елда бу басма Бөтенсоюз китап сәнгате конкурсында беренче дәрәҗә дипломга лаек була.

Халык авыз иҗаты – миниатюр китаплар нәшер итүчеләрнең яраткан темасы. «Уральские пословицы и поговорки» (Чиләбе, 1978), «Каменные цветы: сказы, сказки, легенды» (Донецк, 1983), «Сибирские побасенки» (Новосибирск, 1987), «Сказано – связано: пословицы и поговорки Прикамья» (Пермь, 1988), В.Рыбаковның «Народный календарь» (Свердловск, 1990) басмалары һ.б. китапчыклар игътибарны җәлеп итә.

Күп кенә миниатюр басмалар күренекле даталарга туры китереп чыгарылган. Мисалга, 1985 елда Пермь китап нәшрияты, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 40 еллыгына багышлап, «Весна Победы» дигән җыентык бастыра. Аның форматы – 55х74 мм. Шушы ук сериядән тагын бер китапка шагыйрь-фронтовиклар әсәрләре бергә җыелган: «Огненные строки: стихи поэтов-уральцев, павших на Великой Отечественной войне» (Свердловск, 1988).

Тупланмада эчтәлеге һәм жанры белән төрле булган башка бик күп миниатюр һәм кечкенә форматлы китаплар да бар. Күпчелеге гадәти булмаган тышлыклар, рәсемле супертышлыклар белән чыгарылган, эчләрендә гаҗәеп матур рәсем-иллюстрацияләр ясалган, ефәк бау-кыстыргычлар беркетелгән.

Безнең тупланмада китаплары урын алган нәшриятларның географиясе дә бик киң. Китапчыкларның күбесен Мәскәүнең алдынгы нәшриятлары, шулай ук Пермь һәм Ставрополь китап нәшриятлары чыгарган. Ленинград, Свердловск, Новосибирск, Ростов-на-Дону, Саратов, Чиләбе һәм башка шәһәрләр нәшриятларында дөнья күргәннәре дә бар. Рус шагыйрьләренең Казанда нәшер ителгән китапчыкларын атап үтәргә мөмкин, мәсәлән: Е.А.Баратынскийның (1984) һәм Г.Р.Державинның (1986) «Стихотворения» басмалары.

Миниатюр басмаларда татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әсәрләре дә аз түгел, алар, нигездә, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган: Габдулла Тукайның «Без туган бер җепкә бергә теркәлеп...» китабы (1976), Фатих Кәримнең «Ант»ы (1978), Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ы (1978), Хәсән Туфанның «Лирика»сы (1980), Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ы (1981), Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы (1982), Габдулла Тукайның «Шигырьләр һәм поэмалар»ы (1986), Фатих Әмирханның «Хәят»ы (1986), Галимҗан Ибраһимовның «Хикәяләр»е (1987), Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е (1987), Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш»е (1990), Сибгать Хәкимнең «Фазыл чишмәсе» (1991), Һади Такташның «Җир уллары» трагедиясе (1993), Роберт Миңнуллинның «Әнкәмнең догалары» (1995), Шәехзадә Бабичның «Исемнәр бакчасы» (1997), Гаяз Исхакыйның «Остазбикә»се (1997), Туфан Миңнуллинның «Робагыйлар»ы (1999), Сәгыйть Рәмиевнең «Сызла, күңлем!»е (2000), Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» факсимиль басмасы (2005). Алар белән беррәттән, шулай ук «Татарские пословицы» (1979), «Конституция (основной закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики» (1980), «Без яшибез Совет илендә» дигән шигырьләр җыентыгы (1982), «Сандугачым-былбылым»: татар халык җырлары (1985), «Герб, флаг, гимн СССР. Герб и флаг РСФСР. Герб и флаг Татарской АССР» (1985), Гомәр Хәйям «Робагыйлар»ы (1986), «Агыйдел»: халык җырлары (1989), Каюм Насыйриның «Китаб-эт-тәрбия» (1994), «Казан-Уфа-Чиләбе...»: татар халык җырлары (1994), «Юл догасы»: Коръән сүрәләре, намаз догалары һәм юл йөргәндә укыла торган догалар (1995) һ.б. китаплар да нәшер ителде. ■

АВГУСТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Август ае башында Актаныш районының Яңа Әлем мәктәбе каршында эшләп килүче «Серле дөнья» курчак театры, «Театраль Идел буе» театр фестивалендә катнашып, иң яхшы дип табылган биш театр исемлегенә керде.

● Август ае башында Актаныш районындагы Такталачык авылының мәдәният хезмәткәрләре агитбригадасы хуҗалык уңганнарына матур концерт куйды.

● Август аенда язучы Нәзифә Кәримованың туган авылы Арташта (Мамадыш районы) яңа мәчет ачылды. Мәчет ачу тантанасында 400гә якын кеше катнашты.

● 5 августта Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев X Халыкара мәктәп укытучылары фестивален ачу тантанасында катнашты һәм Россия Федерациясенең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән 500дән артык укытучы алдында чыгыш ясады.

● Август аенда 2019 елның Союздаш Дәүләт иҗтимагый премиясе лауреаты исеме Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия мөфтиләр советы рәисе шәех Равил Гайнетдинга бирелде.

● 7 августта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Ростов өлкәсендә булып, өлкәнең «Якташлар» татар-башкорт мәдәни үзәге иҗтимагый оешмасы активы белән очрашты. Очрашуда Ростов өлкәсе губернаторы Василий Голубев та катнашты. Милләттәшләр белән очрашуны Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразыев алып барды.

● 9 августта «Зөя калкулыклары» тау чаңгысы комплексы территориясендә XIII Халыкара тарихи техника фестивале ачылды. Чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

«Бүген – ретроавтомобильләр бәйрәме. Биредә 200дән артык катнашучы җыелган, фестиваль халыкара дәрәҗәгә ия», – диде «Авторетроклуб-21» президенты Фәрит Мөхәммәтшин.

● 11 августта Апас районының Иске Йомралы авылында «Гармун моңы – йөрәк җыры» фестивале үтте. Фестивальне район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рөстәм Мингазиев ачты. Чарада Табар Черкене, Әлмәндәр, Зур Күккүз, Олы Болгаер, Чүрибураш авыл җирлекләрендә яшәүчеләр катнашты.

● 11 августта Кукмара районының Туембаш авылында парлы чишмә – «Әниләр һәм әтиләр чишмәсе»н ачу тантанасы булып узды.

● Августта Ульяновск өлкә типографиясендә күренекле дин әһеле Әнвәр хәзрәт Адельшинның «Иске Кулаткының Җәмигъ мәчете» дигән китабы басылып чыкты.

● 13 августта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Калмык Республикасы башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Бату Хасиков һәм Әстерхан өлкәсе губернаторы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Игорь Бабушкин Казанның «Әл Мәрҗани» мәчетендә булды. Әлеге мәчетнең имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдин кунакларга мәчетнең тарихы һәм мәшһүр мәгърифәтче, галим Шиһабетдин Мәрҗани турында сөйләде.

● 14 августта «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе (баш мөхәррире – Гөлнара Сабирова) Казан ресторанннарының берсендә Корбан ашы үткәрде. Бәйрәм чарасына мартәбәле кунаклар һәм ветеран-журналистлар – барлыгы 80 кеше чакырылган иде. ■

Мирасворд

Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» повестендагы герой

Хөснул Вәлиуллин операсы

Эсфир ... (татар драматургы, прозаик)

Бик зур, көчле, тиз оча торган әкияти кош

Нота

Кар барсы

Кадыйр Сибгатуллинның тәүге шигырьләр китабы

Габдулла Тукайның 1908 елда язган шигыре

Калын, тыгыз йон тукыма

Корьән сүрәсе

Башкорт халык җыры

Өйнең тышкы стенасы тирәсендә туфрактан өелгән нигез

Борынгы Рим императоры

Садриев, Шәмсуаров

Җайдак утыргычы

Татар халкының борынгы бәрмә уен коралы

Албаниядә административ-территориаль берәмлек

XIX йөз рус рәссамы

Ил гизеп, туган җирдән еракта, читтә каңгырып йөрү (иск.)

Атның борынгы кыргый төре

...-чи

Әхмәт Гаделнең 1978 елда Ташкентта чыккан шигырьләр китабы

Самара өлкәсендә татар телендә чыга торган газета

Җырчы ... Гарифуллина

Поляк алпавыты

Матур, сөйкемле (иск.)

Катыкны суга болгатып ясалган эчемлек

Тур Хейердал көймәсе

Яшь каен агачы (диал.)

Синтаксис (иск.)

Мисыр мифологиясендә чүл Алласы



Теге дөньяда мөселманнарны күккә очырта торган канатлы ат

Ләм, дуен

Драма әсәре

Шагыйрь ... Сәгыйров

Ерак җир, урын (диал.)

... Гайсин, Әхмәдиев

Оренбургта Хөсәен Ямашев чыгарган газета

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: «Сәхнә», сыза, санам, Рамо, ар, әфсен, скетч, «Аваз», Үкәк, өрпәк, каравыш, Илида, гравюра, «Ниса», Трир, Маликов, грек, фәза, Ади, «Ант», «Уяну».
Өстән аска: соса, Күк, «Гэм», каюр, Хәниф, Рә, аел, Сакаев, Ифрат, Әлмиев, юшкә, назыйр, «Озату», Арвад, Ибн, «Сорыкортларга», Истр, замат, Әйди, орчык, Анак.

Рәис Габдулла төзеде.

ТАССР тарихы – фотоларда

Арча районының Урта Сәрдә авылындагы чүәк артеле

Арчаның данлыклы читекчесе Әнәс Гыйләҗиев

Индира Ганди өчен махсус заказ үтәүче Илсөя Мостафина. Биектау районының, Мүлмә авылы. 1958 ел

Арча милли аяк киемнәре фабрикасының Ямаширмә филиалында эшләүчеләр: Илсөя Хәсәнова, Гөлсинә Исмәгыйлева, Гөлнур Хәлилова. 1968 ел

Фотолар Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарих-этнография музее фондыннан алынды



СОДЕРЖАНИЕ. СЕНТЯБРЬ 2019

И останется в мире слово моё…: Шаукат Гадельша.

Историческое наследие: «Сююмбике». О.Иванова; «Этруски – римские умельцы». С.Шамси; «Татарские спичечные фабрики». Л.Муртазина; «Под огнём большевизма». К.Наджми; «Археологический дневник». М.Усманов; «На татарском или на русском языке?» Г.Губайдуллин; «Гаяз Исхаки на страницах французского журнала». Л.Галиева.

Татарский мир: «Книга с зелёной обложкой». Х.Ибрагим; «Наше время и наши современники». Р.Хамидуллина; «Стихотворное обращение к Пушкину». З.Мансуров.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Хусаин мирза». Ф.Бурнаш.

В глубинах памяти: «Свидетели истории». А.Дубин; «Школы и одноклассники». Л.Лерон.

Художественное наследие: «Анвар». А.Зарипов; «Древние татарские музыкальные инструменты». Р.Гилязов.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. SEPTEMBER 2019

There will be left my word in the world…: Shavkat Gadelsha.

Historic heritage: «Suyumbike» by O.Ivanova; «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «Tatar match factories» by L.Murtazina; «Under fire of Bolshevism» by K.Nazmi; «Archeological diary» by M.Gusmanov; «Is it in Tatar or in Russian?» by G.Gubaydullin; «French magazine lights Gayaz Iskhaki» by L.Galieva.

Tatar world: «The green cover book» by Kh.Ibragim; «Our time and our contemporaries» by R.Khabibullina; «Poetic duel with Pushkin» by Z.Mansurov.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Khusain Mirza» by F.Burnash.

And broke the world cage out: From Gumar Bashirov's diary.

From the deepest store of memory: «Eyewitnesses of the history» by A.Dubin; «Schools and classmates» by L.Leron.

Creative heritage: «Anvar» by A.Zaripov; «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

Виктор Куделькин

«Идел култыгы».
1990. Киндер,
майлы буяу

Рәссам Виктор Куделькин 1911 елның 9 гыйнварында Чуашстанның Алатырь шәһәрендә туган.
1938 елда Чабаксар рәсем сәнгате училищесын тәмамлый.
1940 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, Бөек Ватан сугышы ветераны.
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1960 ел), ТАССРның Халык рәссамы (1971 ел), РСФСРның атказанган рәссамы (1978 ел), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1986 ел).
Казан шәһәрендә яшәп һәм иҗат итеп, Татарстан башкаласында вафат булды.

«Сыер савучы Исмәгыйлева портреты».
1960. Киндер, майлы буяу

«Социалистик Хезмәт Герое, ташчы А.А.Хабаров портреты». 1960. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Беренче рәттә:
уң яктагы кыз бала –
Нәкыя, аның артында –
әнисе Нәубаһар апа.
1944-1945 еллар

(Н.Гыйләҗева.
«И, бөек китап...»)

Фин татарлары тарихы. Чыңгыз Сафиулла
Кем ул – Карәхмәт? Фатиһ Кутлу
И, бөек китап... Нәкыя Гыйләҗева
Нәдер, Гали абый, Мингали Исламович... Әхтәм Зарипов
Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләре

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• ***uslugi.tatarstan.ru*** *сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• ***podpiska.pochta.ru*** *сайты ярдәмендә*
электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*